КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№ 10
22 сентябрь
1995 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

БҮГЕНГЕ САНДА:

2 *Радик ФӘИЗОВ.* Күмәк хезмәт кешелек җәмгыятенә дә, хәтта төрле җанварлар, бөҗәкләр өчен дә күпкә отышлы һәм уңайлы.

5 *Флүн МУСИН.* Берләштерелгән дәүләт музееи Татарстан Милли музее итеп үзгәртү чираттагы эшебез булып тора.

9 *Таҗи ГЫЙЗЗӘТ.* Шушы вакытка кадәр Татарстан язучылары җитәкче оешмалар тарафыннан иҗат мәсьәләләренә карата бернинди кайгыртучанлык һәм игътибар тоймый.

14 *Атилла РАСИХ.* «Тыныч еллар күләгәсендә» дигән яңа романымда әдәбиятка ничегрәк килүем, шинди киртәләр-каршылыклар аша узуым турында сөйләргә теләдем.

23 *Андрей ТАРАСОВ.* Үзен чын урыс дип атаучы Николай Лысенко, кул кысышудан баш тартып, башка бер русиялегә — мөселман Халит Яхинга карата бөтен ил алдында тупаслык күрсәтте.

Дөнья базарына чыккан чакта
Көзге чебеш булып чыкмыйлар!..

РУХИ ХӘЗИНӘБЕЗНЕ БАЕТКАН ӘДИП

Хөрмәтле Гариф Ахунҗан улы!

Җитмеш еллык бәйрәмегез уңаеннан Сезне, республикабызның олы әдибен, ихлас күңелдән котлыйм! Саулык-сәламәтлек, бәхет, киләчәктә дә бетмәс-токәнмәс иҗат ләззәте телим!

Җир йөзендә кеше дигән олы хәзинә бар. Һәм аның тумыштан чишмә суыдай саф күңеле бар. Язучыларның, гомумән, сәнгатькәрләрнең төп вазифаларыннан берсе — әнә шул күңел сафлыгын-пакьлеген саклау, аны рухи баету, әхлакый тәрбияләү. Саный китсәң, ул вазифалар — диңгездәге тамчылар саны кадәр. Чөнки әдәбият-сәнгать үзәгендә бөтен барлыгы белән кеше тора, ә сәнгатькәрнең иҗат кыры — халык тормышы. Гариф Ахуновның иҗат кыры — татар халкы тормышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге. Менә шуңа күрә, ул иҗат күпьяклы, киң колачлы. Шуның өчен дә Гариф Ахунов — халык язучысы.

Гариф Ахунов каһарманнары дигәндә, күз алдына җиң сызганып, хезмәтеннән тәм табып, аңа үзгә ямь биреп,тырышып эшләүче хезмәт кешесе килеп баса. Шунысы кыйммәт: әлеге образлар язучының үз образы белән тәңгәл килә. Мин белгән Гариф Ахунов һәрвакыт хезмәттә, эшчән, актив, туры сүзле, зур абруйлы, халкыбызның олы мәхәббәтенә чын-чынлап лаеклы мәшһүр каләм остасы.

Хөрмәтле Гариф Ахунҗан улы!

Сезнең олы талантыгыз белән сугарылган, дистәләрчә телләргә тәрҗемә ителгән берсеннән-берсе матур роман, повесть, драма әсәрләрегез, республикада әдәби хәрәкәт барышын җентекле өйрәнеп язган мәкаләләрегез, менә дигән тәрҗемәләрегез, иҗтимагый тынгысызлыгыгыз — болар Сез яулаган биеклекләр, үрләр. Биеклектән биеклеккә атлап, Сез бөеклеккә барасыз. Шушы изге хезмәтегез өчен олы рәхмәт әйтеп, мин Сезгә, халкыбыз өчен җан атып яшәүче һәм эшләүче кодрәтле иргә, ак юл телим!

Татарстан Республикасы Президенты
Минтимер ШӘЙМИЕВ.

МИН ӘЙТТЕМ

Радик ФӘИЗОВ

Күмәк хезмәт отышлы

Быелның 13 августында кич белән «Русия» каналыннан Американың «Авыл» дигән фильмын күрсәттеләр. Карадыгыз микән шуны? Океан арты фермерлары тормышын сурәтләгән бу кинокартина күптөрле уйларга сала. Безнең өчен һич көтелмәгән, безнең башка килмәгән нәрсәләрне ачып күрсәтә ул. Никадәр бай, никадәр алга киткән бу илдәге крәстиянннең хәле нинди тотрыксыз, көндәлек хезмәте ничек авыр икәнне күреп тәмам аптырашта каласың. Крәстиян белән бәйләнеш тотучыларның никадәр имансыз, капитализм законнарының ни дәрәҗәдә кырыс икәнен күреп.

Халык арасында йөргән сүзләрдән һәм матбугаттагы кайбер чыгышлардан да сизелеп тора ки, безнең зур күпчелегебездә чит илләрдәге барча фермерлар, җирдә иген үстерүчеләр, мал-туар асраучылар иркенлектә, мул тормышта, хәтта инде рәхәтлектә яши, дигән фараз бар. Киң таралган, күңелләргә тирән кереп утырган фараз. «Һай, кара син аларның тормышын! Алардагы техниканы, машиналарны күрсән. Нинди йортларда торалар, ничек кинәләр алар!» Менә мондый соклану сүзләрен еш ишетәсең. Ә беләсезме каян килә безгә бу наив соклану? Тышкы күренештән, тышкы ялтыраудан. Без чит илләрдә, шул ук АКШта булып кайткан җәй-йөремнәрнең андагы тормыш тирәнлегенә бер генә карыш та үтеп кермичә алынган беренче тәэсирләрен тыңлыйбыз. Журналистларның да күбесенчә шул ук тышкы күренешләрне сурәтләгән язмаларын укыйбыз. Чит илләрне ялтыр-йолтыр иттереп төрле киножурналлардан күрсәтәләр. Без боларны укыйбыз, тыңлыйбыз, карыйбыз һәм... таң калабыз. Кемнәрдер алган беренче тәэсирләр, беркатлы сокланулары безгә дә килеп сылана. Чын күңелдән ышануга әйләнә.

Әлбәттә, хәл болай гади генә дә түгел әле. Матбугатта чит ил фермерларының тормышын, аларның яшәешен бөтен барлыгы, тирәнлеге белән яктырткан язмалар да җитәрлек. Капиталистик җәмгыятьнең чын йөзен ачып, аның законнарын күрсәтеп, безгә чын хакыйкатьне китереп җиткергән язмалар. Бу хакыйкать әлеге илләрдәге язучыларның әдәби әсәрләрендә дә бик тирәнтен яктыртыла. Һәм менә бу «Авыл» дигән фильм. Алай да американнар молодец алар! Туган илләре, андагы хәлләр турында үзләре үк хакыйкатькә никадәр тугрылыклы булган, бөтен кимчелекләрне, кыенлыкларны һич яшермичә әйтеп салган фильм төшергәннәр. Мактанмыйча, бернәрсәне яшермичә, киметмичә һәм арттырмыйча. Бездә булсамы?! Ялган горурлыкка бирелү, тегесен киметү, монысын арттыру, нәтиҗәдә ялган юлына басу башлана. Дөреслекне пычагым табарсың. Элек тә шулай иде, бу гадәт бездән әле дә китеп бетмәгән..

Ярый, монысы сүз уңаенда. Теге фильмны карамаганнарга без аның эчтәлеген азрак сөйләп бирик. Америка, яшь фермер гаиләләре. Машиналар күп, техника менә дигән. Фермерлар торган икешәр катлы, әллә ничә бүлмәле, бөтен уңайлыклары тудырылган йортлар турында безнең авыл кешесенә әлегә хыялланырга гына кала. Әмма... эш! Алны-ялны, көнне-төнне белмәгән авыр хезмәт. Әмма... базар икътисады шартлары. Аз гына уңышсызлыкны, ялгышлыкны да гафу итми торган, һәр адымыңны сагалап торган базар икътисады. Ни эшли аласың син аларга каршы үзеңнең машиналарың, техникаң белән генә. Монда шайтанның үзе кеби үткер, елдам, зиһенле булырга кирәк. Ә бөтен кешегә дә алай булырга димәгән.. Ялгышлыклар җибәрәләр, ахырда бөләләр теге яшь гаиләләр. Фермер Арлен авырлыкларны күтәрә алмый, үз-үзенә кул сала. Билл, нинди тәртипле, инсафлы, сабыр Билл, ни эшләргә дә белми, ахырда хатынын, балаларын кыйнарга сабыша... Фаҗига, кешеләр, гаиләләр, тормыш фаҗигасе. Менә шундый хәлләр!

Ярый, болары болай. Ә беләсезме нәрсә, минем монда әйтәсе килгән фикер, алга куйган максат Америка фермерларының тормышын ямаплау, шуның белән бездә фермер булган яисә булырга ниятләнеп торган кешеләрне куркыту, аларны кисәтү түгел. Һич кенә дә! Америка фермерларының барысы да бөлмиләр. Андый авыр хәлгә дә төшмидер. Моңарчы американнарның икмәксез утырганнары, безнең Рәсәй шикелле, аны бүтәннәрдән теләнеп йөргәне юк әле. Мин монда чынбарлыкны гына искә төшердем. Өстәвенә, анда да фермерларга караш үзгәргәндер. Мәсәлән, фильм азагында ук, иген игүчеләрне яклап, яңа законнар кабул ителүе турында искәртелде. Әлбәттә, фермер булырга теләгән кешегә бездә дә юл ачык булырга, аңа төрле яклау, хуплау күрсәтелергә тиеш. Һәм бу чынбарлыкта да шулай.

Минем әйтәсе килгән нәрсә икенче. Бу фкерне мин бик күп кешеләр белән сөйләшкәннән соң әйтәм: авыл хуҗалыгын алып баруның күп төрле яңа формалары белән беррәттән, күмәк хуҗалыклар да яшәп калырга тиеш. Гади итеп әйткәндә, колхозлар һәм совхозлар. Инде безнең бер буын кешеләр туганнан алып гомере буена эшләгән, күнегелгән, сыналган, бик авырлык белән булса да бүгенге шартларга, базар икътисадына да яраклашып килгән күмәк хуҗалыклар.

Авылларда булып, анда яшәүче кешеләрнең сүзләренә колак салсаң, аларның күпчелеге, бик зур күпчелеге күмәк хуҗалыкларның таркатылуын теләми. Әйтик, безнең Әтнә районы Дусым авылыннан бер генә кешедә дә андый теләк тә, ният тә юк. Белмим, алар мондый хәлне күз алдына да китермиләр булыр. Электәге нинди кодрәтле «Игенче» колхозыннан аерылып чыгып, җирләре шактый азаеп калса да, барысы да тырышып кына «Дусым» күмәк хуҗалыгында эшләп йөрүләре.

Бер уйлаганда, хәзер күмәк хуҗалыкларны таркатып ташларга, һәркем үзенә аерым, хуҗа булырга тулы мөмкинлек бар. Һәркем үзенә тиешле техникасын, җирен аяк терәп сорый һәм аерып та алырга мөмкин. Ә менә авыл кешеләренең зур күпчелегендә моңа омтылыш күренми. Сорау туа: ник алай? Бу сорауга җавап эзләгәндә, шунысын искә алырга кирәк, авыл кешеләре, кайберәүләр фараз иткәнчә, үз язмышларына һич тә битараф түгел. Алар барысын да уйлап, исәпләп, чамалап карыйлар. Кешеләрне аерымлыкка омтылудан тыеп торган сәбәпләрнең берсе һәм иң зурысы: күмәк хезмәт отышлы, күмәк хезмәт җиңел. Бигрәк тә авыл хуҗалыгы эшләрендә. Монысын авыл җирендә яшәгән һәркем бик яхшы белә. Өстәвенә, авылда әле колхозлар чыкканчы, аерым хуҗалыклар вакытында бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы басуларда эшләп җык чиккән, аерым хезмәтнең никадәрле авыр, ялыктыргыч икәнен үз җилкәсендә татыган кешеләр әле дә булса бар. Аларның берсе генә дә ул заманнарны мактап сөйләми. Әгәр ышанмыйсыз икән, әнә хәзерге сиксән-туксан яшьлек әбиләр белән сөйләшеп карагыз. Аллага шөкер, хәзер авыл хатыннары озын гомерле, бик өлкән әбиләр дә җитәрлек.

Күмәк хезмәт кешелек җәмгыятендә дә, хәтта төрле җанварлар, бөҗәкләр өчен дә аерымлыктан күпкә отышлы һәм уңайлы. Гадиләштереп әйтсәк, кеше, мәсәлән, бишәүләп бергә эшләгәндә, бер үк вакыт эчендә, үзе генә эшләгәннән шактый күп җитештерә. Умарта кортлары, кырмыскалар, бергә оешып яшәүче башка бөҗәкләр дә шулай. Бу фән тарафыннан күптән расланган, исбат ителгән күренеш. Аның хәтта күмәклек файдасы (эффект коллективности) дигән фәнни исеме дә бар.

Тагын бер зур сәбәп — җаваплылык хисе. Монысы да бик мөһим нәрсә. Һәм җаваплылыкны үз өстенә алырга теләмәгән һәр кешене куркаклар, начарлар рәтенә кертеп кую да бик үк дөрес булмас. Менә хәзерге заманда, әйтик, утыз гектар җирне үзенә алу, анда хуҗалык итү, иген үсте... рү, бу хуҗалыкны бөлдерм... чә, таркатмыйча алга ал... бару җаваплылыгын үз өсте... алып кара әле син! Ә? Бик зу... вазифа бит бу. Моңа һәркем... нең дә йөрәге, тәвәккәллеге җитми, һәм андый эшкә җө... рьәт итмәү өчен кешеләрне битәрләп тә булмый. Табигать анабыз безне бик күп төрле-төрле итеп яраткан: б... бик йөрәкле, уңган-булган ке... шеләр, бар уртачалар. Һәм шул булдыклы затлар янәшә... сендә уртачалар да яшәргә хокуклы бит әле.

Монда шунысын танырга кирәк, нәкъ менә шушы ча... елгыр затлар янәшәсендә у... тачаларның да яшәп ятуы, те... ләсәң-теләмәсәң дә, берник... дәр тигезләүгә (уравниловка... га) китерә. Социалистик җәм... гыятьне яратмаучылар нәкъ менә моны иң зур аргумент... итеп куялар. Янәсе, салагае... ләр, уңмаган-булмаганнар да ашап ята. Әмма әлеге җәмгы... ятьнең төп максаты нәкъ менә шушы тигезләүне акрынлап киметү, уртак эш өчен һәркемдә бердәй җаваплылык хисе тәрбияләү иде. Икенчедән, мин үзем тигезләүдән курыккан кешеләрне өнәп бетер... мим. Һәрхәлдә, мин белгән андый кешеләрнең барысы да диярлек астыртын, бик нәфесле, шома, асылда әллә ни көч түкмичә генә зур байлыкларга ия булуны өмет иткән адәмнәр иде. Һәм алар социализмны да, күмәк хуҗалыкны да каты сүктеләр.

Алай да берникадәр тигезләүдән котылып булмауны күмәк хуҗалыкның зур бер кимчелеге итеп танырга кала. Һәм, табигый хәл, аның әле бүтән җитешсезлекләре дә бар. Әйдә, булсын кимчелекләре! Димәк, ул камилләштерүгә мохтаҗ.

Әле менә шушы мәкаләне язып йөргән көннәрдә мин Казан поездында ике кеше белән сөйләшеп кайттым. Арча районының «Курса почмак» күмәк хуҗалыгыннан алар. Исемнәрен сорамадым, әмма икесе дә шактый шома, күренеп тора, шактый булдыклы, ахры, мал-мөлкәтле кешеләр. Тел очларын яшереп кенә сөйләшәләр. Әмма ки, аларның икесе дә күмәк хуҗалык яклы. Һәм аның таркалу, зур үзгәрешләр кичерү ихтималына да борчылу белдерәләр.

Безнең якта авыл халкы бу дөньяны бергәләп көтү, бергә тормыш... тәләп яшәү, бергә... иту яклы. Чыннан да, күмәклеккә ни җитә!

Җидегән
ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР
5 6 7 1 2 3 4

Президент котлавы

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев барлык профсоюз әгъзаларын һәм республиканың профсоюз активын республика профсоюзлары оешуга 75 ел тулуы уңае белән котлады, уңышлар, бәхет, иминлек теләде, нәтиҗәле хезмәттәшлек итәчәгебезгә иманым камил, диде.

Думага депутатлыкка кандидатлар

«Азатлык» радиосының хәбәр итүенә караганда, Татарстанның халык артисты Вафирә Гыйззәтуллина һәм язучы Айдар Хәлим Русия Федерациясенең Дәүләт Думасына депутатлыкка кандидат булып теркәлгәннәр. Аларны кандидат итеп «Нур» Бөтенрусия мөселман иҗтимагый партиясе күрсәткән.

Бәйләнеш офыклары киңәя

Татарстан Республикасының чит дәүләтләр белән икътисади һәм мәдәни бәйләнешләре елдан-ел киңәя бара. Узган ел, мәсәлән, Татарстанга Германиянең Түбән Саксония Җирә Премьер-министры Герхард Шредер визит белән килеп, республика белән танышып, төрле предприятиеләрдә булып киткән иде. Бәйрәм ашы кара-каршы дигәндәй, күптән түгел Татарстан Премьер-министры Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге делегация Германиядә булып кайтты. Шушы очрашу вакытында Татарстан Республикасы һәм Түбән Саксония Җирә хөкүмәтләре арасында хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды. Шул уңайдан 18 сентябрьдә хөкүмәтебез җитәкчесе матбугат конференциясе үткәрде.

Журналистларны Татарстанда җитештерелгән продукцияне Германиягә чыгарылуы мәсьәләсе кызыксындыра. Чөнки безнең икътисади сәүдә өлегә чималга корылган. Чынлап та, безгә үз товарларыбызны дөнья базарына чыгару өчен шактый вакыт кирәк булачак. Әмма кайбер заводлар, предприятиеләр җитештергән продукцияне чит илләр дә сатып ала башлады.

— Германиягә килгәндә, — диде Премьер-министр, — без нигездә нефть, нефть продуктлары һәм башка чимал хисабына товар алмашу турында сүз алып барабыз.

Мәдәният өлкәсендәге элемтәләрне киңәйтү мәсьәләсе дә каралды. Төрле ансамбльләр алмашу, журналистлар һәм менеджерларның бәлемен күтәрү, банк хезмәткәрләрен әзерләү, артистлар һәм галимнәрнең үз коллегалары белән аралашулары күздә тотыла. Быел апрель аенда бер төркем журналистларның Германиягә сәфәрен дә бу бәйләнешләрнең бер чагылышы дип карарга кирәк.

Матбугат конференциясендә Ф.Мөхәммәтшин Казан һәм Ганновер шәһәрләре арасында даими һава элемтәсе ачу мөмкинлеге, ике хөкүмәт бергәләп, танкерлар җитештерү һәм аларны киләчәктә куллану турындагы фикерләре белән уртаклашты.

Т.Гыйззәт үзе эшләгән театрга кайтты

Татар халкының бөек драматургы Таҗи Гыйззәтнең тууына 100 ел тулган көннәрдә аның истәлеген мәңгеләштерүгә багышланган күп кенә чаралар үткәрелә.

Чәршәмбе көнне шушы уңайдан үз заманында спектакльләре гөрләп барган К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасына язучының барельефы төшерелгән истәлекле такта кую тантанасы булды.

Тантананы Татарстан мәдәният министры урынбасары М.Низамиев ачып җибәрде. Аннары сүз Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р.Мөхәммәдиевкә бирелде. Ул Таҗи Гыйззәтнең татар театр сәнгатен үстерүдәге һәм халыкны рухи яктан тәрбияләү өлкәсендәге олы эшчәнлегенә югары бәя бирде.

Драматург турында үтемле һәм кайнар рәхмәт сүзләрен өлкән буын сәнгать әһелләреннән Р.Җиһаншина һәм Ш.Сарымсаков әйтте.

Тантанада драматургның улы, Таҗи Гыйззәтнең якты истәлеген, әдәби мирасын мәңгеләштерү юлында һаман йөрүче Казбек Гыйззәтуллин да катнашты һәм чыгыш ясады. Тантанада барельефны эшләгән рәссамнар Ә.Бакиров һәм Г.Зябливцев та бар иде.

Сәлисә ГӘРӘЕВА.

● Театр диварына куелган истәлекле такта.
● Тантанада катнашучылар.

Китапның үз музее була

Тиздән Татарстан Республикасының берләштерелгән дәүләт музеенда Китап музее ачыла. Хәзер монда әзерлек эшләре бара. Беренче экспонатлар инде музей хезмәткәрләре кулында. Болар — Хәсән Туфан, Сибгат Хәким кулъязмалары, казакъ шагыйре Абайның пуля тишкәләп бетергән шигырьләр җыентыгы...

Яңа музей 170 квадрат метр мәйдан биләячәк. Музей фондын туплауда Татарстан китап нәшрияты һәм «Мирас» китап нәшрияты ярдәм итәчәкләр булдылар.

Очрашу дәвам итә

Сара Садыйкова фонды һәм «Мәдәни җомга» газетасы редакциясе бөек композиторыбыз Сара Садыйковага багышланган очрашу-тапшыруны шушы айның 27 сентябрендә яңадан эшли башлавын хәбәр итә.

Кышкы вакытка күчәбез

24 сентябрьдә иртәнге 3 тә сәгатьне 1 сәгатькә артка күчерергә.

Урыс теле яклауга мохтаҗ

Русия Язучылар берлегенең Санкт-Петербург оешмасы урыс телен яклау (файдалану) турында закон кабул итү зарурлыгы мәсьәләсен пленум һәм җыелышларда берничә тапкыр күтәреп чыккан иде. Агымдагы елның башында шушы уңайдан РФ Дәүләт Думасына язучылар Мөрәҗәгате дә җибәрелде. Һәм, ниһаять, чаң сугуның үзенә күрә бер нәтиҗәсе — Думаның мәдәният, фән һәм югары мәктәп буенча комитеты өлегә тәкъдимне карады һәм яңа закон проектын эшләү юнәлешендә беренче адымнар ясады.

Иксез-чиксез Русиядә, башка «азчылык» телләрен йота барып, чын мәгънәсендә хакимлек итүче бөек урыс теле, күрәсез, ашыгыч рәвештә яклау-саклауга мохтаҗ. Ничә тапкыр бетүгә дучар ителгән, гасырлар буе кысылып яшәгән, закон тарафыннан тиешенчә кайгыртылмаган татар теленә инде ни кала?!

Русия гадел булырмы?

Җәмгыятьчелектә үзенчә абруй казанган Федераль-демократик хәрәкәт «Гадел Русия өчен» дигән сайлау берләшмәсе төзү турында белдерү белән чыкты. Мәгълүм булганча, өлегә хәрәкәттә утыздан артык иҗтимагый-сәяси оешма, иҗат берлекләре катнаша. Ә аның сәяси шурасында Андрей Дементьев, Римма Казакова, Владимир Дашкевич, Леонид Жуховицкий кебек күренекле әдәбият һәм сәнгать әһелләре, шулай ук фидакарь милләттәшебез галим Вил Мирзаянов, генерал Олег Калугин бар.

Федерализм принципларын «астан өскә» таба торгызу хәрәкәтнең максаты мышка ашыруны алга сөргән бу хәрәкәтнең максаты изге, әмма мондый оешмалар гына «явызлык империясе» булырак яманаты чыккан Русияне гаделлек юлына бастыра алырмы? Хәер, монысын вакыт күрсәтер.

Җомгадан — җомгага

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Төркиядә Төркия Президенты Сөләйман Дәмирәл Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев белән очрашты.

Татарстан Дәүләт Советының Русия — Канада парламент программасында тулы хокуклы катнашучы булуын раслаган беркетмәгә кул куелды.

Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачев Мәскәүдә Федерация Советы Рәисе урынбасары Р.Абдулатыйпов белән очрашып сөйләште.

АКШ илчелегенең сәяси бүлеге икенче секретаре Дженни Листон һәм АКШ Дәүләт департаментының Русия эшләре бүлеге хезмәткәре Джердж Биби Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ренат Харисов белән очрашты.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачев БМО Генераль Ассамблеясенең шушы оешмага 50 ел тулуга багышланган утырышына барасы Россия Федерациясенең рәсми делегациясе составына кертелде.

Балалар музыка мәктәпләре, мәдәният һәм сәнгать махсус урта мәктәпләре җитәкчеләренең республика киңәшмәсен ачканда Татарстан Республикасы мәдәният министры М.Таишев, чорыбыз авыр булуга карамастан, элек булган махсус уку йортларын саклап кына калмаенк, яңаларын да ача алдык, дип белдерде.

ТОО «Салех» ликвидируется.
ТОО «Совет» ликвидируется.

Алтынбаевка — халыкара бүләк

Чаллы шәһәренең мэры Рәфкать Алтынбаев «Бирмингем факелы» дигән абруйлы халыкара бүләккә лаек булды.

Бу бүләк аңа базар мөнәсәбәтләре нәтиҗәсендә килеп чыккан икътисади кыенлыклар алдында югалып калмаганы, социаль-икътисади процессларны җайга салуга үзеннән лаеклы өлеш керткәне өчен бирелә.

Лауреатны бүләкләү тантанасы шушы елның 26 октябрендә Бирмингем (АКШ) шәһәрендә була.

Муса «Иртәнге йолдыз»да җырлый

«Утренняя звезда» дигән мәшһүр телевизион тапшыруда катнашу өчен безнең бәләкәй җырчыбыз һәм композиторыбыз Муса Маликов Мәскәүгә китте.

Бу тапшыруның җюриенә Русиянең таләпчән «йолдызлары» керә. Аларга Муса дүрт җыр башкарырга җыена: «О, соле мио», «Вернись в Сорренто», шулай ук төрек көен һәм үзе язган «Сугыш кайтавазы» дигән җырны.

Шулай итеп, Казан дәүләт консерваториясе каршындагы махсус урта музыка мәктәбе укучысы Муса Маликов (педагог Нина Варшавскаяның вокал классы) композитор сыйфатында да чыгыш ясаячак.

Сүз уңаеннан шуны да әйтик: Муса ике яшеннән бирле җырлый, һәм ул — «Яңа исемнәр» программасы, Русия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыклары стипендиаты.

Тагын бер юбиляр

Казандагы сәнгать училищесы үзенең 100 еллык юбилеена әзерләнә.

Тантаналар 12 октябрьдә башлана. Юбилей программасына төрле конференцияләр, очрашулар, экскурсияләр үткәрү, Татарстан нәфис сәнгать музеенда «Казан сәнгать мәктәбе традицияләре» дигән күргәзмә ачу керә.

13 октябрьдә Татарстан Рәссамнар берлеге күргәзмә залында Казан сәнгать училищесы студентлары әсәрләреннән зур күргәзмә эшли башлый.

Яңа гимназия

Алабугада элекке 1 нче урта мәктәп базасында гуманитар юнәлештәге яңа гимназия ачылды.

Монда урыс теле һәм әдәбияты, урыс мәдәнияте нигезләре төп фәннәрдән булачак. Гимназиянең укытучылар коллективы тәҗрибәле педагоглардан тора.

Австрия белән Казан арасы якыная

Австриянең Мәскәүдәге илчелеге каршында эшләп килүче Сәүдә бюросы Татарстан Республикасының Сәүдә-промышленность палатасы һәм Тышкы икътисади элемтәләр министрлыгының Халыкара хезмәттәшлекне үстерү агентлыгы белән берлектә Австрия фирмалары белән ныклы элемтәләр булдыру буенча зур хәзерлек эшләре алып бара. Хәзерге вакытта Австриянең 33 банкы, предприятиесе, сәүдә компанияләре һ.б. фирмалары Татарстан белән хезмәттәшлек итәргә ризалык бирде. Якын көннәрдә Казанга әлеге предприятиеләрдән 50 вәкил килергә тиеш.

Көнбатыш һәм Татарстан эшкуарлары «Казан» милли мәдәни үзәгендә очрашачаклар. Анда һәр чит ил предприятиесенең үз стенды булачак. Кунаклар үзләренең партнерлары белән әнә шулар янында сөйләшүләр алып барырга тиешләр. Шунысын искәртеп узыйк: предприятиеләрнең һәркайсы аерым бер график буенча эшләячәк. Шуңа күрә Австриянең бер яисә берничә фирмасы вәкилләре белән очрашырга теләүче татар эшкуарларына оештыру комитеты белән алдан ук элемтәгә керү зарур. Бу комитетка Австрия ягыннан — Австрия илчелегенең Сәүдә Атташесы Кристиан Гессель, аның Сәүдә бюросы хезмәткәрләре Иоханнес Кель, Татьяна Суворова, Кристина Кофлер, Татарстан ягыннан — Сәүдә-промышленность палатасы генераль директоры Шамил Агеев, Татарстан Республикасының Тышкы икътисади элемтәләр министрлыгы каршындагы Халыкара хезмәттәшлекне үстерү агентлыгының халыкара элемтәләр үзәге җитәкчесе урынбасары Роман Шәфигуллин һәм Сәүдә-промышленность палатасы хезмәткәрләре Зөлфия Кадеева белән Руслан Сюбаев керде.

Чит ил кунаклары инде Алабуга, Чаллы, Чистай һәм Түбән Кама шәһәрләрендә булып, администрация һәм предприятиеләр җитәкчеләре белән очрашырга да өлгерделәр. Тиздән алар Әлмәт, Зеленодол, Лениногорск һәм Бөгелмә шәһәрләрендә дә булачаклар.

15 сентябрьдә әлеге оештыру комитеты әгъзалары Татарстан Сәүдә-промышленность палатасы бинасында матбугат конференциясе үткәрделәр.

Заһид МӘХМҮДИ.

● **Австриянең Мәскәүдәге илчелеге Сәүдә Атташесы Кристиан Гессель.**

Халык улына — халык ихтирамы

15 сентябрьдә республикабызның зыялылары, әдәбият сөючеләр классик драматургыбыз Таҗи Гыйззәтнең 100 еллыгын билгеләп үтте.

Тантаналар драматургның туган якларында — Әгерҗе районы Барҗы Омга авылында башланды. Казан кунаклары — Татарстан мәдәният министры урынбасары Илдус Тарханов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Мансур Шиһапов, галим Фоат Галимуллин, җырчылар Хәйдәр Бигичев һәм Зөһрә Сәхабиева, Таҗи Гыйззәтнең улы Казбек Гыйззәт авыл эшчәннәре, мәктәп укучылары белән очраштылар, драматургның һәйкәленә чәчәкләр куйдылар.

Авыл мәдәният йортында юбилей хөрмәтенә үткәрелгән концертта Хәйдәр Бигичев «Наёмщик» музыкаль драмасыннан һәм «Башмагым» музыкаль комедиясеннән арияләр башкарды, Зөһрә Сәхабиева исә халкыбызның борынгы көйләрен җырлады.

Таҗи Гыйззәтнең 100 еллыгына багышланган тантаналы юбилей кичәсе 26 сентябрьдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында була.

Экспедиция дәвам иттерелер

Самара шәһәренең 12 нче татар мәктәбе укучылары җәйге ял вакытында үз гомерләрендә беренче тапкыр археологик экспедициядә булдылар. Экспедициягә Самара өлкәсендә танылган археолог, тарих фәннәре кандидаты Риза Баһаветдинов җитәкчелек итте. Археологик казынулар бирелә юкка гына үткәрелмәде, чөнки бу якларда борын-борыннан төрки кабиләләр яшәгән. Эзләнүләр әлегә әллә ни зур нәтиҗәләр бирмәсә дә, укучылар күңелләрен төшермәделәр. Экспедиция киләсе җәйгә дә дәвам иттерәләчәк бит.

Шатлык «Чишмә»се

Ямал-Ненец милли округының төрле шәһәрләрендә Салехард шәһәрендә оештырылган татар мәдәнияте үзәгенең филиаллары уңышлы гына эшләп килә. Анда мәктәп укучылары да бик яратып йөри. Хәзер мәдәни үзәкнең «Чишмә» вокаль-инструменталь ансамбле һәм татар фольклор группасы яңа программа әзерли. Алар аны Салехард шәһәренең 400 еллыгына багышланган юбилей тантанасы вакытында күрсәтәчәк. Тантанада Татарстаннан да кунаклар булуы көтелә.

«Иманыбыз — Ислам» конкурсы

Ырынбурдагы җәмигъ мәчете каршында эшләп килүче мәдрәсә «Иманыбыз — Ислам» дигән темага конкурс игълан итте. Иң яхшы дип табылган язмалар Ырынбурда чыга торган «Яңа вакыт» газетендә дөнья күрәчәк.

Конкурста Ислам динен хөрмәт иткән татарстанлылар да катнаша ала. Җиңүчеләрне кыйммәтле бүләкләр көтә.

Язмаларны түбәндәге адрес белән җибәрергә мөмкин:

460000, г.Оренбург, а/я 116, редакция газеты «Яңа вакыт».

Хәтер көне — 95

Татар милли оешмаларының координацион шурасы утырышында 15 октябрьдә «Хәтер көне»н уздыру мәсьәләсе каралды. Карар ителгәнчә, Матәм җыены шул көнне сәгать 10да Ирек мәйданында башланып, Сөембикә манарасы янында 1552 елда шәһит киткән бабаларыбыз рухына намаз уку һәм алар истәлегенә торгызылачак һәйкәл урынына чәчәкләр кую белән тәмамланачак. Шулай ук башкалабызда, җөмһүриятебездә һәм татар халкы яшәгән башка төбәкләрдә «түгәрәк өстәл»ләр, конференцияләр, матәм җыеннары уздыру күздә тотыла.

3 нче һәм 4 нче битләрдә «Татар-Информ», авторларыбыз һәм башка чыганакларның хәбәрләре файдаланылды.

Элекке СССР территориясендә иң борынгы этник цивилизацияләрнен берсен тудыы һәм яшәтүче буларак, татар халтабигый, бик бай һәм күптөрле ска ия. Әмма, кызганыч ки, сәяси, огик һәм башка рухтагы сәбәпркасында, без озак вакытлар, бигта совет чорында, әлеге хәзинәләрбелу һәм кабат торгызу мөмкинлен нигездә мәхрүм ителеп килдек ын урынына гасырлар дәвамында быбызның үткәне хакында аны бараптып күрсәтә торган ялган мәматлар таратылды, татарлар бехәтта балаларны куркыта башлар Бу хал безнен халыкны ахыр цивилизацияле дөнья тарихынсызып ташларга мөмкин иде Халбуки, татар иленең географик тарихи әһәмиятле урында урнаүзе инде баштан ук безнен халыккүп яклы һәм бай эчтәлекле торбелән яшәвенә нигез булган Эш татарлар бик борынгыдан геоәһәмиятле территориядә Идел белән Чулман буйларында, шушы елгалардан үткән сәүдә аша Шәрык белән Көнбатыш гәятләре очрашкан урында яшәр Шуңлыктан алар әлеге цивилиләрнен гуманистик тәҗрибәсен тәҗрибәсе, авыл хуҗалыгы һәм сәүдә, һөнәрчелек һәм промышленность, табигать һәм техник фәннәр, медицина, иҗтимагый-сәяси һәм фәлсәфи фикер тарихларын һәм мирасларын өйрәнү буенча эш башланды Дөрес, бу эшләр кайвакыт әле ничектер стихияле төстә, аерым энтузиастларның башлап йөрүе һәм тырышлыгы белән генә алып барыла Шуңлыктан хәзер безнен алга кичекмәстән халкыбызның күпгасырлык һәм гаять күптөрле мирасын өйрәнүне, торгызуны чын фәнни нигезгә кую бурычы баса Моның өчен беренче чиратта әлеге байлыкны җыю, өйрәнү, саклау һәм пропагандалау буенча дәүләт программасын һәм аның фәнни концепциясен эшләргә кирәк Бу программада музей эшенә дә лаеклы урын бирелергә тиеш.

Республикабызның үзәк музее үзенен 100 еллык юбилеена халыкның тарихи хәтерен саклау һәм үстерү кебек гаять мөһим эштә бай гына тәҗрибә туплап килде Әйтергә кирәк, бу йөзьеллык бер үк вакытта татар милли музей эше тарихында да билгеле бер этапны тәшкил итә Кызганыч, бу тарих әле бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән Хәлбуки, ул үзенен тамырлары белән Бөек Болгар, музейлары, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре музейлары һ.б. бар Шулай да халкыбыз тарихы һәм мирасының бөтен өлкәләре дә музейларда чагылыш таба дип әйтә алмыйбыз әле Мисал өчен халык һөнәрчелеге һәм этнография музейларын, ачык һавадагы музейлар, төрле фәннәр һәм белемнәр тарихы буенча музейлар булдыруга әле аз игътибар бирелә

Татарстан дәүләт музеенда һәм аның филиалларында халкыбызның күпгасырлык әдәби мирасы зур гына урын били Һәм бу бер дә очраклы хәл түгел, мондый байлык әдәбиятка күптәнге хөрмәтебезнең һәм бу мирасны саклау турында кайгыртуыбызның бер чагылышы, нәтиҗәсе булып тора Аерым әдипләребезнең музейларын булдыруга игътибар ителә Төгәлрәк әйтсәк, шәһәрләрдә һәм авылларда К Насыйри, Г Исхакый, Р Фәхретдинов, Г Тукай, Ш Камал, М Фәйзи, Х Туфан, М Җәлил, С Хәким, Ш Маннур, Г Кашапов-Үзиле музейлары оештырылган

Татар халкы әдәби мирасын җыю, саклау һәм пропагандалау буенча республикабыз музей хезмәткәрләренең зур гына эш башкаруларын искә алу белән бергә, әдәбиятыбыз тарихын җирләргә таралган мирасын җыю, саклау һәм пропагандалау эшенә дикъкатьне көчәйтү кирәклеген әйтәсе килә Бу яктан бигрәк тә Г Исхакый мирасы мәсьәләсе үзгә игътибарга лаек Бу мираска аерым басым ясауның сәбәбе шунда ул XX гасыр татар әдәбиятын гына түгел, гомумән, бөтен тарихыбыз һәм мәдәниятебезне өйрәнүдә принципиаль әһәмияткә ия, бу эштә үзенә бер ачкыч булып тора Шундый зур кыйммәтле бу мирасны җыю һәм саклау эшенә хәзергә дәүләти караш булмау аркасында аның кабат төрле җирләргә таралуы ихтимал Шул нигездә бу мирасның янә юкка чыгуыннан котылу өчен аны җыю, саклау һәм пропагандалау буенча үзәк бер дәүләт оешмасын булдырырга кирәк Бәлки ул Г Исхакый музее рәвешендә булыр Гәрчә әдипнең туган җирендә — Чистай районының Яуширмә авылында аның музеен төзү буенча фидакарь эш эшләнсә дә, ул, төрле сәбәпләр аркасында, әлеге үзәк вазифасын башкара алмый Мондый үзәк Казанда оештырылырга тиеш Ә аның булмавы иң башлап Г Исхакый мирасын җыю эшен кысынлаштыра Мәсәлән, Төркиядә яшәүче һәм әдипнең андагы мирасы һәм шәхси әйберләре турында кайгыртучы милләттәшләребез бу байлыкны бездә

Флүн МУСИН,
академик

Мирасыбызны кадерле беләбезме?

традицияләрен үзләштергәннәр, н кешелек яшәешенен төрле-төркаләрендә актив күрсәткәннәр р барысы үз чирагында безнең хаз ике дөньяны, аларның тәҗрибәләр традицияләрен очраштыручы ара бәйләнешкә кертүче вазифайкләгән кебек. Нәтиҗәдә аның бәсе һәм казанышлары башка ларга да үтеп кергән. Бериш очрда – табигый-ирекле рәвештә, ләрендә – мәҗбүр ителеп. Менә сал. Мәрхүм профессор А Халиләп чыгарганча, урыс тарихы 500 дән артык атаклы кешеләр лары буенча татар булганнар н тө тулылыкка дәгъва итә ал бу исемлеккә болгар-татар зылавының аеруча күренекле вә кертелгән. Татар халкының интеллектуаль җегәрен үзләрендә н бу кешеләр яки нәселләр үз лары һәм сәләтләре белән халкыннан аерылып башкаларга итәргә мәҗбүр булганнар. Ачыәйтсәк, көчләп чукындырылу нәдә алар дәүләт җитәкчеләре, чиннар, фән, мәдәният, сәнгать ләре сыйфатында урыс дәүләтхәрби эшен, икътисадын, фәмәдәниятен үстерүгә үзләреннән өлеш керткәннәр һәм шуның урыс тарихында танылганнар. яктан, Алтын Урда заманнаук һәм бигрәк тә Казан ханҗимерелгәннән соң, татар зыяУрта Азиягә барып чыгып, анң кардәш халыкларның икътисәүдәсен, фәнен, мәдәниятен графен булдыруда һәм үстерүм роль уйнаганнар. Әйтергә ңгы вакытта татарларның моләге Көнбатыш галимнәре игътибарын җәлеп итә икән. өчен күптән түгел Алматы шә Абай Кунанбаевның 150 еллыгышлап үткәрелгән халыкара онференциядә ясаган докладла Көнбатыш галимнәре төрки хаың иҗтимагый-мәдәни үсешеларның зур өлеш кертүләрен шлап күрсәттеләр. Моның өстем вакытта без туган җирләрен китәргә мәҗбүр булган мөһаиләттәшләребезнең эшчән бусәләтләре белән ерак чит ил татар исемен югары тотуланда торган саен күбрәк беләләбез.

лар дәвамында бөтен дөньяга н татарларның менә шундый күптөрле мирасы озак вакытекләр күләгәдә калдырылды нылуга дучар ителде. Нәтиҗәр халкы үткәндә кешелек яшәбик аз санлы өлкәләрендә генә һәм үзен күрсәтә алган икән ер туа иде. Ачыграк әйтсәк, ң, халык иҗаты, әдәбият һәм тенең тагын кайбер өлкәләренрасы гына азмы-күпме өйрәнеменә, ниһаять, соңгы вакытолгар-татар дәүләтчелеге, хәрархитектурасы һәм шәһәр төзү Казан ханлыгы һәм башка татар ханлыклары чорларына китә Бездә музей эшенен башлангыч формалары булып хан сарайларында, болгар-татар аксөякләре йортларында, галимнәр, әдипләр яки муллаларның өйләрендә яшәгән китапханә-музейлар торгандыр, ахры Мондый китапханәләрдә төрле илләрдән җыелган, икътисад, фән һәм мәдәниятнең төрле өлкәләренә караган китаплар белән бергә, күпсанлы кульязмалар да, һәртөрле тарихи документлар да сакланган. Гомумән, китап, кульязмалар җыю бездә борынгыдан мәртәбәле һәм абруйлы шөгыль булып торган, рухи ихтыяҗга әверелгән.

Менә шул сәбәпле, Казан ханлыгын яулап алганнан соң, Русиядә татарны этнос һәм милләт буларак көчсезләндерү, юкка чыгару максатында аның интеллектуаль көчләрен, шул исәптән рухи азыгы булган китабын һәм гомумән язма ядкарьләрен юк итүгә күп көч куелды. Татарның күп кенә китапханәләре, беренче нәүбәттә иң атаклылары яндырылды яки аларның кыйммәтле хәзинәләре талап читкә алып кителде. Нәтиҗәдә Болгар һәм Казан ханлыгы чоры мәдәниятендә бик күп «ак тап»лар хасил булды. Китапсыз яшәүнең үзен һәлакәткә китерәчәген яхшы аңлаган безнең халык, табигый, шул ук вакытта әлеге байлыгының күпмедер өлешен саклап калу чараларын күргән һәм шуның аркасында үзен дә саклый алган.

Татарда музей эшенең тарихы шулай бик еракларга китүе, бу өлкәдә бай тәҗрибә тупланулы, икенче яктан, шушы тарихны саклаучы һәм дәвам итүче үзәк милли музейны булдыруны яки мондый вазифаны хәзерге Берләштерелгән дәүләт музеена йөкләүне, ягъни аны Татарстан Республикасының Милли музее дип игълан итүне сорый. Әйтергә кирәк, күп кенә республикаларда, гәрчә аларда музей эшендә татардагыдай бай тарих булмаса да, үзәк милли музейларны инде булдырганнар. Чөнки алар үз халыкларының, республикаларының абруй-дәрәҗәсен билгеләүдә һәм күтәрүдә Милли музей, Милли академия, Милли университет, Милли китапханә кебек оешмалар булуның роле зур икәнен аңлаганнар, күрәсең. Язучы Разил Вәлиев кебек энтузиастларның тырышлыгы белән бездә дә элекке В.И.Ленин исемендәге китапханә Татарстан Милли китапханәсе итеп үзгәртелде. Бу өлкәдә чираттагы эшебез булып Берләштерелгән дәүләт музеен Татарстан Милли музее итеп раслау торсын иде. Татар милли университетын дәүләт карамагына алу да, ниһаять, хәл ителсен иде инде.

100 еллыгын билгеләп үткән Татарстан дәүләт музее күппрофильле булуы, татар һәм республикадагы башка халыклар тарихы һәм мирасының төрле тармакларын колачларга омтылуы белән аерылып тора. Аның республикадагы күпсанлы филиаллары арасында туган якны өйрәнү музейлары, аерым шәһәрләр, районнар һәм авыллар һәм мирасын музейларда яктыртуның гомум торышы хәзерге яңа таләпләргә һәм ихтыяҗларга җавап биреп бетерә алмавын да әйтергә кирәк Бигрәк тә бу өлкәдә музейлар төзү яки экспозицияләр оештыруның бербөтен фәнни системасын һәм концепциясен эшләү кирәклеге сизелә Шундый эш башкарылмау аркасында, аерым әдипләрнең музейлары урыннарда ничектер үзбашка, стихияле төсторәк оештырыла һәм алар кайвакыт фәнни таләпләргә җавап бирә алмыйлар

Моннан тыш, хәзер гамәлдәге әдәби музейларның концепцияләрен һәм экспозицияләрен яңарту кирәклеге дә сизелә Чөнки алар еш кына элеккерәк елларда һәм шул вакыттагы мәгълүм идеологик карашлар һәм таләпләр рухында эшләнгәннәр Хәлбуки, соңгы вакытта идеология өлкәсендә хасил булган тирән үзгәрешләр әдәбиятлар тарихын яктырту эшен җитди яңартуны сорыйлар Һәм хәзер элекке СССРның бөтен республикаларында милли әдәбиятлар тарихын өр-яңадан өйрәнү башланды Мондый эшкә беренчеләрдән булып урыс әдәбиятчылары тотынды. Алар хәзер урыс әдәбияты тарихын, бигрәк тә аның XX йөзен бөтенләй башка позицияләрдән торып өйрәнәләр. Аларның тикшеренүләрендә туган әдәбиятларын урыс милли идеясен чагылдыручы итеп, ягъни милли әдәбият итеп өйрәнүгә басым ясала. Татар әдәбияты тарихын шушы рухта һәм яссылыкта өйрәнү эше бездә дә башланды. Ачыграк әйтсәк, татар әдәбият фәнендә төп академик үзәк булган оешмада — Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият бүлеге бүлегендә хәзер XX гасыр татар әдәбияты тарихын яңартып язу эше алып барыла. Мондый эшкә безне хәзерге иҗтимагый-идеологик ситуация генә түгел, бәлки әдәбият тарихына совет чорында онытылуга дучар ителгән әдипләрне яки әдәби фактларны кире кайтару да этәрә. Мисал өчен Г.Исхакый, С.Максуди, Й.Акчура, Рәшит Казый (Габдерәшит Ибраһимов), С.Җәлал һәм В.Җәлал мирасын торгызу яки Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ш.Бабич, Һ.Такташ, Х.Туфан, Г.Рәхим, Ф.Кәрим һәм башкаларның мирасын тулырак күрсәтү — болар үзләре үк XX гасыр татар әдәбиятын өйрәнүгә зур гына яңалыклар алып киләләр. Шундый ук яңарту эше теге яки бу күләмдә әдәбиятыбыз тарихының элгәрерәк чорларын яктыртканда да сорала.

Аңлашыла ки, әдәбият тарихын шулай яңартып өйрәнү һәм бәяләү хәрәкәте музей эшен дә читләтеп үтә алмый. Биредә беренче чиратта әдәбият тарихындагы мәгълүм «билгесезлек»ләрне бетерү кирәклеге сизелә. Музей экспозицияләрендә, мисал өчен, Г.Исхакый, С.Максуди, Й.Акчура кебек шәхесләр лаеклы урын алырга тиеш. Сүз уңаенда мондый мәдәният эшлеклеләренең төрле кая һәм кемгә бирергә белмиләр Мәсьәләгә бик җаваплы карап, алар Г.Исхакый мирасының аерым кулларга таралып әрәм-шәрәм ителүеннән шикләнәләр, аның дәүләт карамагында булуын, халык байлыгына әверелүен телиләр Шуңлыктан XX гасыр татар әдәбияты һәм мәдәниятенең бөек эшлеклесе Г Исхакый мирасын җыю, саклау һәм пропагандалау эшен дәүләти дәрәҗәдә алып баруны сорап, Татарстан Президентына һәм хөкүмәтенә мөрәҗәгать итәсе килә Хәзергә исә бу олы шәхес мисалында кабат бер мәртәбә күңелсез хакыйкатьне -- бөек кешеләребезне тиешенчә хөрмәт итә белмәвебезне танырга туры килә Бу эштә безгә башка халыклардан үрнәк алырга кирәктер Белгәнебезчә, күптән түгел Казакъстанда Абай Кунанбаевның 150 еллыгы бик зурлап билгеләп үтелде Эш шунда, анда әлеге юбилейны үткәрү дәүләткүләм әһәмиятле бурыч итеп каралган, һәм ул Казакъстан Президентының турыдан-туры җитәкчелегендә башкарылган. Чөнки бу ил хакимияте мондый чараны үткәрүнең мәдәни яңгырашлы гына булмавын яхшы аңлаган. Абай юбилее бөтен казакъ дәүләтенә зур иҗтимагый-сәяси табыш китерде. Тантаналы утырышта турыдан-туры бу юбилей яшь Казакъстан дәүләтен асылда дөнья җәмәгатьчелегенә тәкъдир итү (презентацияләү) дип әйтелде.

Безнең дә Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Мәрҗани, Исхакый, Фәхретдинов, Тукай кебек бөек шәхесләребезне шундый югары дәрәҗәдә хөрмәтләү бер үк вакытта Татарстаныбызны зурлауның, аны дөньяга танытуның үтемле формасы булыр иде. Бу мәсьәләдә музей эше дә мөһим роль уйнарга тиеш. Абайның исемен һәм хәтерен мәңгеләштерүдә дә нәкъ менә музей чараларына зур игътибар бирелгән. Аерым алганда, юбилейга шагыйрьнең туган төбәгендә – Семипалатинск шәһәрендә таш белән мәрмәрдән тарихи-мәдәни һәм әдәби-мемориаль музеенең яңа мәһабәт комплексын, Җидебай аймагында Абай белән Шәкәримнең тагын да мәһабәтрәк мавзолейлары мемориалын төзегәннәр. Безнең исә Кырлайда Тукай музееның тыйнак кына агач бинасын булдырудан уза алганыбыз юк әле.

Кыскасы, безгә дә, бигрәк тә ил җитәкчелегенә халык мирасын, аның иң күренекле вәкилләрен зурлау бер үк вакытта шул халыкны, аның дәүләтен хөрмәтләү, аны киң дөньяга чыгару икәнен аңлап эш итәсе, мондый мәсьәләләрне хәл итүгә көчне кызганмыйсы иде. Минем ышануымча, Абай юбилеенда катнашкан Президентыбыз Минтимер Шәймиев тә шушы хакыйкатьне тагын да тирәнрәк төшенеп кайтты. Хәзер шуны аңлауның аерым гамәлләрдә чагылуын телисе кала.

АВЫЛЫ БАРНЫҢ КАВЕМЕ БАР

Әхәт ГАФФАР

СӘЕР КЕШЕ

Чулман җиле миңа һәрчак тансык. Быелгы чилләдә Казаннан гел үземнең туган якларым күгең күзәттем. Ни хәл анда? Болытлар кучкыллан-мыймы? Суга сусап хәлсезләнгән игеннәр көрнәкләнмиме? Җиләк-җимеш, яшелчә-мазар көй-миме? Үлән ничек тә, терлек-туар ач түгелме? Иң мөһиме -- халык нишли? Җитәкчеләр жас чыккан саен әйткәнчә, күңеле шулай көр микәнни? Ә жаны сай судагы эре балык нигә тыпырчынмыймы?

Ул арада түзмим, автобуска утырам да сәфәргә чыгып китәм. Күрәм, сөйләшәм, кешеләрнең әй-ткәннәрен анлыйм, тел очындагы сүзләрен, зиһеннәрендәге уйларын тоям.

Ябага коеп кайтуның тәме бар инде аның. Хикмәт күктән яумый ул. Судан балык тотып, тияккә те-згәндәй, аны халык жаны дәрья-сыннан эзләп табасың да зиһенеңә иңдерәсең.

Шулай бер заманны юл өстен-дәге Имәнкискә авылына төшеп калдым. Бу авыл -- бик борын-гылардан. Моннан ике мең ел әү-вәлтен үк биредә Ананьев культ-урасына караган бер кавем көн кү-ргән. Аннары кая китеп, кая югал-ганнардыр тагын. Күрмәдем, бел-мим. Тарихының безгә караган өлеше болгар кабиләләре килеп төпләнгәч башлана инде. Теге Явыз Иван чиргүе килеп баскач, бу авылны Чулман буеннан 40 чак-рым эчкәрә кумаганнар. Бактың исә, аларга хәтле үк монда бер урыс килеп төпләнгән дә, тегеләр-не ипи-тоз белән каршы алырга чыккан икән. Шуннан, авылны туз-дырмыйча, халыкны рәнҗетмичә, олы юлдан ары узганнар. Ә авыл мулласы барыбер әйткән, бу урыс гаиләсе ике йорт-курадан артык үрчемәсен, дигән. Ишәеп караган-нар каравын, тик өченче хуҗалык-ка башка чыгу белән янып, көл-ләре күккә очкан. Болар, татарга тимерчелек эше тиелгәнгә күрә, тимерчелек белән көн күргәннәр. Шулар токымыннан берәү әле дә тимерче, татарчасы нәкъ безнеке кебек үк.

Монда мул тормышлы тырыш кешеләр яши. «Маяк» дигән күмәк хуҗалыклары да таза, дәүләтле. Игенне каерып алалар, терлек-ту-арның телен беләләр. Җитмәсә, җитәкчеләренннән дә уңалар тагын. Инде менә идарә рәисе булып Риф-кать Аббазов эшләргә керешкән. Килеш-килбәте дә мач килгән, са-лкын канлы, сабыр, сөйләгәне төп-ле. Әйтми калдырсак 'яхшы түгел инде. Яңа кеше. Белмәгәннәр бе-леп торсыннар диюем. Ул Кама Тамагындагы совхозның баш аг-рономы буларак, игенчелектә азау тешен ярган, XXII партсъезд исе-мендәге колхозда партия оешмасы секретаре булып тел чарлаган, К.Маркс исемендәге колхозда рә-ислек мәктәбе узган. Шуңа күрә эреләнеп кыланмый, ярарга тыры-шмый, ясалма елмаймый, колми.

— Кая, карап карыйк инде, — дигәч, басу юлларында бүз ту-зан кубарып, дөнья кадәр җир урап кайттык. Рифкать үз хәстәрен күрде, мин үз жаем белән йөрдем. Бер-беребез эшенә тыкшынмадык. Мирәтәк дигән керәшен, урыс, та-тар авылындагы бригадаларның җитәкчеләре -- алтын куллы, егет-ләрчә йөрәкле Роза Малышева, алдынгы механизатор һәм шофер-лар Николай Порфирьев, Леонид белән Алексей Касимовлар, Габде-лхәй Фәхриев, Наил Шакиров, Ри-нат Хәсәнов, Раил Фәттахов, Вла-димир Батумов калдык гектарлар-га чыгып китәргә җыена иде. Тех-никаларын әллә ниш.тәләр шун-да. Атларын Сабан туена чабышка әзерлиләрмени.

Шуннан соң ындыр табагына су-гылдым. Тиз тотарга ниятләгән идем дә -- кая ул! Мөдирләре Зин-нәтулла Гатауллин белән аны-мо-ны сөйләшеп, кәгаземә үз эшләрен жиренә җиткереп эшләүчеләрнең исемнәрен теркәп куйдым. Фәүзия Шакирова, Тәскирә Хәсәнжанова, Таһирә Гарипова, Нурия Вәлиәх-мәтова, шофер Рәшит Сәйфул-лин...

— Әйдәле, тагын бер кешебез белән таныш, - диде Зиннәтулла.

Кем соң ул?

-- Күрерсең.

Ярыйсы гына зур, вагонга тар-тым тимер бер «өй»гә кердек. Эче тулы пөхтә җиһаз, күрсәткечләр угы селкенә, утлар җемелди. Бөтен эшен компьютерлар җайлый. Ху-жасы түрдәге караватта черем итә икән. Уянды, күреште. Чал чәчле, куе сакал-мыеклы урыс кешесе — Альберт Владимирович Демен-тьев. Танышкач, ул мине калай өс-ле өстәлгә утыртты, бер чокыр сөт салып бирде.

-- Эч, -- диде. — Кайнатылган сөт.

Бераз әчи төшсә дә, эчтем инде.

Бу кеше Казанныкы булып чык-ты. Җәй саен шулай хуҗалыкта эшләп китә икән. Әлеге «калан-ча»ны да үзе корган, көйләгән. Хә-зер үз баласыдай тәрбияләп, сак-лап тота. Әллә никадәр үз төзәт-мәләрен, җайланмаларын кертеп бетергән.

Дөресен әйтим, мин аны үз уры-нын тапмаган сукбайрак, шабаш-чырак бер адәм диебрәк уйлаган идем. Кем, нинди кеше икәнен бел-гәч исә, үземчә «сәер кеше» дип атадым. Бактың исә, алтмыш яше җитәренә ике генә ел калган Аль-берт Дементьев заманында Казан-дагы авиация институтын тәмам-лаган, 60 нчы еллар уртасы... техник фәннәр кандидаты ди... гыйльми дәрәжә алган, 18 ел бу... Казандагы исәпләү техника... фәнни-тикшеренү институтын... ул ябылгач, авиация техника... фәнни-тикшеренү институтын... эшләгән икән. Хәзер «Вакуу... маш»та оешкан агропромның г... льми киңәшчесе. Моның житә... легендә республикабыздагы ... лык киптергечләренең 75 процен... проектлаштырылган.

-- Алайса ничек монда -- ... седә, тузанда йөрисең соң, А... берт Владимирович? — дип кы... ксындым.

Гади генә итеп:

-- Ияләшкән, -- диде ...
-- Авылны, менә шулай эшлә... яратам. Шәһәрдән качып тор... рәхәт ул

Бу «сәер кеше» 27 ел буена ... лык Бистәсе районындагы КЗС... рның 95 процентын куеп чык... «Мактау билгесе» ордены, бе... тикмәгә бүләкләмәгәннәрдер ... де.

Ул үзе чегәннәр кавеме... икән Бабасы иген игү хикмә... бик яхшы белгән. «Вакыт җитм... әле, чәчмәбез», -- дисә, чәчмә... нәр. Моның сигез баласы бул... шуларның бишесе Ленинградта... югары технология институтын ... мамлаган Шул бабасы балалар... «урыс» дип яздырган инде.

Альберт Владимирович был... әлеге венор корылмасында 1... тонна орлык әзерләгән, 500-... тонна фураж чыгарган. Быел ... үлегенә 80 тонна биргән. Ә КЗС... рныкы -- 2,5 тонна гына. Ул ... орлык чыгаруны кирәгрәк са... Чөнки аның тоннасы 3 тонна ... ражга тора. Хуҗалык рәисе Ри... кать Аббазов аның хакында кы... гына итеп:

-- Алтын кеше ул! -- диде.

Шулайдыр шул. Әнә, алтын ... ясе торырлык рапс орлыгын да ... стартып бетергән. Бер тонн... миллион сум! Туклыклы ма... малы. Ярдәмчеләре Рәсим Сиб... туллин белән Наил Гарипов та ... нише -- эш дип, җан атып йөри...

Әйе, җир Альберт Владими... вич Дементьев кебек «сәер» ке... ләрне үз итә, ярата, шундыйла... таяна да инде. Мондый зат... -- җөмһүриятебезнең иң зур б... лыгы ул.

Лаеш райо...
Имәнкискә авы...

ҖИДЕ БУЫН ЯДКАРЕ

Сатышның данлы мәдрәсәсе

Байлар Сабасына җитәргә 10 чак-рым кала Сатыш дигән борынгы авыл бар. Ул тирә-якта үзенең мәдрәсәсе бе-лән дан тоткан. Аның бер катлы кир-печ бинасы XIX~XX гасырлар чиген-дә төзелгән. Монда Татарстан халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең әтисе, булачак имам-хатип Сөнгатулла аб-зый да белем алган.

Мөхәммәт ага Мәһдиевнең 1991 ел-да «Саба таңнары» гәзитенә җибәргән «Без кемнәр?» дигән язмасында мон-дый юллар бар иде: «Саба районында Сатыш мәдрәсәсе булган. Бу мәдрәсә заманында Арча, Тәкәнеш, Кукмара, Мамадыш, Балык Бистәсе яклары өчен шәм-лампа ролен үтәгән. Монда гасыр башында шагыйрь Миргазиз Укмасый (Миргазиз Каюм улы Зәбиров, 1884-1946), язучы һәм әдәбият белгече Мөхәммәт Гали (Мөхәммәт Вәлиулла улы Галиев (1893-1952) укыган. Болар әле мин белгәннәре генә. Бу мәдрәсәдә белем алган шәкертләр камил рәвештә гарәп телен белеп чыкканнар...»

Әле быел гына дөнья күргән «Татар халкының һәйкәлләре» дигән китапта (авторлары Р.Салихов, Р.Хәйретди-нов) анда җитәкчелек иткән руханилар Мөбарәкша Яруллин (1894 елның сен-тябреннән имам), Мөхәммәт Мөхәм-мәтвәлиев (икенче мулла, указы 1872 елның 12 мартыннан) һәм аның улы Габдерахман Мөхәммәтов (1903 елның 26 августыннан имам-хатип) исемнәре китерелә. XX гасыр башында биредә 300ләп шәкерт сабак алган. Бу тарихи бина, рәсемдә күргәнегезчә, бүген дә исән-сау. Хәзер анда реставрация эш-ләре бара. Ремонт тәмамлангач, бире-дә музей һәм авыл китапханәсе була-чак.

Мәдрәсәдән инеш аркылы гына мә-чет бинасы булган. Ул хәзер дә авыл-ның мәдәният йорты итеп файдаланы-ла. Авыл халкы, хуҗалык җитәкчеләре тырышлыгы белән мәчетнең яңасы да төзелде. Озак та үтмәс, мәдрәсәле бо-рынгы авылның яңа мәчете манара-сыннан азан тавышы таралып, бу... бәккә кабат иман нуры иңәр.

Тәлгат НӘҖМИ...
«Саба таңнары» гәзите мөхәрр...

Әкрам ШӘФИГУЛЛ...
фотол...



● Сатыш мәдрәсәсе.



● Авылның яңа мәче...

Рухым

Бирешмәсен, диләр, дус-ишләрем,
Багып карыйм күзгә
Карап торырга бит гомер бакый
Үзем белгән йөз генә!
Таң атулар, кояш чыгыш шул ук,
Әүвәлгечә бер төсле,
Үзгәрмәгән офык, тау битләре
Уч төбендә йөртешле!
Эреп китәм ихлас елмаюга,
Сары майдыр һәр шатлык,
Таң кошлары сайрауларын йөрим
Язларыма охшатып.
Бөгеләсен, диләр, күзгә карап,
Арттыралар, күрәсең.
Тел — сөяксез, дуслар өчен кайчак
Эт булып та өрәсең.
Җыерчык ни!
Япь-яшь күңелемә,
Мөлдерәмә тулган җыр
Әле яшәгән дә кебек түгел
Ходай шулай кылгандыр.
Асыллар да җәсәдләре белә
Тормыш кырын ашлаган
Тулгый сабыр җан авазым,
Кимме,
Артыкмы мин башкадан!
Булды рух сынган мәл,
Сулаган чак
Булды күкрәк тутырып
Яндым-көйдем,
Сүнгән бер учакта
Җан тергездем, ут өреп

Яшәдемме?

Фани дөнья! Башкалардан
Ким яраттың кай ягымны?
Күкрәгемдә сынган рухны
Сынар өчен аядыңмы?
Тилмерттең син сыныкка да.
Таннар килә чымыр-чымыр
Сәбәпләрне сәбәпләргә
Ялгый-ялгый үтте гомер.
Имчәк бала сөт күрмәскә
Мәхрүм иттең юлдашымнан
Күтәралмам кебек хәзер,
Әле дә ничек тырмашылган!
Даһи ясап, бер-бер артлы
Баш идерден җаһилләргә
Күңел өчен аз гына да
Исәбең юк бәхилләргә
Өмет чаткысына гикле
Тартып алдың үчеккәндәй,
Бер-бер хис кузгатса илһам,
Үткәрмәдең ишектән дә!
Күрсәтмәсен Хак Тәгалә
Безнең баштан кичергәнне,
Беркемгә дә бирмәсен, әй,
Җан өшеткеч моңдый гамьне
Корыч куллар «койган» гомер
Таралды да китте бер көн
Яшәдемме? — Аңга килми,
Әвәлимдер тоткан бүркем...

Җәза һәм дәва

Җәмит Рәхимовка

Мукшы тәмәкесе төтененә
Уралгандай авыр копчәге,
Сутә Хәтер тау-тау йомгакларын,
Җиңеләйми уйлар һич әле
Шаулый Хәтер,
Элеватормыни,
Үтеп керә жиде катламга
Шул җәза бар —
Котылгысыз җәза! —
Үткәннәргә кире кайтканга
Фатихасын үзе биргән тарих
Гел яшерергә өнсез түгел лә!
Алып батыр рухлы йөрәкләләр
Арбасына аның җигелә

... Ыңгыраша чокыр-чакыр юллар,
Каберлекләр өстен таш баскан,
Хәрабәгә әверелгән өмет,
Чуер ташка
Чыңга ашмастан
Тоти «Черепанов паровозы»,
Аның саен Хәтер янара,
Манаралар калка офыкларда,
Кай тарафта рухи манара?
Күп табындык корыч сөңгеләргә,
Хәтер диварына ишек ач.
Иман манарасын торгызырга
Бәргәләнә Кисекбаш
Милләт авыру,
Син табибы аның,
Күпмегәчә барыр бу кизү?
Батыршалар батырлыгын сорый
Рухи Болгарлыкны тергезү
Изге дәва да ул,

Илдар ӘХСӘНОВ

Дәгъва да ул,
Авырттыра җанны кайтавазы
Иблис яный безгә һәр адымда.
Кулда — каләм,
Билгә балтан ас!

* * *

Газиз әнкәсе ганымас,
Чынлыкны шундый шомарттык.
Гөнаһ җыйганчы өстенә,
Күкләргә ашканың артык

Йөзен ерт ялган гөмбәзнең,
Ялтыраг булат хәнҗәрең,
Коерыгын кыссын явыз көч
Тапмасмы шунда әҗәлен!

Әллә сабырлык мәгъкульме,
Түзәсең бардыр бик азга
Сөяген белән гиреңне
Аудар син, илтеп базарга!

Күләгә артыннан куып,
Кылгансың гөзәлмәс хата.
Үз жаның йоклаган кебек
Хәнҗәрең кынында ята

Иләһи кодрәт

Син миңа — иртәнге кояшны
Инендә күтәргән гау кебек,
Тик синең назларың гартканга
Гомерем тирәгә сау кебек

Тик синең хозурга буй җитмәс,
Ничекләр үземне яндырмыйм,
Иләһи кодрәтең белән лә
Дөньяга тансык бер җандыр мин

Син миңа иртәнге кояшны
Гөл итеп күтәргән таг гүя
Син үзең — күңелем түрендә
Таң нуры, иң гүзәл гакыя

Сискәнер ташлар

Сайраша кошлар талпынып,
Урынында түгел йөрәк,
Минем күк үлеп гашыйклар
Дөньяда булыр сирәк

Яз кайткан кошлар сайравы
Ямансу инде бигрәк
Ямаса сагыну утында,
Ул йөрәк кемгә кирәк?

Үз дигән ярым, кошлар күк,
Кайтмаса илгә гел дә,
Җыламый гүзмәм гауларның
Чирәмле итәгендә

Аңламас һич тә яшь чирәм
Ачысын күз яшемнең.
Сайрашкан чакта пар кошлар
Мин кемгә эндәшермен?

Сискәнер таш та, чыдамас
Тулышкан сагышыма,
Өздерә моңнар, кагылсам
Шул кылга ялгыш кына

И тәкәббер...



И шул көлуләрең
Авылсытып,
Шаяртуың җанны
Давылсытып

Ялкын ялмап үтте
Яфрак очып,
Тик син ялгышып та
Саргаймыйсың

Үртә чарасызны,
Кызык табып
Синең өчен кошмын
Тозактагы

Сүнде өмет, качты
Дөнья гаме
Бу мәхшәрнең артык
Булмаганы!

Комсыз падишаһы
Салкын өйнең,
Бисклегем булып
Кал син минем

Кол ит мәгәр, сана
Мәҗнүнеңә, —
Салма өметсезлек
Җәбереңә!

Ваз кичмәмен — күккә
Ник ашмыйсың
Әллә ташлан гына
Кояшмы син?
Дәрья суы белән,
И тәкәббер,
Керфек чыландырыр
Идең лә бер

Ташка дүндердең лә
Күңелдәген,
Үкенечләр салдың
Үкенмәдем!

ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ



15 сентябрьдә татар драматургиясе классигы Таҗи Гыйззәтнең тууына 100 ел тулды. Әдипнең 40 ка якын драма әсәре татар сәхнәсендә, бигрәк тә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелды. «Ташкыннар», «Чаткылар» пьесалары мәктәп дәреслекләренә кертелеп, укучылар тарафыннан өйрәнелде. Т.Гыйззәт милли сәнгатьнең музыкаль драма жанрын дәвам итүче дә. Ул — «Наемщик» либреттосының авторы. Әсәргә музыканы С.Сәйдәшев язган һәм аны үзенең иң уңышлы әсәре дип санаган иде. «Башмагым» музыкаль комедиясенең либреттосын да Т.Гыйззәт язды, ә музыкасын икенче күренекле композиторыбыз — Җәүдәт Фәйзи иҗат итте. «Башмагым» Татарстан чикләрен үтеп, Русия һәм СССРның күп шәһәрләре сәхнәләрен урап чыкты, тамашачы тарафыннан җылы кабул ителде. Таҗи Гыйззәт — күпсанлы публицистик әсәрләр авторы да. Алар республика матбугатында татар һәм урыс телләрендә дөнья күрде һәм җәмәгатьчелек тарафыннан яратып кабул ителде.

Таҗи Гыйззәт талантлы артист та иде. Ул татар, урыс һәм Аурупа драматурглары әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә уйнап, дистәләрчә истә калырлык образлар тудырды. Татарстан Республикасы дәүләт бүләгенә лаек булган язучылар арасында ул беренчеләрдән иде, орден белән бүләкләнгән, Татарстанның һәм һәм РСФСРның мактаулы исемнәренә лаек булган язучы иде.

Әдип республика тормышында актив катнашты һәм күп җәмәгать эшләре башкарды. Дистә еллар буе ул «Совет әдәбияты» журналының редколлегия әгъзасы, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының сәнгать советы, Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы, ә 1942-1943 елларда бу берлекнең җитәкчесе булды.

Драматург Р.Ишморат үз вакытында Т.Гыйззәт эшчәнлеге турында болай дип язды: «Сугыш елларында Таҗи Гыйззәтнең Язучылар берлеге идарәсендә алып барган җәмәгать эше чын мәгънәсендә сугышчан хезмәт булды. Аның бу көннәрдә Мәскәүдән күчеп килгән язучыларны урнаштыруда ашыгыч чара күрүе, үз өстенә төшкән сугышчан бурыч санап, көн-төн эшләве әдипнең кешелек сыйфатларын тагын да калкурак ачты. Таҗиның ярдәмен күргән Мәскәү язучылары аңа үзләренең кайнар рәхмәтләрен әйтәләр». (Р.Ишморат. «Дусларым, остазларым». Казан, 1988, 78 б).

Укучыларыбызны Т.Гыйззәтнең Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан Язучылар берлеген җитәкләгән чактагы эшчәнлеген чагылдырган һәм архивларда сакланып калган кайбер документлар белән таныштырабыз.

ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетына

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе язучыларга Татарстан Республикасында туып-үскән Советлар Союзы Геройлары турында очерклар язу эшен йөкләде. Геройларның биографияләре, башлыча аларның Бөек Ватан сугышына кадәрге тормышлары һәм хезмәт юллары белән язучылар таныштылар инде.

Очеркларны тиешле югарылыкта ышандырырлык итеп язар өчен, берүчә геройларның каһарманлык күрсәткән җирләрендә, алар хезмәт иткән частьләрдә булып, материал туплаярга кирәк. Шул максаттан чыгып, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе Сезнең РККА Политуправлениесенә үтенеч белән чыгуыгызны сорап мөрәҗәгать итә.

Түбәндәге язучыларга фронтта, частьләрдә булу мөмкинлеге тудырылсын иде.

1. Фатих Хөсни. Ул Советлар Союзы Герое Ф.Фәткуллин турында очерк яза

2. М.Елизарова. Ул В.Григорьев турында яза.

3. Б.Зернит. Ул Лихачев турында яза.

4. Г.Иделле (Усманов). Ул Маннапов турында яза.

Т.Гыйззәтов,
Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе.
5.12.1942 ел.

Сәхнәбезнең

ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетына

Шушы көннәрдә Казан шәһәренең Свердлов район хәрби комиссариаты яшь татар совет тәнкыйтьчесе, СССР Язучылар берлеге әгъзасы Г.Халитовны Кызыл Армиянең хезмәт частьләренә алды (ип. Халитовны комиссия стройдан тыш хезмәткә генә яраклы дип тапты).

Ип. Халитов бүгенге татар совет әдәбиятының әйдәп баручы тәнкыйтьчесе санала һәм аның җитди хезмәтләре бар: ул «Хәзерге татар әдәбиятының 25 еллыгы» дигән зур хезмәт язып тәгәлләде һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан яклау тапты. Иптәш Халитов бүген «Татар әдәбияты Бөек Ватан сугышы көннәрендә» дигән тема буенча эшли.

Әдәби кадрларны саклау максатыннан һәм ип. Халитовны төп хезмәтендә файдалануның зарурлыгын искәртеп, ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетыннан Халитовны хезмәт частьләреннән азат итүдә ярдәм күрсәтүен сорыйбыз.

Т.Гыйззәтов,
ТАССР Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе.
2.12.1942 ел.

ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетына

Фронтта татар телендә чыгарыла торган газеталарның хәзерлекле журналистларга һәм язучыларга мохтаҗлыгы билгеле. Шуңа да карамастан, шундый әзерлеккә һәм зур эш тәҗрибәсенә ия булган Мәхмүт Максудов, Сибгат Хәким, Әхмәт Исхак, Гариф Галиев, Фатих Кәримов, Абдулла Әхмәтов кебек шагыйрьләр һәм язучылар Кызыл Армия сафларында үз белгечлекләре буенча хезмәт итмиләр. Шушыларны һәм татар әдәбиятының язучы кадрларын исән калдыру зарурлыгын истә тотып, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе Сездән югарыда исемнәре аталган язучыларны фронт матбугатында куллану мәсьәләсен РККАның Политуправлениесе каршында куюгызны сорый.

Язучыларның адресы.

1. Мәхмүт Максудов — 4 нче чаңгы бригадасы.

2. Сибгат Хәкимов — 821 нче частьнең 1443 нче кыр почтасы;

3. Әхмәт Исхаков — Алтай краеның Бийски шәһәре, 234/24 часте;

4. Гариф Галиев — Горький өлкәсенең Выкса шәһәре, 7/А кыр почтасы;

5. Фатих Кәримов — 204 нче частьнең 633 нче кыр почтасы;

6. Абдулла Әхмәтов — 502 частьнең 341 кыр почтасы.

Т.Гыйззәтов,
Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе.
5.12.1944 ел.

СССР Язучылар берлегенә ип. Фадеевка

Хөрмәтле ип. Фадеев!

Без инде Татарстанның әйдәп баручы язучыларының СССР Сәүдә Халык комиссариатының 1943 елның 7 августында чыккан 308 санлы приказына кушымта итеп бирелгән исемнәр рәтенә кертелмәве мәсьәләсендә мөрәҗәгать иткән идек. Бәхәссез, безнең бертөркем язучылар (исемлек теркәлгән) приказда күрсәтелгән «Б» пунктына кертелүгә лаек. Сезнең өлкә комитетына язган хатыгыз һәм бу хәлне төзәтү буенча күргән чараларыгыз турында да безгә мәгълүм. Әмма бүгенге көнгәчә бу мәсьәлә хәл ителмәгән, һәм Татарстан язучылары 308 нче приказ нигезендә үзләренә тиешле паекларны ала алмыйлар.

Шушы мәсьәләне хәл итүдә ярдәм күрсәтүегезне сорап янә Сезгә мөрәҗәгать итәбез һәм ул якын көннәрдә хәл ителер дигән өметтә калабыз.

Т.Гыйззәтов,
ТАССР Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе.
1.09.1943 ел.

РСФСР Министрлар Советының сәнгать эшләре комитетына

РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, орденлы Таҗи Гыйззәт һәм ТАССРның атказанган артисткасы Мәрьям Сульва концертларда һәм радио тапшыруларында даими рәвештә сәнгатьчә сөйләү жанрында чыгыш ясыйлар.

Алар сәнгатенең сәнгати дәрәҗәсе югары булуын искә алып, ТАССР Министрлар Советы каршындагы сәнгать эшләре идарәсе Т.Гыйззәтов һәм М.Сульва иптәшләргә филармония тарифы категориясенең сөйләү жанрындагы I нче ставкасын раславыгызны сорый.

А.Прошина,
Министрлар Советы каршындагы сәнгать эшләре идарәсе начальнигы урынбасары.
9.05.1950 ел.

асыл заты

ВКП (б) ӨК секретаре ип.Колыбановка

Татарстан совет язучылары берлеге Ватан сугышы шартларында үзенең төп эшен – тылда булсын, фронтта булсын – татар укучыларын немец басып алучыларга каршы көрәшерлек итеп тәрбияләүгә юнәлтә.

Совет власте елларында үсеп чыккан язучылар совет халкының тирән патриотик хисләрен, туган илгә һәм халыклар юлбашчысы иптәш Сталинга булган мәхәббәтен, эшебезнең хаклыгына һәм дошманны җиңүгә бетмәс-төкәнмәс ышаныч, туган халыкларыбызны кол итүчеләргә карата ачы нәфрәт хисләрен чагылдыра торган матур әдәбият әсәрләре тудырдылар һәм тудыралар.

Хәзерге вакытта Татарстан совет язучылары берлегенең 54 әгъзасыннан 28е Кызыл Армия сафларында кулына корал тотып немец вәхшиләренә каршы көрәшә. Кайберләре инде батырларча һәлак булды.

Шушы чор эчендә язучылар тарафыннан җырлар, шигырьләр һәм поэмалар, хикәяләр, очерк һәм повестьлар, драмалар һәм вак сәхнә әсәрләре язылды, публицистика җанланды. Күренекле шагыйрьләребез Муса Җәлилнең, Шәйхи Маннур, Нур Баян, Әхмәт Ерикәй, Сибгат Хәким, Фатих Кәрим, Әхмәт Исхак һәм башкаларның фронт шигырьләре һәм поэмалары зур популярлык казанды. Ш.Камал, Г.Разин, К.Нәҗми, Г.Әпсәләмов, Ф.Хөсни, М.Әмир, Х.Госман, Г.Кашшаф кебек язучыларыбызның Ватан сугышындагы һәм тылдагы батырлыкны чагылдыра торган хикәяләре язылды. Драма жанрында Н.Исәнбәт, Т.Гыйззәт, Р.Ишморат, М.Әмир әсәрләре дөнья күрде.

Шушы чор эчендә яңа язучы кадрлар үсеп чыкты. Яшь язучылар һәм башлап язучылар фронт эшләрен иҗат эше белән оста бәйләп алып баралар. Фронтовиклар Ш.Мөдәррис, Г.Әпсәләмов, Ә.Камал, Х.Мөҗәй, М.Закиров һәм башкалар немец фашистларына каршы актив рәвештә көрәшкән хәлдә, укучыны дөреслеге, тормышчанлыгы һәм хисле леге белән дулкынландыра торган очерклар, хикәяләр, көндәлекләр, шигырьләр яздылар. Бу әсәрләр халыкта немец вәхшиләренә карата нәфрәт хисләре, татар халкында патриотик тойгылар тәрбияләүгә юнәлдерелгән.

Хәзерге вакытта, совет язучылары берлеге, үзенең эш чараларын үзгәртеп, фронт заказын үтәүгә күчте. Язучылар фронт газиталәре өчен очерклар һәм хикәяләр, җырлар һәм шигырьләр, «Кызылармеец китапханәсе» өчен татар телендә әдәби әсәрләр һәм Татарстанда туган Советлар Союзы Геройлары хакында очерклар сериясе язуга мобилизацияләнде. Шуның өстенә язучылар Воениздат һәм Татгосиздат тарафыннан чыгарыла торган матур әдәбият әсәрләрен тәрҗемә итүдә катнашалар.

Ватан сугышы чорында Татарстан язучылары халкыбызның Совет ватанын саклауда каһарманнарча көрәшен яктырта торган зур әдәби әсәрләр тудырырлык материал җыйдылар. Бу бурычны тормышка ашыруга республикабызда талантлы әдәби кадрлар булуы мөмкинлек бирә. Әмма мондый зур әсәрләрне тудыру, бигрәк тә драма һәм проза өлкәсендә, берничә төрле җитди каршылыкка килеп терәлә.

Беренчедән, шушы вакытка кадәр язучылар җитәкче оешмалар, ВКП(б) райкомнары, шәһәр комитеты, өлкә комитеты һәм халык комиссарлары советы тарафыннан иҗат мәсьәләләренә карата берниндн кайгыртучанлык һәм игътибар тоймый. Бу хәл татар әдәбияты үсешенә, язучылык хезмәтенең активлыгына гына түгел, ә бәлки инде язылып, татар укучылары арасында киң таралган әсәрләрнең абруена да комачау итә. Безнең республика һәм шәһәр җитәкчеләрен татар язучыларының (коммунист булмы ул кеше, фиркасезме), бер язучы да аларның иҗаты бервакытта да кызыксындырмады, бервакытта да тикшерелмәде. Язучыларга җитәкчеләре игътибарына лаек булмады һәм иҗатлары тикшерелмәде. Язучыларга җитәкчеләре тарафыннан мәгълүм юнәлеш биргән һәм шуның аркасында бик яхшы нәтиҗәләргә ирешкән республикалар һәм өлкәләрне без күпләп китерә алабыз.

Икенчедән, безнең күп язучылар төрле совет учреждениеләрендә эшлиләр, үзләренең энергияләрен һәм вакытларын казна эшен үтәүгә сарыф итәләр, шул ук вакытта алар җәмәгать эшләреннән дә азат ителмиләр. Иҗат эше өчен язучылар фәкать үзләренең ял вакытларын, йокы вакытларын гына файдалана алалар. Хезмәт урыннарында эшләре артык күп булу сәбәпле, алар хәтта кыска сроклы иҗади ял вакытыннан да, чисә иҗади командировкадан да файдалана алмыйлар...

Өченчедән, фронттагы татар язучылары белгечлекләре буенча файдаланылмыйлар, чөнки Татарстан Республикасының хәрби комиссариатлары аларны гаскәри частьләргә гомуми нигездә җибәргән. Хәзерге вакытта безнең язучылардан өчесе-дүртесе генә армия матбугатында эшли.

Дүртенчедән, башка халыклар тарафыннан татар әдәбияты белән кызыксыну үсүгә карамастан, без тәрҗемә итү өчен акча булмау сәбәпле миллионнарча укучыларның ихтыяҗын хәтта өлешчә генә булса да канәгатьләндерә алмыйбыз. Дөрес, соңгы елларда татар шагыйрьләренең аерым шигырьләре тәрҗемә ителгән иде, ләкин проза һәм драматургиядән бөтенләй тәрҗемәләр юк, чөнки моны оештырыр өчен совет язучылары союзының да, Татгосиздатның да бер тиен акчасы да юк. Шуңа күрә татар әдәбияты бөтенсоюз бәясен ала һәм тәнкыйтьнең игътибарына алмый. Болар исә аның алга таба үсүе өчен кирәк.

Бишенчедән, язучы хезмәте өчен түләү Татарстанда сугышка хәтле үк инде бик түбән дәрәҗәдә иде. Сугыш вакытында язучыларның әдәби хезмәте өчен түләү берничә тапкырга кимеде. Бу бер яктан әдәби әсәрләрнең басылуы кимү белән аңлатылса, икенче яктан язучыларның көнкүреш тәэмин итү чыганакларының кимүе белән аңлатыла.

Алтынчыдан, гәрчә халыкны тәрбияләүдә һәм аларны фронт һәм тыл алдында торган кичектергесез бурычларын үтәүгә мобилизацияләүдә матур әдәбият искиткеч зур әһәмияткә ия булса да, Татгосиздат үзенең эшендә... матур әдәбиятны бастыруга карата ваемсызлык күрсәтә. Татар язучыларының күп кенә оригиналь әсәрләре айлар буена, кайчакларда хәтта еллар буена, типографиядә хәрәкәтсез ята. Татгосиздат җитәкчелеге аларны вакытында чыгарып, укучыга җиткерү турында кайгыртмый. Тукайның халыкны патриотик рухта тәрбияләүдә әйтеп бетергесез әһәмияте булган сайланмалар җыентыгы, халык эпосы «Идегәй», «Татар поэзиясе антологиясе» кебек әсәрләр хәзергәчә басылып чыга алмыйча ята.

Җиденчедән, укучылар арасында искиткеч зур популярлык һәм абруй казанган «Совет әдәбияты» журналы хәзергәчә өлкә җитәкчеләре һәм Татгосиздат тарафыннан таяныч таба алмый. «Совет әдәбияты» журналы өчен берниндн эш шартлары тудырылмаган. Журнал ВКП(б) ҮКы тарафыннан өлкә газиталәре һәм журналларына нисбәтән чыгарылган басма һәм хезмәткәрләргә эш хакы түләү турындагы карары биргән хокукка ия түгел. Нәшрият хезмәткәрләре һәм типография җитәкчеләре журналны вакытында дөньяга чыгару турында кайгыртмыйлар гына түгел, хәтта аны төрлечә тоткарлыйлар.

Татар совет әдәбиятын үстерү, язучыларның иҗатын активлаштыру һәм аларның көчен фронт заказын үтәүгә мобилизацияләү максатларында, ... Татарстан совет язучылары берлеге идарәсе түбәндәге чараларны үткәрүне зарур дип саный һәм бу эштә сездән гамәли ярдәм итүегезне үтенә:

1. Һәр язучы җитәкче оешмалар һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан реаль кайгырту һәм үз иҗатына карата игътибар тоярга тиеш.

2. «Кызылармеец китапханәсе» өчен оригиналь әсәрләр иҗат итү һәм Советлар Союзы Геройлары турында очерклар язу максатында татар язучыларын предприятиеләргә, колхозларга, совхозларга һәм бигрәк тә фронтка җибәрү өчен командировкалар белән тәэмин итәргә. Совет язучылары берлеге әгъзалары булган язучылар эшли торган учреждениеләрнең җитәкчеләрен, уртача эш хакын саклаган хәлдә, язучыларны иҗат ялы белән тәэмин итүне мәҗбүри куярга, шулай ук язучы иҗаты өчен җитәрлек кадәр вакыт бирерлек итеп совет учреждениеләрендәге эш сәгатьләрен җайлаштырырга.

3. Татар язучыларын максатчанрак файдалану һәм ул кадрларны саклап калу җәһәтеннән Ватан сугышы фронтларындагы язучыларның квалификацияле төп өлешен армия матбугатында эшләү өчен күчерергә. Беренче чиратта газита эшенә түбәндәге язучыларны һәм шагыйрьләрне – Мәхмүт Максудны, Гариф Галиев, Әхмәт Исхак, Фатих Кәрим, Сибгат Хәкимне күчерергә.

4. Татар әдәбиятының бөтен жанрларын совет язучылары берлеге аша тәрҗемә иттерүне бик кирәкле гамәл дип табарга.

ТАССР Халык комиссарлары советына татар әдәби әсәрләрен урыс теленә тәрҗемә итү өчен ел саен җирле бюджеттан 50 шәр мең сум акча бүлеп бирергә тәкъдим итәргә.

Татгосиздатны татар матур әдәбияты әсәрләрен ел саен 50 басма табактан да ким булмаган күләмдә чыгарырга мәҗбүр итәргә.

5. Татгосиздат һәм Камил Якуб исемендәге типография җитәкчеләрен татар язучыларының матур әдәбият әсәрләрен тиз арада басып чыгаруны тәэмин итәр өчен катгый чаралар күрергә мәҗбүр итәргә. Татгосиздатны татар халык шагыйре Г.Тукайның инде җыелган һәм өлешчә басылган сайланма әсәрләрен, антологияне, производствога төшерер өчен әзерләнгән халык эпосы «Идегәй»не дөньяга чыгарырга мәҗбүр итәргә.

6. «Совет әдәбияты» журналына җитди әһәмият биреп, аны вакытында дөньяга чыгару һәм хезмәткәрләренә шартлар тудыру максатында:

а) Татгосиздат управляющие ип.Мангушевны һәм типография директоры ип.Әхмәдуллинны журналны вакытында дөньяга чыгарырга мәҗбүр итәргә.

б) ТАССР ХК Советын һәм Госпланын журнал хезмәткәрләренең эш хакын ВКП(б) ҮКның өлкә газиталәре һәм журналлары турындагы карары нигезендә тәртипкә салу чараларын эшләргә мәҗбүр итәргә, аларның эш хакын өлкә журналлары һәм газиталәрендәге эш хакына тигезләргә.

7. Татарстандагы әдәби хезмәт өчен түләүне нормаль булмаган хәл дип санап, язучыларга хөкүмәт ярдәме күрсәтергә. Моның өчен ТАССР ХК Советына аеруча мохтаҗ булган язучыларны һәм аларның гаиләләрен, ягулык, транспорт, өс киеме һәм аяк киеме белән тәэмин итүне мәҗбүри итеп куярга.

Аеруча актив 15ләп язучыны, тәэмин ителешнең аерым төркеменә кертеп, партактив ашханәсенә һәм махсус дәвалау клиникасына беркетергә.

Т.ГЫЙЗЗӘТОВ,
ТАССР Совет язучылары берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе.
1942, ноябрь.

Моннан кырык биш ел элек Таҗи Гыйззәтнең пьесалар китабын без — мәктәп балалары кулдан-кулга йөртеп тә, аулак өйләрдә, җылы мунчада сукыр лампа янып та кат-кат укыдык. Шуннан бирле Таҗи Гыйззәт исеме миңе гел озата йөрде: аның пьесаларында артист буларак уйнап, режиссер буларак ул пьесаларны сәхнәгә куеп та үстек, зәүкый ләззәт алдык.

Мәшһүрләребезгә кагылышлы «Үзга язмаган хәлләр» исемле китабымда да Таҗи ага турында хикәяләр байтак. Шуларның кайберләрен «Мәдәни җомга» укучылары игътибарына тәкъдим итәм.

БАТУЛЛА.

Көлмәгез кешедән

1920 елның май аенда Самара шәһәрендә Идел аръягы хәрби округы идарәсе каршында татарлар өчен махсус драма студиясе ачыла. Йөздән артык кеше арасында Саратов каласыннан Хөсәен Уразик, Мәләкәстән Әсгать Мәҗит, Иж заводы эшчесе Таҗи Гыйззәт тә була. Башкалардан аермалы буларак, Таҗи Гыйззәт шунда укыган вакытта, көнел ачуларга кушылмыйча, буш вакыты чыктымы, язарга утыра.

- Язасың да язасың, нәрсә язасың соң син? — дип сорыйлар сабакташлары Таҗи Гыйззәттән.

- Пьеса язарга теләк бар! — ди булачак драматург.

Сабакташлары Таҗидан көләләр.

— Булдыра алмаслык эшкә тотынгансың син, Таҗи. Завод эшчесе булдыра ала торган кәсеп түгел ул! — диләр.

Таҗи Гыйззәтнең шунда яза башлаган «Талир тәңкә» (соңра — «Чаткылар») исемле беренче пьесасы дөньяны шаулата. Таҗидан көлебрәк йөргән сабакташлары үзләре дә бу спектакльдә уйнау бәхетенә ирешәләр.

Бәхетле гаилә

Драматург Таҗи Гыйззәткә хатыны Мәликә ханым иҗат эшендә бик нык ярдәм итә торган була, пьеса язганда ул иренә җыр сүзләре табыша. Бу турыда Таҗи сабакташы Рифгать Фәйзигә үзе сөйләгән:

— Язган бөтен пьесаларымдагы җырларны миңа Мәликә табып бүләк итте!

Соңрак кагылырмын

Таҗи Гыйззәтнең яхшы актер икәне дә мәгълүм иде.

Бервакыт Таҗи абзый үз пьесасында уйнаганда, вакытыннан алда ялгышып сәхнәгә чыга. Сәхнәдәге актер аптырап кала, аның кушаганын күреп, Таҗи ага да эшнең нидә икәнен сизеп ала. Ләкин сәхнәгә чыгылган, халык аннан нидер көтә; сәхнәгә сүзсез кереп, сүзсез чыгып китү пьесаның тәртибенә туры килми. Уңайсыз хәлдән чыгу өчен, әлеге актер сүз башлый:

— Ник килдең? — ди.

— Болай гына, — дип Таҗи Гыйззәт пьесада булмаган сүзләр сөйли башлый. — Менә хәл белеп чыгарга уйладым әле, ни хәлләрдә яшәп ятасыз соң?

— Без әйбәт ятабыз, агайне, ә менә син бераз ашыгыбрак килгәнсең бит әле.

— Шулайрак булган икән шул, туган, алайса, мин бераз соңрак кагылырмын әле, — дип Таҗи ага сәхнәдән чыгып китә.

Алла ярдәм бирсен!

Касыйм Шамил урамнан баргапда, Таҗи Гыйззәт күренгәч, исереккә сабыша Таҗи Гыйззәт Касыйм Шамил янынинан үтеп китә алмый, аны өенә илтеп куярга була. Ләкин Касыйм Шамил атлый алмый, егыла.

— Урамда калдырып булмый бит инде сине, — дип сөйләнә-сөйләнә Таҗи Гыйззәт Касыйм Шамилне күтәреп, өенә чаклы илтә. Капка төбенә кайтып җиткәч, Касыйм Шамил сикереп Таҗи Гыйззәт җилкәсеннән төшә дә:

— Син мине күтәреп кенә йөртәсең, Алла ярдәм бирсен, зур рәхмәт! — дип, йөгереп өенә кереп китә.

Икенче тапкыр Касыйм Шамил чыннан да көчкә-көчкә генә аягында басып урам чатында торганда, Таҗи Гыйззәт:

— Алла ярдәм бирсен! — дип узып китә.

Шул көнне Касыйм Шамилнең хәлләре чыннан да «Алла гына ярдәм итәрлек» була.

Сәер атлау

«Башмагым»да Таҗи Гыйззәт үзе Кәрим байны уйный икән. Пәрдә азагында югалган Сәрвәрне эзләргә чыгар алдыннан хор болай җырлый:

Киттек-киттек Сәрвәрне эзләргә.
Кай җирдә икән, күзләргә;
Нинди хурлык бу безләргә,
Әгәр ябышып чыккан булса...

Шулай җырлый-җырлый барысы да Сәрвәрне эзләргә китә. Ләкин шулчак Кәрим бай-Таҗи Гыйззәтнең ыштан бавы шартлап өзелә. Зур төпле чалбар котылгысыз рәвештә аска шуа. Таҗи Гыйззәт ике кулы да буш булмау сәбәпле, чалбарны тота алмый икән. Бер кулында таяк, икенчесендә комган. Ыштансыз калмас өчен Таҗи сәхнәдән ике аягын аерып чыгып китәргә мәҗбүр була. Аның иләмсез атлаганын күреп, тамашачы да, артистлар да егылып көлә башлый.

Хозыр Ильяс

1942 елда Татар дәүләт академия театрында Таҗи Гыйззәтнең «Башмагым» музыкаль комедиясе куела. «Башмагым» гаять зур уңышка ирешә. Спектакльне көн аралаш уйный башлыйлар. Шулай төрләнгән чагында гына спектакльдә Кәрим бай ролен уйнаучы артист Касыйм Шамил кинәт авырып китә. Билетлар сатылып беткән. Театр җитәкчеләре нишләргә белми. Шулчак Таҗи Гыйззәт:

— Кайгырмагыз, Кәрим байны үзем уйныйм! — ди.

Бер репетициясез, бер сүзен төшереп калдырмыйча, Таҗи ага Кәрим байны зур уңыш белән башкарып чыга.

Алыштанмы, садыштанмы?

Югары Осланда ял иткән чакта Әхмәт Фәйзи үзенең «Тукай» романын язучыларга, театр кешеләренә укый. Уку мәҗлесләрендә Таҗи Гыйззәт тә катнаша. Тәнәфес вакытларында Таҗи Гыйззәт, осшкан тәнен язып алу өчен, төрле нәрсәләр уйлап таба. Берсендә ул Шириаздан Сарымсакны көрәшергә чакыра.

— Әйдә, Шириаздан, татарча көрәшеп алыйк. Син Казакъстан кешесе, татарча көрәшнең серләрен белмисеңдер! — дип алыша башлыйлар болар.

Шириаздан да гәүдәле, таза кеше. Таҗи ага үзе дә чын көрәшче — көч сынаш озакка тартыла. Арыслан белән юлбарыс көрәше сыман — көчләр тигез була, ахрысы, бу алышта җиңүче булмый.

— Аның каравы, Әхмәт Фәйзи җиңде! Шәп роман язган! — ди Таҗи.

Кызык эзләүче

Таҗи Гыйззәт «Алсу таң» исемле пьесасын «Совет әдәбияты» журналына әзерләгән вакытта Гариф Ахун аңа болай ди:

— Таҗи агай, сезнең бу пьесагызда баш каһарманның сөйләшүе кызык түгел кебек тоела миңа...

— Син яшь әле, Гариф энем, баш каһарманнан кызык эзләп утырма! — ди драматург.

Көрәшче Таҗи

Драматург Таҗи Гыйззәт белән артист Хәбиб ишеккә-ишек күрше булып яшиләр.

— Карале, Хәбиб, — ди беркөнне Таҗи Гыйззәт. — Кыш килеп җитте, ягарга утын юк, ярдәм итсәнче.

Полуторка машинасы алып, болар Усия складына утынга китәләр. Сигез кубометр әрдәнәне икесе ярга ташыйлар, машинага төйиләр. Алып кайтып бушаталар. Капка тар булу сәбәпле, әрдәнәне урамнан утынлыкка ташырга туры килә.

— Җен икәнсен син, Хәбиб! — ди драматург. — Синдәй куәтле адәмнәр сирәктер.

Хәбиб, мактаганга кәдрәеп, Таҗи Гыйззәтнең биленнән ала. Таҗи абзый да аптырап калмый, Хәбибнең биленнән алып аркасына салып куя

— Һай, Хәбиб! — ди Гыйззәт. Синдә куәт бар, ләкин хәйлә юк. Көрәш хәйләсез булмый ул, энем!

Тигезсез мәхәббәт

Бервакыт Таҗи Гыйззәт үзенә килгән кунак белән Камал театрында спектакль карап утыра икән. Мәхәббәт каһарманы ролендә чибәр, яшь артист уйный. Мәхәббәт гүзәлен кайчандыр яшь булган бер артистка башкара икән.

Залда утыручы бер тамашачы бөтен кешегә ишетелерлек итеп:

— Шушы карт хатын өчен үләрдәй булып гыйлмерә бу яшь җүләр! Беткәнме сиңа яшь хатын, дивана! — дип кычкыра

Таҗи Гыйззәт авызын якасына яшереп бик озак кына көлә.

— Их, — ди кунак җегет. — Таҗи абый, бу җегет ролен син уйнасаң, ул чагында «чиләгенә күрә капкачы» дигәндәй, мәхәббәт тигез булыр иде

— Дөрес әйтмисең, дустым, җегетне түгел, кызны алыштырырга кирәк! — ди Таҗи Гыйззәт.

Калып

1950 нче елларда Таҗи Гыйззәт «Совет әдәбияты» журналының редколлегия әгъзасы булып тора. Әсәрләр турында фикер алышканда ул үз сүзен иң азактан, бөтен кеше сөйләп бетергәч кенә әйтә торган була. Баш мөхәррир Гази Кашшаф

— Җә, Таҗи ага, синең фикерне дә ишетик инде! — дигәч кенә, Таҗи Гыйззәт сүз башлый икән.

Әсәр ошаса, ул ике җөмлә белән:

— Бастырырга кирәк, бу тормышчан әсәр! — ди.

Әсәр ошамаса:

— Кирәк түгел, бу тормышчан булмаган! — ди.

Таҗи Гыйззәт

Коръән карагы

Гастрольдә йөргәндә артист Хәбиб Иж-Буби мәдрәсәсеннән Коръәннең татарчага тәрҗемәсен урлый. Казанга кайткач, «Сорочьи» базарына алып чыгып сата. Озак та узмый, Хәбиб Таҗи Гыйззәт бүлмәсендәге китаплар арасында үзе саткан Коръәнне күреп шакката һәм:

— Таҗи абзый, каян алдың син бу татарча Коръәнне? — дип сорый.

— Базардан сатып алдым, — ди Гыйззәт. — Сирәк китаплар сатучыдан.

Кая киткән ул Коръән — билгесез.

Тормыш һәм сәнгать

Таҗи Гыйззәт коллективка «Коммунар» исемле яңа пьесасын укый икән. Пьесада шундый күренеш була. Имеш, бер шаян җегет ничек итеп Питербурда патшаны бәреп төшергәннәрен сөйли:

— Килеп кердем Кышкы сарайга, Микулай патша утыра сәке башында. Якасыннан умырып тоттым да бирдем кирәген. Патша әйтә, ярар, Ханнан, артык кыйнама, мин үзем сәкедән төшәм, ди.

Шушы сүзләрне ишеткәч, артист Хәбиб иләмсез акырып көлә башлый.

— Иплебрәк көл, җүнсез! — диләр өлкәннәр.

Хәбиб һаман тыела алмый:

— Бу бит безнең авылның «Бохара ялганчысы» дигән атлы Габделхалик Ханнан! — ди.

Чыннан да, авылларда йөргәндә, Таҗи Гыйззәт Хәбибнең туган авылы Әлкидә, Бохара ялганчысыннан күп кенә мәзәкләр язып алган булган икән.

Соликамски — тозлы сазлык

Бер тапкыр Таҗи Гыйззәт театрны Урал ягына гастрольгә алып чыгып китә. Тимер юл белән Соликамски шәһәренә килеп төшәләр болар. Ул вакытта машина сирәк була. Таҗи ага бер ат табып килә. Артистлар бар булган әйберләрен арбага төйиләр. Кием тутырылган сандыклар, кәрҗиннәр, чемоданнар шактый авыр була. Ша-

турында сөйләкләр

һәргә юл байтак. Галимә ханым Ибраһим белән аның апасы Мәрьям ханым

— Бик арыдык, бераз утырып барыйк әле! — дип, сыртлап тоялган йөк өстенә менеп утыралар.

— Егыласыз бит! — ди Тажи Гыйззәт. — Төшегез яхшы чакта! Җәяү генә атлагыз!

Апалы-сеңел төшәргә уйламыйлар. Бер заман ат арбасы-ние белән пычрак уртасына кереп бата. Олаучы атны әйдәкли, чыбыркылый, сүгенә. Ат кинәт ыргып, арбаны тарта, ал тәгәрмәч чокырдан чыга, Галимә белән Мәрьям чәпелдәшеп сазга егылып төшә. Күлмәк-яулык, бит-баш пычракка буялган, тегеләр авызга тулган пычракны төкерә-төкерә үкереп җылый башлыйлар.

— Әйттем мин сезгә, — ди Тажи Гыйззәт. — Җәяү генә барыгыз, дидем.

Бераз баргач, артисткалар кипшенгәч, Тажи ага:

— Нигә алай төкеренәсең, Галимә? — дип сорый.

— Балчыгы бик тозлы! — ди Галимә ханым.

— Тозлыдыр шул, Соликамски бит, Тозлы Чулман! — ди Тажи Гыйззәт. — Аннан соң арбаны тарталмагач, анда бия ике тапкыр печ иткән иде.

Җүләр балык

Тажи Гыйззәт гаиләсе белән Юхмачыга, Әлки ягына кунакка кайта, ял арасында пьеса өчен материал да җыймакчы була. Шушы эшләр арасында ул һәрвакыт Кече Чирмешән елгасына балыкка йөри. Болар кунак булып төшкән йортка Заһидулла исемле тагын бер кеше ялга кайткан икән. Заһидулла абзый гомере буе кармак салып карамаган, хәтта балыкка йөргән кешене эшлексезгә саный торган адәм икән. Тажи Гыйззәт Заһидулла абзыйны балыкка барырга тәки күндерә бит.

Су буена килеп җиткәч, Тажи ага, бер чыбык табып, җеп-кармак тагып, Заһидулла абзыйга тоттыра да:

— Син, Заһидулла, миңа бик якын утырма, һава бик тыныч, икәү утырсак, балыкларны куркытырсың, — ди.

Заһидулла абзый йөз адымнар читкә китеп, кармагын суга ташлый да, исе китмичә генә Тажи Гыйззәтнең «юк эш» белән шөгыльләнгәнен күзәтә башлый. Гыйззәт булыр-булмас кечкенә алабуга, кызыл канатлар, чабаклар каптыра да савытына салып куя. Күзәтеп тору шөгыле Заһидулла абзыйны ялкыта. Ул иренеп кенә үз кармагын тартып карый — кармак чыкмый. Төпкә эләккән ахрысы, дип уйлый Заһидулла абзый, ныграк тартып карый — зур гына балык капкан.

— Тажи! — дип җир селкетеп акыра башлый Заһидулла абзый. — К-апты-ы!

Куркуыннан, каушавыннан Заһидулла абзый зур гына корбан балыгын ярга сөйрәп чыгара. Гыйззәт атылып килеп тә җитә. Кеше тоткан шулкадәр зур балыкны күреп, кайсы балыкчының гына күзе кызмас икән?

— Ничек капты бу сиңа? Ничек ала алдың син мондый зур балыкны? — дип хәйран кала Тажи Гыйззәт.

Юлда кайтканда да Тажи Гыйззәт корбан балыгына карап-карап ала да:

— Ничек капты бу сиңа, ә? Ничек ала алдың син моны, ә? — дип куя. — Җүләр балык булгандыр ул. Җүләр булмаса, беренче тапкыр кармак салучыга килеп капмас иде...

Шул көннән соң әлеге Заһидулла абзый ата балыкчы булып киткән, дип сөйлиләр.

Миһербан

Сугыш елларының соңында Тажи Гыйззәт үзенең туган авылы Барҗы-Умгага кайтып, колхоз эшләре белән кызыксынып, озак кына материал туплагач, китеп бара. Китәр алдыннан ул район үзәгендәге ашханәгә керә. Ашханәдә эвакуация белән Украинадан килгән кешеләр эшләгәнен белгәч, Украина кешеләренең хәл-әхвәлләрен сораштыра да райком кешесенә әйтеп куя:

— Алар монда боегып йөрерлек булмасын иде. Аларның хәле тагын да авыр! — ди.

Нәкъ шушы вакытта Кырымнан татарларны сөргән чак була. Аларны һич кызганмыйча атып, җәберләп, ач-ялангәч килеш хайван ташый торган вагоннарга төяп алып китеп, йортларына украин, урыс кешеләрен кертеп тутыралар, малларын алалар.

Тажи Гыйззәт кебек, украин, урыс язучысы татарларның хәле белән кызыксындымы икән? Гөнаһсыз татарларны акларга омтылучы булдымы икән?

Гыйззәт җылысы

Тажи Гыйззәтне бик кешелекле, миһербанлы шәхес булган, дип сөйлиләр. Бер тапкыр ул студент Шириязданн Сарымсак белән театрдан кайтып бара, ди. Алар бер урамда торалар икән. Шириязданның өстендә җылы тотарлык хәле калмаган кечерәк бер яңгырлык була. 1939 елның көзе, көннәр суык, җиле җилекләргә үтеп керерлек. Әче Шириязданның плащ эчендә калтыранып кайтканын күреп, Тажи Гыйззәт:

— Миндә бер көзге пәлтә бар, әле киелмәгән, акчасын соңыннан, эшли башлагач бирерсең, — дип, Шириязданны үз өенә алып керә.

Пәлтә студентка гаманлап теккән кебек булып чыга.

Еллар узып, бу пәлтә тузып бетсә дә, Ширияздан Сарымсак гомере буе үз тәнендә Тажи ага Гыйззәтнең җылысын тоеп яши.

Беренче бала

— Тажи ага, сез кайсы әсәрегезне беренче урынга куясыз? — дип сораганнар Гыйззәттән.

— «Чаткылар»ны! — дигән драматург. — Ул бит минем беренче балам!

Тылсымлы орден

Сугышка кадәр Риза Ишморат белән Тажи Гыйззәт Мәскәүгә баралар. Бер кунакханәгә киләләр — урын юк. Икенчесенә китәләр — урын юк. Шулай йөри торгач, ике драматург арып бетә. Урамда кунып булмый бит инде, Тажи Гыйззәт түшенә тагылган «Почет билгесе» орденын күрсәтә төшеп, администраторга:

— Директорыгыз кем сезнең? Чакырыгыз әле аны монда! — ди.

Тажи Гыйззәтнең кырыс тавышы администраторга яхшы ук тәэсир итә, күрәсең, ул:

— Гафу итегез, сез кем буласыз, иптәш? — дип сорый.

— Орденлы язучы булам мин! — ди Гыйззәт.

Администратор тиз генә боларга ике кешелек бүлмә табып бирә. Җылы, якты, кайнар сулы бүлмәгә урнашып алгач, Ишморат:

— Әллә кайчан әйтәсең калган шул гуң күчәп администраторларга орденың турында! — ди. — Башка вакытта да шулай ит әле...

— Юк, ярамый, — ди Тажи Гыйззәт. — Кабат мондый хәлдә калырга туры килмәсен!

Кайгыдашлар

1942 елның көзендә Тажи Гыйззәт улы Үзбәкнең сугышта үлгәнлеге турында хәбәр ала. Ул беркемне күрмичә, башын аска иеп, авыр адымнар белән урамнан барганда, артистка Фатыйма Ильская килеп чыга.

— Тажи, ни булды соң сиңа? — дип сорый Фатыйма ханым.

— Улым Үзбәк танк эчендә янып үлгән. Унтугыз яшендә иде... Синең улың да, Фатыйма, танкист... Фоатыңа яз... сак булсын!

1943 елның ноябрендә, Киев шәһәрен азат иткәндә, Фатыйма Ильскаяның улы лейтенант Фоат та һәлак була. Бу әче үлем кайгысын Фатыйма ханым бик авыр кичерә. Бу хәбәрне ишеткәч тә, Тажи Гыйззәт Ильская янына китә.

— Фатыйма, син сәхнә кешесе, синең хезмәтеңне халык көтә. Кайгыдан сыгылып төшү ул — дошманга бирелү, дигән сүз. Синең кебек, улларын югалткан меңләгән аналарның, агаларның күңелен күтәрү өчен эшләргә, иҗат итәргә кирәк! Батыр бул, Фатыйма!

Боек, артистка сәхнәгә юнәлә һәм, бөтен кешене шаккатырып ролен уйнап чыга.

Сыйфат

Тажи Гыйззәтне җирләгәндә, кабергә иңдерер алдыннан матәм җыелышы уздырыла. Атаклы драматург турында байтак кына җылы сүзләр әйтелә. Сүз композитор Җәүдәт Фәйзигә бирелә. Ул озын-озак итеп, ләкин бары тик үзенең иҗаты турында сөйли.

Матәм тантанасында катнашучы Шириаздан ага Сарымсак янәшәсендә торучы Салих Батыевка әйтә:

— Игътибар итегез, Җәүдәт Тажи абзый турында түгел, үзе турында күбрәк сөйли бит! — ди.

— Шулай шул, — ди Батыев. — Без моны киләчәктә истә тотарбыз.

Үлем түшәгендә

Драматург Тажи Гыйззәт күп эшләсә дә, аның иҗаты турында матбугатта җылы сүз күренми. Ниһаять, 1939 елда «Кызыл Татарстан» газетенең 15 февраль санында Мөхәммәт Гайнулланың «Драматург Тажи Гыйззәт» исемле мәкаләсе басылып чыга. Газетнең бу санын Тажи Гыйззәт кочагы белән сагып ала. Тыныч холыклы, сабыр табигатьле кеше булса да, Тажи Гыйззәт бу көнне шатлыгын яшерә алмый.

— Күрдегезме, минем турыда шәп мәкалә чыккан, — дип дусларына әйтеп куана.

Аннары, танылган драматург булса да, Тажи Гыйззәтнең ишле гаиләсе бик мул яшәми. Җитмәсә, ул каты авырый башлый. 1955 елның язында хәле бөтенләй мөшкелләнә. Авыру янына Гариф Гобәй хатыны Мөнирә ханым белән, Мөхәммәт Гайнулла хатыны Җамал ханым белән хәл белергә киләләр.

— Хәлем авырая, аякка баса алмам, ахры, — ди Гыйззәт. — Гаилә авыр хәлдә кала. Шуның өчен борчылам. Бер тиен маябыз юк. Шуның өстенә сайланма әсәрләремнең өч томлыгын да өченче категория белән генә бастыралар бит.

Моны ишеткәч, Мөхәммәт Гайнулла тиз генә чыгып китә. Бер сәгать чамасы узгач, әйләнеп керә дә авыруга бер кәгазь суза.

— Менә, Тажи абзый, өч томлык сайланма әсәрләрегезне беренче категориягә күчерү, гонорарны шул исәптән түләү турында Татарстан китап нәшрияты башлыгы Нәбиев иптәш приказын китердем, — ди ул.

— Рәхмәт, Мөхәммәт, инде тынычландым. Мәгълүм бер вакытка кадәр гаиләм тәэмин ителде, — ди авыру.

Шул көнне Гыйззәт ага, балаларын чакырып, васыятен әйтә. Берничә көн узгач, атаклы драматург Тажи Гыйззәт вафат була.

«Чаткылар» спектакленнән бер күренеш. Уңда — Орлов ролендә Тажи Гыйззәт.

Рифгать ӘХМӘТҖАН

Башак һәм милләт

(Нәсер)

1

Август басулары буйлап авылга кайтып килам. Көн аяз, юллар такыр, нигә бераз атламаска? Мондый чакларда тәпи-турак йөрү үзе бер хозурлык!

Камыллы басулар күпләнге-күпләнге хатирәләремне уятты. Балачактан калган гадәткә буйсынып, мин игътибар белән җиргә — камыл төпләренә карап барам. Кайда башаклар күренә ~ күңелдән шуларны барлыйм Ә башаклар җирдә бик күп калган. Кызганыч, сыйфат сакчылары — пионерлар да, рөхсәтсез башак җыючылар да күренми.

Безнең заманда башак җыю бөтен бер эпопея иде...

2

... Янчыгына дыңгычлап тутырылган башакларны җилпучка бушатып, берәмләп уасың да, саламын-әрбәсен җыеп алып, астагысын күзәп-җилписең. Кибәге бер якка, бодай янсә арыш бөртекләре (аралаш булса да ярый) бер якка җыела. Неолит бабаңнар заманыннан калган җайланма бу! Бодайны исә шундук куырып ашарга була.

— Дөньяда иң тәмле ризык — куырган бодай ул! - диләр яшьлекләре шул елларга туры килгән апалар.

Борынгы мисырлылар да «дөньяда иң тәмле су -- Нил суы», дигәннәр иң. Ә ул болганчык сары су икән, баксаң. Ләкин бөтен нәрсә нисби. Гаять авыр юл газапларын кичеп, Нил ярларына ирешкән борынгы кәрванчыга Нил суыннан да тәмлерәк ни бар дөньяда!

Әйе, шәп нәрсә куырган бодай. Әмма миң тутырып ипи пешергән чакларын онытып бетермәгән хуҗабикәләр моның белән генә канәгатьләнмиләр. Бодайны шешә белән сытып, ярма ясыйлар янсә тоеп онтаклыйлар. Тагын да кортлыраклары кул тегермәнендә тарттыралар. Әгәр дә урамнан үтеп барганда берәр өйдән «аю үкерә -- йонын коя» дигән табышмакны исенә төшереп, чабата базары шавы шикелле күңелле тәрелдәгән тавыш ишетелсә, белеп тор -- әлеге тегермәнле йортта синең каракашың үзе, энесе янсә энисе баятынак кына (кая монда иртәгә калдыру!) колхоз басуыннан кача-поса җыеп кайткан ашлыкны тарттыра булыр. Кул тегермәнен әйләндереп, битләре алсуланган чибәркәй шул заман егетләренең идеалы иде, мәгәр. Ничек үтмәк кирәк аның тәрәзәсе яныннан сызгырмыйча гына!

3

Кызлар - мәңгелек тема, әмма башак та «төшеп калганнар»дан түгел. Татар хәятында үзгә бер урында торган башакның хасиятләрен әйтеп бетереп булмыйдыр. Хәзер «кыз йолдызлыгы» дип аталган йолдызлыкны халкыбыз Сөмбелә бөреже дип йөрткән. Ә сөмбел - башак сыман чәчәк -- төптә «башак» дигән сүз. Кызларны түгел, башакны күккә мендергәннәр безнең бабайлар!Әмма егерменче гасыр башак шигъриятен пычратырга да юл гапты.

Утызынчы-кырыгынчы елларда татар һәм башкорт әдәбиятларында еш күтәрелгән тема колхоз басуыннан башак урлаучыларны «фаш итү»дән гыйбарәт иде. Мин урыс әдәбиятын шактый белам — аларның язучылары да ул чорларда «партияле» булырга тырышканнар. Ләкин урысларда, һәрхәлдә, олы әдәбиятта, башак урлауны «актуаль проблема» итеп күтәрүчеләр юк иде бугай. Ә менә безнекеләр «башак чәйнәп» вакландылар. Андый әсәрләрнең идеясе примитив: менә, әйтик, фәлән атлы кеше шулай-шулай башак урлый. Никадәр әшәкелек, ә?! Карак, әлбәттә, тотыла һәм аның кирәген бирәләр. Кирәген генәме соң:

Нурый
айлы төндә мыштым гына
Капчыгына башак төяде.
Нурый сизми калды
капчыгына
Ун озын ел кайтты иярел.

Соңрак башкорт халык шагыйре булып танылган Рәшит Нигъмәтинең бу юлларында гомуми хәл-әхвәл бик дөрес чагылдырылган: башак урлаган өчен ун ел да, унбиш ел да бирәләр иде ул чакларда. Шагыйрь хәтта прокурорның зәһәрле сарказмын да бирә алган. Үзе прокурор булган диярсең.

Башак урлау ул елларда чыннан да олы фаҗигане чагылдырган бик тирән тема иде. Тик «большевик» әдипләребез моны күрмәделәр, күрсәләр дә күрмәмешкә салыштылар.

Утызынчы еллар уртасында элекке кулакларны, руханиларны һәм башка шундый «чит элементларны» колхоздан куып чыгару кампаниясе уздырылды. Мөлкәте таланган, эшкә-укуга урнашырга да хокукы калмаган («кәҗә билеты» бирелгән) бәндә башак урламыйча ничек яшәргә тиеш иде икән?! Асылда әлеге кампания миллионнарча гаҗизләрне төрмәгә куып кертү кампаниясе булды.

Хәер, «сыйнфый саф элементлар» да урлашудан ерак китә алмадылар. Һәм бүген дә шулай дәвам итә.

4

Егетләренең иген урлаудан уза алмаячагын сизенгән чибәрләр кул тегермәннәрен ашъяулыкка кагып өйләреннән чыктылар да, туп-туры «кәнсәгә» юнәлделәр: «вербоваться ителеп», ят якларга олагырга...

Без сызгырып калдык. Гүзәлләребез урыс, үзбәк, грузин, тагын әллә кемнәрнең хатыннары булып, токымнарын ят якларда калдырдылар. Үз илләрендә яшәргә теләгәннәре шәһәрләргә юнәлде. Шәһәрләрдә исә алар йә ачтан үләргә, йә урыс егетләренең «татарва» дип мыскыллауларына түзә-түзә, урысча сөйләшә башларга тиеш иделәр. «Вербовать итүләр», «шәһәрләштерүләр» асылда ассимиляция җәтмәсенә куып кертү иде. Ә һәрбер ассимиляция — милли фаҗига ул.

5

Кырлар буйлап атлыйм. Җирдә күпме башак калдырганнар! Нидән мондый ваемсызлык? Башак бит ул, башак!

Иелеп берсен алам ~ баксаң, үрентели башлаган лабаса! Яңгырлардан соң бөтен басу шуннан яшәрә икән бит!

Ләкин юкка шыткан бодай бөртекләре. Әнә, тракторлар җир сөрә башлаганнар инде. Законсыз шыткан, шытымнар юкка чыгарылып, алар урынына «законлы» ашлык үсәчәк ич!

Шунда күңелгә бер чагыштыру килеп керә. Үз гаиләләрендә туган телләрендә сөйләшеп үскән татар, башкорт, чуаш, мари, удмурт балалары да шул кыргый шытымнар хәлендә — алар урыс басуында урыслаштыру комбайныннан төшеп калган башак үрентеләре генә. Ләкин аларның язмышы билгеле.

Иа, Ходай, безнең үз басуларыбыз да булырмы икән, ә?

● Илне туендыручылар тамак ялгый.

Әсрар ШАКИРҖАНОВ фотосы.

ГАЗЕТА ҺӘМ УКУЧЫ

Энҗе МӨЭМИНОВА

Сүнмә генә!..

«Мәдәни җомга»ның чыга башлавы уңаеннан

«Төлке һәм йөзем җимеше» —
Таныш мәсәл.
«Буй җитмәслеккә үрелмә» —
Таныш мәкаль.

Тик барыбер яшь Өмет,
Гомер буе ымсындырып.
Кеше өчен Өмет —
Буй җитмәс бер йолдыз кебек.
Омтыласың,
талпынасың,
ашкынасың...

Бер көн килеп.
Йолдыз үзе синең янга төшәр кебек!

Әй, син Өмет!
сүнмә генә,
Яшә шулай ымсындырып,
Яшәү өчен гомер буе Өмет биреп
«Мәдәни җомга»!
Син дә минем якты Өметем -
Күгемдәге йолдыз,
чын ашкан хыял!
Мин сине озак,
бик озак көттем.
Якты Өметем!

Әлмәт районы,
Габдрахман авылы.

У л бик танылган, мәшһүр язучы үзе Күп эшли, пьесасын да яза, романын да яза, телевизордан да гел-гел сөйләп тора Кы... эшли дә эшли Кырык ел эшли Җәмгыятькә ...шулай тугры хезмәт итә торгач, ул бер машина... акча җыйды Аны җәмгыятебезнең ышанычлы ...к кассасына салды Хәзер инде касса димиләр, ...к банкы, диләр, янәсе, алай абруйлырак, дәрә...рәк була

— Шекер, — диде мәшһүребез — Пенсиягә чык... машина алырмын, рәхәтләнеп кайта-килә авыл...ермен

Машиналы булдым дигәндә генә, типтә бия гәр... акча кинәт үзгәрде дә куйды, мәшһүребез шул ...сумын учлап калды, янды урыс акчасы, җәм...ебезнең абруйлы саклык банкы акчаның үз ...мәтен саклап калалмады Кырык ел ипрәеп эш... жилгә очты язучыбызның. Соеклс җәмгыяте... ...ыртып талады бичараны Аннан соң илле сум... ...арны җыям дип, җәмгыятебез мәшһүребезнең ... акчасын да үзләштерде, язучыбыз ерак коман...када иде, үзе югында иллелекләре дөрләп янып ...те.

...йгырмады язучыбыз, йөзәр мең яндырганнар ...лды бит Шуннан соң көр күңелле мәшһүребез ...югында «Урал» матае алырга акча җыя баш... Ләкин бу хыялы да, һәр ай саен акча кыйммәте ...а торып, челпәрәмә килде Җәмгыятебез аны ...е тапкыр үкертеп талады Талый да талый хө...т талыкны. Каравыл кычкырыр идең, ишетмәс...ьонки сакта-каравылда торучылар да хөкүмәт... бит Ишетсәләр дә, файдасы булмас иде, утыр...уюлары ихтимал Дәшмәде мәшһүр, җәмгы...ы өчен шәп әсәрләрен яза торды Ләкин ул ...әрен ни җәмгыятькә, ни хөкүмәткә кирәге юк Ул әсәрләрне чыгарырга кәгазь юк, аларны ...у өчен язучы үзе акча табарга тиеш икән Йөз ...китерсән, китаплы буласың, шәп бит, әй!

— Ю-ук, — диде мәшһүребез — Йөз лимун тап...мен китап чыгармас идем, илле лимунын хатын...ереп, калганына машина алып, авылга китәр ...м

...балмады мәшһүребез йөз лимунны, йөз лимун ... ике-өч әфлисун да юнәтәлмәде

...ннан соң ул да таларга уйлады

— Хөкүмәт мине күпме талады, мин дә хөкүмәтне ...йм, — дип тәдбир кора башлады

...вод-фабрикага аны якын да китермәделәр үз ...үтел. Вак кибетләрне шарагалардан сакларга ...ыр иде, беләк нечкә, йодрык бәләкәй Алып...ыкка китәр иде — хәйләсе юк, аннан соң ул ...олы яшьтә, бер елдан пенсиягә. Шулай итеп, ул ...нең бер очыннан икенчесенә йөреп пенсияле ...өчен эш эзләргә тотынды Ләкин юлда йөрер... ...аның акчасы юк иде, таланган язучыбыз трам... бүш йөреп, хөкүмәттән үч алырга булды Та... ...ек таларга, түләмичә транспортта йөрергә

— Нигә йөрмәскә! Хөкүмәткә мин бер машина, ...атай, күпме иллелек бүләк иттем, ул акчага мин ...з ел бушка йөри алам! — диде мәшһүр

...ннан соң ул, куян булып, гел бушка йөри баш... Төкерми дә Бушка йөрүне ул фәнни-психоло...есенә корып җибәрде. Һәм билетсыз йөрүнең ...ычлы биш ысулын ачты

...енче ысул. Тыныч кына трамвайга кереп уты... Рәхәтләнеп барасың. Төшәргә вакыт җиткәч,

Көлсәң — көл, көлмәсәң — ела!

алгы ишеккә елышасың Ишеккә терәлеп басма Чыгар-чыкмастай, бер урында кал Ишек ачылып, тикшерүчеләр күренсә, мин әле чыкмыйм, дигән кыяфәттә бераз читкә кит Ул арада кешеләр төшәр, ишекләр ябылыр, трамвай китеп барыр, син алгы тукталышта төшеп, бер аралыкны кирегә, җәяү барырсың Аның каравы, ыштырафтан котылырсың.

Икенче ысул Иркенләп трамвайда барасың, билетсыз инде, әлбәттә .. Төшәр вакыт җитә Арткы, урта ишекләрне ачмыйча, алгы ишекләрне генә ачып, вагон йөртүче билет тикшерә Бер дә каушама Сабыр гына көт Урта ишектән бераз читтәрәк тор Кешеләр төшеп беткәч, урта ишек барыбер ачылачак, чөнки ишекнең тышкы ягында утырырга теләүчеләр күп. Ишек ачылуга ялт кына чыгып өлгер Аллаһу

Ыштыраф

әкбәр!

Өченче ысул Тикшерүче яныннан узганда сул кулыңның имән бармагы белән үң инсәң аша арттан чыгып килүчеләргә күрсәтеп

— Анда, хатында! — диген

Чыннан да, артта ике билет тотып төшәргә торучылар һәрвакыт була Тикшерүче арттагыларга караган арада, син күр дә, мин күр — син инде иректә

Дүртенче ысул Трамвайга утырырга дип, син алгы ишек янына бас, трамвайдан төшүчеләрне сабыр гына күзәт Ике бармагы белән чеметеп билет тоткан балалар кулыннан, тиштерелгән, әзер билетны җәлт кенә тартып ал да трамвайга кер Кесәңдә кампастирланган әзер билет Эчтән генә җырлап бара бир

Бишенче ысул Тикшерү катгы, баягы ысулларны кулланып булмый, ди Син, яна торган урман уртасында калган шакалдай, бөтереләсең, ут йотасың Сабыр! Тынычлан! Алгы ишек янына килеп сөял, ишек янында тишек билетларны ташлар өчен куелган калай кесә бар Анда бик күп кулланылган билетлар ята Башкалар өчен «кулланылган», синең өчен бик кыйбат алар, берсе ун мең, кырык мең сум булыр Имән бармагың белән урта бармак арасына шул билетларның берсен кыстыр да җәлт кенә төшә башла Син — билетлы Алырга мөмкинлек булмаса, син иң өстә ята торган билетның нумирын хәтерләп ал, әйтик, утыз өч мең алты йөз сиксән дүрт. Трамвайдан төштең. «Ваш билет?!» — дисәләр

— Теге тимер кесәгә салдым! — диген.

Гауга башланса

— Хәтта нумирын да юл буе укып килдем, ышанмасагыз, әнә актарып карагыз утыз өч мең алты йөз сиксән, — дип кычкыр

Гафу үтенә-үтенә сезне ыштырафсыз иреккә җибәрерләр

Искәрмә билет саны тулысы белән күренмәсә, соңгы нумирлары да ярый

Бетте-китте!

Әнә шулай итеп, мәшһүребез хөкүмәт талап алган үз акчасы хисабына бушлай трамвайда йөри торгач, үзенә эш тапты Ул «Трансстройпромтрест»ка каравылчы булып урнашты Мафия, рэкет малайларга тимер капка ачып торырга

Икенче көнне эшкә барганда, трамвайдан төшәргә аягын атлаган гына иде, тикшерүче хатынны күреп, җәлт кенә аягын кире алды, янәсе, ул төшми икән әле Әлеге тикшерүче мөлаем карап

— Әйдә-әйдә. Фәлән абый, язучыларның хәлен бик яхшы беләбез, төш, сиңа ыштыраф салмыйбыз!

— дип көлде

Чыннан да, мәшһүр булуның да кайчак файдасы тия икән каһарманыбыз бу юлы да җиңел котылды. Мөлаем хатыннан ераклашкач, мәшһүребез тыела алмыйча үкси башлады Бу жылауның сәбәпләре икәү иде Беренчесе — горурлык менә ул нинди шөһрәтле, хәтта аны трамвайда да, урамда да таныйлар, икенчесе — куркып, коты алынып та җиңел генә котылудан иде, нервылар беткән, ел буе билетсыз йөр әле син Нибуч жыларсың!

Аны мәшһүрлеге шулай кочкара килде Танымаганнары аның ап-ак сакалын хөрмәт итепме, әллә карт пенсионер дипме, билет сорамыйча гына уздырып җибәргәләделәр

Әмма бер көнне язучыбызны әнә шул мәшһүрлеге харап итте Тәки тоттылар бит үзен Тоттылар да, таныдылар да

— Әһә. Фәлән абзый, телевизордан бәк оста сүлисең, күрсәт билетыңны! — диде усал бер хатын

Билет юк иде

— Аһ, кабахәт! — дип кычкырды тикшерүче татар хатыны — Әрәмтамак! Балаларны алда син телевизордан, ә хөкүмәтне талама Черек интеллигент Сез, язучылар, үзегезне жирнең киндеге, дисез инде Ә үзегез хөкүмәт кесәсенә керәсез, халык жилкәсен кимерәсез Бушлай трамвайда түләйт итәсез! Сез түгел жирнең киндеге — без! Түлә ыштырафыңны, язучы тәре!

Тирә-юньдәгеләр мәшһүр язучыны танып, аңа ярдәм итәргә теләде Кемдер

— Ул бит язучы, — дигән иде, әлеге хатын

— Беләм мин аның кем икәнен! — дип акырды

— Телевизордан үзен әллә кемгә куеп сөйләнгән була, үзе хөкүмәтне талый Давай ыштыраф!

— Ыштырафлык акча юк иде Өендә дә юк Каравылда торганы өчен әле хезмәт хакы алмаган. Аны тартгкалый-тартгкалый автобуска алып керделәр Язучы эш урынын әйтмәде, чөнки ишетелә калса, бу эшеннән дә колак кагачак иде

Мәшһүребез язу машинкасын сатып ыштыраф түләргә мәҗбүр булды Гомер буе үзенә тугры хезмәт иткән язу машинкасын сатып, ыштырафын түләп кайтып килгәндә, аны тагын тоттылар, кесәдәге соңгы мая, машинкадан калган акча да ыштырафка китәчәген уйлауга, мәшһүребезнең сул күкрәгендә нидер чәнечте, ул тикшерүчеләр өстенә авып төште.

Пенсиягә җитә алмады, бахыр Авыр туфрагы җиңел булсын! Урыны җәннәттән әйләсен!

А.ТАТАР.

Куян күчтәнәче

— Тәмледән тәмле ни тәмле? Татлыдан татлы ни татлы?

— Белөбез-беләбез — бу сорауга һәркайсыбыз үз җавабын әйтеп бирер. Кемдер уйга калыр, кемдер балачакны, татлы булып тоелган ризык-нигъмәтләрен искә төшерер. Һәм алар арасында, әлбәттә, әти-әниләр кырдан-басудан алып кайткан «куян күчтәнәче» дә булыр...

Шундый бер күчтәнәчне безнең редакциягә, чак кына элегрәк, «Салават күпере» журналы алып килгән иде. Ә бүген менә — «Барабашка» журналыннан күчтәнәч.

* * *

...ем дәресе. Укытучы укучыны кисәтә

— Мин бит сиңа рәсемеңдә сәяхәтче-туристның ...аның палаткасын ясарга кушкан идем, ә син ...ка гына ясагансың!?

— Туристы палатка эчендә бит, әнә, борыны ...күренеп тора!

* * *

— Кайсысы безгә якынрак урнашкан — Ай-... Африкамы?

— Ай, әлбәттә!

— Ни өчен?

— Ай күренеп тора, Африка күренми...

* * *

...е малай үртәшә

— Ишәк син! — ди берсе.

— Мин ишәкме?! — дип ярсый икенчесе.

— Соң син хәтта ишәккә дә охшамагансың!

— Минме?! Мин ишәккә охшамаганмы? — ди ..., тагын да кабыныл.

* * *

...р малай күрше кызына әйтә:

— Мин синең яныңнан мәңге китә алмам инде...

— Чынлапмы?!.

— Соң, ничек китим, син минем аякка басып ...ың бит...

Эротика кайчан туган?



Нинди генә бәхәсләр тудырмый ул бу җиһанда. Борынгы чорлардан ук килеп, кеше тәненең гүзәллеген җырлаган антик чорлар аша узып, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән дә, һаман да тынгы бирми, һаман дә бәхәс кузгата. Кемнедер сокландыра, кемдәдер нәфрәт уята. Кемнәрнедер дәртләндерә, кемнеңдер йөрәк ярасын кузгата.

Инде ярый, без фәкыйрьләрегез генә шулай бәхәсләшсәк-үпкәләшсәк, дәртләнсәк-нәфрәтләнсәк — бер хәл. Әле бит бу хакта зур-зур галимнәр, шактый ук зиһенле адәмнәр баш вата, бәхәсләшә: эротика кайчан туган? Бу сорауга, менә, табигать, әйтерсең лә, үзе җавап бирә: җир куенында үскән бу кишер гүзәл бер хатын-кыз аякларыннан нәрсәсе белән ким? Хәер, эрос сүзе безнеңчә дәрт дигәнне аңлата. Ә дәрт — табигатьнең үзеннән килә...



Мин Төркиядә, Истанбул шәһәрендә, 1915 елның сентябрь аенда — әти-әниемнең юл сәфәре вакытында туганмын. Никахлашканнан соң хаж кылырга сәфәр чыккан әти-әнием, Беренче бөтендөнья сугышы башлану сәбәпле, Төркиядә тоткарланып калган. Хәер, бу хакта да, Троицки шәһәрендә ничек үсүем-яшәвем, алга таба ниләр күрүем хакында да мин «Ишан оныгы» исемле әсәремдә җентекләп язып чыккан идем.

Белмим, минем тууым турында хат-хәбәр Төркиядән Троицки шәһәренә шактый соңарып килгәнме — һәрхәлдә, Зәйнулла бабам (Зәйнулла ишан) метрикә кәгаземне 1916 елда туган дип яздырган.

Бу яңа романым «Тыныч еллар күләгәсендә» дип атала, һәм мин инде бу юлы әдәбиятка ничегрәк килүем, нинди киртәләр-каршылыклар аша узуым турында сөйләргә теләдем.

Укучы аңлар: 1941 елның октябреннән 1945 елның ноябренә кадәр армиядә булган, фронттан язылган һәр әсәрен диярлек газета-журналларда бастыра килгән бер каләм иясе әдәбият, фән мәйданына «ишан оныгы» дигән мөһер тагылган хәлдә килә...

Менә шул романымнан бер өзекне бик тә рәхәтләнеп «Мәдәни җомга» укучыларына тәкъдим итәм.

АВТОР.

Атилла РАСИХ

Тыныч еллар

(Әсәрдән

Көз башланган иде, ахры. Мине, көтмәгәндә, партиянен өлкә комитетына чакырдылар. Дөресен әйтергә кирәк, мин башта шомлана калдым. Нигә кирәк булганмын мин партия органына? Ай-һай, берәр хатәр эш кузгатырга теләмиләрме? Әмма шулай да, һич сер бирергә теләмәгән хәлдә, анда барам, милиционердан, паспортымны күрсәтеп, пропуск алам. Һәм мине ни өчен чакыртканнарын белгәч, аптырап калам. Мине чакыртучы бүлек мөдире Камил Фасеев атлы кеше икән. Ул миннән, Әмирхан Еники дигән язучының иҗатына анализ ясап, шул язманы үзләренә тапшыруымны сорый.

Мин Әмирханны шәхсән белми идем әле ул чакны. Әмма, аның журналда басылган бер хикәясен фронтта чакны укып, бик сокланган һәм чын күңелдән бездә шундый шәп хикәяче тууына шатланган идем. Ул «Ялгыз каз» дигән кыска гына бер хикәя иде. Инде укыганга ярты гасыр вакыт узган булса да, хикәя әле дә хәтеремдә. Мин Фасеевның үтенечен кире кага алмадым. Минем өчен ул талантлы язучының иҗаты белән танышу үзе генә дә бер ганимәт иде. Әмма, өйгә кайтышлый ук, уйга калдым. Хуш, мин аның әсәрләрен, китапханәдән алып, аларга анализ ясадым, ди, авторга әйтмичә генә кульязманы Фасеевка илтеп бирдем, ди. Бу соң үзенә күрә бер оятсызлык булмасмы? Юк-юк, мин андый эшкә бара торган кеше түгел. Барысы да ачыктан-ачык булырга тиеш. Уйладым-эшләдем. Шул ук көнне Әмирханны эзләп таптым, өлкә комитеты тарафыннан үземә нинди эш тапшырылганлыгын әйттем. Болай сөйләштек: мин, аның әсәрләрен укып чыккач, аңа үземнең фикерләремне бәян итәчәкмен. Инде ул минем тәнкыйтем белән килешми икән, аның аңлатмаларын һәм аларны нигезләвен мин игътибар белән тыңлаячакмын. Шуннан соң бер уртак фикергә килгәч, анализымны язып, Фасеевка тапшырачакмын.

Минем барысын да ачыктан-ачык әйтүемне Әмирхан яратты һәм без шул көннәрдән башлап таныш кына түгел, якын дуслар да булып киттек. Хәер, бер нәрсә аңа ошап җитмәде-җитмәвен. Ул да булса — мин үзем язган анализымны аңа укытмадым. Мин болай уйладым: әгәр аны укытсам, бу Әмирханга артык ярарга тырышу булачак, инде бу башкаларга да ишетелсә, минем анализның ямаганаты таралачак.

Ярар, Әмирхан бу бәләкәй үпкәне йотты. Күрәсен, ул үз иҗаты турында мин начар сүз әйтермен дә, моның күңелсез нәтиҗәләре тиздән калкыр дип борчылгандыр. Андый хәл булмады һәм безнең дуслык җепләре көннән-көн ныгый барды. Әлбәттә, монда Әмирханнарның безнең урамның бер очында яшәве дә ярдәм иткән булса кирәк. Без еш кына, бер-беребезгә кергәләп, озаклап әдәбият, тормыш хәлләре турында сөйләшә, фикерләр уртаклаша торган булып киттек.

Әмирхан сөхбәтләшеп утыру өчен бик күркәм кеше булып чыкты. Тыныч кына сөйләр, сүзенә җиңелчә юмор кыстырып җибәрер, әмма үзе һич тавышланып көлмәс, елмайса да, матур итеп, ирен читләре белән генә елмаеп куяр. Аның миңа әчкерсезлеге һәм үз генә дә язган сүзгә юл куймавы барлык ачы хакыйкатьне, хәтта үзе турындагы чатак нәрсәләрне дә яшерми торган холкы ошый. Ул әсәрләрен бик озак, һич иренмичә кайта-кайта яза, күчерә. Күп очракта язылачак җөмләне башта кечкенә аерым кәгазь кисәгенә төшерә. Бу вариант ошамаса, аны яңадан аерым кәгазьгә яза. Инде, ниһаять, үзе теләгәнчә килеп чыкса, ул җөмләне кульязмага күчерә. Аннан, әсәр төгәлләнгәч, ул әле аны тагын бер нык таң «сөреп» чыга. Кыскасы, язучы һәр әсәренә бик зур хезмәт куя. Әмма аның язганнарын ортодокс тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият дилбегәсен үз кулларына алган түрәләр яратмый, аны шәп стилист буларак хупланган хәлдә дә, идеологик чатак әсәрләр яза, дип, үсәргә юл бирмиләр. Әмирхан мондый гаделсезлекне авыр кичерә. Күрәшә, үзенең хаклы булуын исбатларга тырыша, мәгәр һәр әсәрен артык авырлык белән уздыра. Шуның аркасында аның матди хәле дә җиңел түгел. Безнең танышу көннәрендә ул бер учреждениедә дә эшләми, язучының кәсебе белән генә көн күрергә тырыша иде.

Сугыштан кайткач, Әмирхан радиокомитетта редактор булып эшләгән. Берничә елдан соң әле ниндидер техникумда татар теле дәресләре дә укытып йөрде. Ләкин, хәтерем ялгышмаса, ул анда да бер-ике кыш кына укытты. Әмирханның әтисе Нигъмәтҗан абзый исән иде әле ул чакта. Бу карт ифрат дәрәҗәдә кызык булып истә калган. Аның белән Әмирханнарда бер мәҗлестә утырган вакыт хәтердә саклана. Чандыр, елдам Нигъмәтҗан агай ул чакта бик кызыклы вакыйгалар сөйләде, хәтта җырлап та күрсәтте. Кыскасы, бик күңелле итеп, шаярып-көлеп мәҗлес күрке булып утырды. Әмирхан исә әтисенең бу активлыгын өнәми, аны тыярга тырыша. Тик без кунакларга картның мәҗлесне шулай җанландырып утыруы бик күңелле...

... Беренче романымны язам. Күз алдыма үземнең яшьлегемне, заводта токарь булып эшләгән чакларымны китереп бастырам. Шулай ук минем алда сабыйлык елларым узган шәһәрем җанлана. Андагы мин белгән кешеләр, бергә уйнап үскән малайлар — барысы да, яңадан терелеп, минем әсәремә керергә ашкыналар. Мин язу, иҗат итү рәхәтеннән исерәм, узган тормышның кыек, ямьсез яклары да хәзер мине рәнҗетми. Әдәби хезмәт, һәр эш кебек, бик уйлап эшләүне, салкын канлылыкны ярата. Мин язам. Тик шулай да ара-тирә күңелдә икеле-микеле уйлар туганлый. Әйе, мин язуын язам, әмма дөрес юлдан барамммы соң? Тәҗрибәлерәк кешеләр белән киңәшәсе иде. Беләм бит мин, безнең көннәрдә әдәбият кысалары ифрат та тар, өстәвенә, бу бит әле минем зур әсәр язуда беренче тәҗрибәм.

Шундый фикер белән үземнең максатларым турында язучылар белән киңәшеп алырга кирәк дигән карарга килэм. Карар кылдым, гамәлгә ашыра да башладым. Язучылар берлегендә сөйләшеп, язылып ята торган романым турында киңәшүне көн тәртибенә куюларын үтенәм.

Ул көннәрдә инде армиядән кайтырга тиешле әдәбият әһелләре барысы да Казанда иде. Менә, сөйләшү көне дә килеп җитте. Байтак кеше җыелган. Хәтта Мәскәүдән вакытлыча Казанга кайткан Әхмәт Фәйзи дә утырышка килгән.

Мин башта укыйм, аннан булачак вакыйгалар турында сөйлим. Хәтердә шулай саклангай: тыңлаучылар булачак әсәрне бик җылы кабул иттеләр, әсәр укыр өчен бик кызыклы булачак, диделәр. Тик партиянен ролен тагын да ачыграк итеп күрсәтергә кирәк дигән фикер әйтелде. Аннары шундый киңәш тә булды: олы туганыбыз — урыс халкының ролен тагын да калкурак чагылдырырга кирәк икән.

Әсәр җылы каршы алыначак, дип уйладым. Мин татар язучылары арасында сугыштан соң беренче роман язучы. Яшибез болай булгач!

Тик миңа тиздән роман язуны туктатып торырга туры килде. Институттагы эш, кандидатлык минимумын тапшыруның авыр, зур йөк икәнлеген мин бик тиз аңладым. Учхоздагы ветврачлык эшен ташларга туры килде. Мин аннан кайбер азык-төлекне дә арзан бәягә алгалый идем бит. Хәзер ул юк. Хәерле булсын, бик авыр булса да, аспирантураны тәмамлап, диссертация якларга кирәк. Тагын мондый яңалык та булды бит әле: гыйльми хезмәткәрләргә эш хакын арттырдылар. Болай сөйли халык: янәсе, бу эшкә америкалыларның Хиросима белән Нагасакига атом бомбасы ыргытуы сәбәп булган. Сталин бабайның күзе, ниһаять, бездәге галимнәрнең фәкыйрь тормышларына төшкән.

Өнием безгә, булдыра алганча, Әстерханнан акча җибәреп тора. Мин аның ярдәменнән баш тарт[…] алмыйм. Башка килер җир юк бит безнең. Хатыным Зәкия авырый, өстәвенә, балалар багу аркасында, беркайда да эшли алмый. Әйе, авыр, ашау ягы такы-токы, еш кына бурычка керергә туры килә.

Алай да беренче кышым бушка узмады, мин чит телләрне, программа таләп иткәнчә үзләштереп, имтиханнарны тапшырдым. Инде яңадан тугыз фәннән имтихан бирәсе калды. Мин баш-аягым белән фәннәр дөньясына чумам. Ә өйдә хәлләр бер дә мактанырлык түгел. Зәкия тагын балага узды, авырый, ябыкты. Улыбыз Илдарга да тиешле тәрбия юк. Минем дә тамак һаман төзәлми, йод-глицерин һәм стрептоцид кулдан төшми. Авыруның һич чиренәсе килми. Инде котылдым, чир бетте дисәм, тагын яңадан да әшәке булып башлана. Мин ахырда хәтәр бер эксперимент ясарга булам. Тамак шешкән, тәнем ут булып янган хәлдә учхозда гекә ярдан Казансуга сикерәм. Янәсе, йә мин бетәм, йә авыру бетә. Һәм искитмәле хәл: мин икенче көнне үк үземне сау-сәламәт сизәм, ләгънәт төшкере тамак чирен Казансуның суык суында калдырам. Шулай үземнең сәламәтлегем өчен көрәшәм.

Сынауларны уздыргач, диссертация язып, аны якларга, гыйльми дәрәҗә алырга тиеш мин. Уемча, шулай иткән очракта гына барлык төеннәрне чиш[…] алачакмын. Тик шулай да эш өзелгәли, әледән-әле колхозларга чыгарга туры килә. Авылларның хәлен күреп торам. Күрәм андагы халыкның интегүен, күрәм белгечләрнең нинди газаплар кичереп колхо[…] эшен юлга салырга тырышуларын. Аерата терлекчелек авыр хәлдә. Ни өчен шулай? Чөнки терлекчелек ул — һәр көнне бик зур игътибар сорый торган җанлы организмнар өлкәсе. Ә колхозчы а[…] дый игътибарны биреп җиткерә алмый. Дөресрәге, булдыра алмый, чөнки — теләми. Теләми, чөнки аңа хезмәт көне урынына бары әлиф таяк кын[…] эләгә.

Авылдагы хәлләр әйтеп бетермәслек алама. Мин моны сугышка кадәр үк, җир эшләре комиссари[…] атында хезмәт иткәндә үк белә идем. Шуның нәти[…] җәсендә мин үземнең сатирик әсәрем — «Каһә[…] төшкән тел»не яздым да бит! Ләкин мин ул чакт[…] һәм әле сугыштан соңгы беренче елда моның сәбә[…] бен дөрес бәяли алмадым. Пәрәү авылында бу ту[…] рыда кайнатам Әхмәт Бәдигов белән бәхәскә кер[…] емне хәтерлим. Ул Пәрәүдәге колхозның хәлләре[…] бик ачынып сөйләде. Мин исә бу эштә колхозч[…] гаепле дип дәгъвалладым, янәсе, ул юри колхоз эше[…] нә бойкот игълан итә. Мин ул чакны партиянен һә[…] эше дөрес дип уйлаучы бер зат идем. Партиянең, ягъни Сталинның һәрбер гамәлен дөрес дип табучы[…] тугрылыклы шәкерте идем. Шулай булмый хәлем д[…] юк. Мине бит совет мәктәбе, комсомол тәрбияләд[…] Без бит фронтта Сталин өчен үлемгә барырга әз[…] торган солдатлар идек.

1948 елның җәен без Зәкия белән бер айга якы[…] институтның өйрәнү хуҗалыгы янындагы Шуш[…]

…урыс авылында уздырдык. Янәсе, ял итәбез …ий. Хәлбуки, моның исеме генә ял иде. Без бер …зак карт маржаның өендә яшибез. Аш-суны …з әзерлибез. Зәкиянең соңгы ае, без икенче ба…ны көтәбез. Ярый әле Казанга кунакка кайт…, озакламый икенче бала булачагын исәпкә …, үзе белән улыбыз Илдарны Әстерханга алып …

…нкүрешебез ни кадәр генә мәшәкатьле булма… Шушарда яшәгән көннәр якты бер истәлек …рган миндә. Зәкиянең йөзенә ул сәламәтлек …е кертте. Ни әйтсәң дә, биредә икмәк белән …ге генә түгел, саф авыл һавасы да бар. Без һәр …е иртән яшел болын аша Казан елгасына су …гә барабыз. Коенгач, күтәренке кәеф белән, …ый-җырлый, үз куышыбызга кайтабыз. Җыр…ыгәннән, Зәкия бу эштә маһирләрнең маһире. …ты яшеннән үк туган-тумача арасында шәп …авы белән дан казанган кыз. Мин аның Яңа …дәге мәчеттән клубка әйләндерелгән бинаның …ендә әле 29 нчы елны ук җырлавын ишетеп …лган идем.

…е, без шулай һәркөн иртән су коенгач, җыр…ырлый үзебезнең куышыбызга кайтабыз һәм … эш башлыйбыз. Зәкия мич янында кайнаша, …сә язарга утырам.

…че сентябрь кереп, институтта укулар башлану … мин диссертациям өчен сынаулар уздырырга …ттем. Экспериментал эш атлар белән башка…ак. Ат дигәннән, мин сугышта да, дүрт елга … шул гаҗәп гүзәл, акыллы һәм түземле җан … белән эш иттем. Мин аларны яратам, ул …сәкләрем миңа бала чагымнан ук таныш. …штан ук сөйләшү буенча, сынауларны авыл

…күләгәсендә

(…ек)

…гы институтының өйрәнчек хуҗалыгында …ачакмын. Моңа ул хуҗалыкның директоры … Юлмитев ризалык бирде. Юлмитев дигән… кеше турында кыскача гына булса да язмый …лмыйм. Чөнки ул, минемчә, моңа бик лаек. …ка кадәр, мин әле студент чакны, безнең фа…т авыл хуҗалыгы институты карамагында …м без шул хуҗалыкта, 2 нче фермада яшәп …к. Ул чакта да хуҗалыкның директоры шул …жип Юлмитев иде.

…жип абыйның үзенчәлеге бар: ул үтә туры … әйткәнен үтәми калмый, ифрат үҗәт һәм … кергән һәрбер яңалык белән мавыгучан. …л мавыгучан, ифрат та тырыш, булдыклы, …ан да тиккә бармагын селкетмәс һәм, өстә…енең хезмәтен барлык нәрсәдән өстен саный. …п елларында тәмам тузган, хәерчегә әйлән…әмә хуҗалыкны ул фронттан кайту белән үз … ала һәм бик тиз арада аңа җан иңдерә. Эш …, гөрли башлый. Тик шулай да бер бәхетсез…галап торган була аны. Күрәсең, ул сугыш …ның бер әшәке бүләгедер — Мөҗип әчкече…ерелә. Хәл шул дәрәҗәгә җитә, аракы аның … бер тисә, атна буе сәрхүшләнеп ята. Бил…е, әйбәт сыйфатларын ни кадәр хөрмәт …әр, аның бу алама гадәтен гафу итә алмый. …һаять, югары оешмалар аны директорлык… … ташлыйлар. Юлмитев нишли соң? Мон… … һич риза булмый, инде хуҗалыкка яңа …р тагаенләнгән һәм эшли башлаган булуына …тан, ул һәр көнне, нәкъ элеккечә, иртә таң…дә чыга, нәкъ элеккечә, хуҗалык хәлләре …нышып абзар-кура, остаханәләрдә була, …рага кергәч, яңа директор белән янәшә бер … янына утыра. Йомыш белән кергәннәргә …рсәтмәләр бирә. Һәм, минем белүемчә, мо… бер атна гына да, ике атна гына да дәвам … директор, бу мыскылга түзмичә, хуҗалы…ап китә. Югары оешмалар Мөҗипне яңа… урынына утыртырга мәҗбүр булалар.

… шул кешенең рөхсәте белән, диссертациям … тәҗрибә эшенә керештем. Мөҗип абыйны … киләчәктә үземнең «Ике буйдак» исемле … бер прототип итеп алачакмын. Тыштан … һәм дә күзенә карап турысын әйтергә яра…рдәм Юлмитев минем хәтеремдә шулай …

…л чакта әнә шул фермада сыерларны ясал…ландыручы ветфельдшер өендә яшим. Әм… яшим дип әйтү дөреслеккә туры да кил… Мин ат абзарында яшим. Таңнан кара төн…р янында мәш киләм. Ат абзары һавасын …әдә үзләштердем ки, хәтта өстемдәге … пальто мүктәй саргылт-көрән бер төскә …н атларымны бик төгәл, норма буенча …ам, ашаткан азыктан химик анализлар …рымның тизәгеннән дә анализ алып то… көнне, шприц белән, атларымның бөят

тамырыннан кан суыртам. Шундук, махсус ысул белән, аны анализлыйм. Атларымның көн дә күпме эшләгәнлекләрен, ничә килограммометр хезмәт башкарганлыгын динамометр белән төгәл исәпкә алам. Кыскасы, минем эш муеннан, өлгер генә. Ниһаять, бу коточкыч хезмәт көннәрдән бер көнне тәмамланды. Инде Казанга Кыш бабай да килеп җиткән, абайламаганмын да. Хәзер инде миңа, бик төгәл итеп, кафедра лабораториясендә анализлар уздырырга кирәк. Бусы да хәлиткеч, бик җитди эш. Чөнки эшемнең нәтиҗәсен шул билгели. Монда инде ялгышмаска кирәк. Егәреңне һәм күз нурларыңны һич кызганмыйча тырышырга кирәк. Мин иртә таңнан институтка китәм, өйгә төнлә генә кайтам. Ә өйдә хәлләр шәп түгел. Вакытыннан алдарак картайган кайнанам өй эшләрен башкара алмый, ә хатынымның кәефе юк. Ул җәй уртасында миңа бер кыз бала бүләк итте, шуннан бирле ныгый-савыга алмый.

Ә миңа барысына да өлгерергә кирәк. Минем роман төгәллисем бар. Алда тагын бер хәтәр нәрсә тора. Ярар, мин эшемне төгәлләрмен, язган диссертациямне якларга туры килер, шул чагында әтиемнең Әстерханда мулла булып торуы миңа зыян китермәсме соң? Кайбер таныш язучыларым кырын карый башлаганны, бу хәлгә институт әһеле башкача карар дип уйлыйсыңмы? Әйе, эшнең ни белән бетәчәген белеп булмый. Минем тырышлыкларымның хәтәр төгәлләнүе мөмкин. Бик ачык сизәм, яңадан 37 нче ел җилләре исә илдә. Ишетелеп тора, әле бер кешене, әле икенчесен кулга алганнар. Әле кайчан гына соң шагыйрь Шәйхи Маннурны, «Тартай арбасы» исемле мәсәле өчен дау куптарып, һич булмаган гаепләр тагып, үзен зур җыелышта эт

урынына сүктеләр. Янәсе, син безнең җәмгыятьтән көләсең. Мин ул җыелышта булдым, академия филиалының зур залында йөрәккә дәһшәт суыгы йөгерә, репрессия елларының сулышы айкала иде.

Әйе, шулайрак шул менә. Эш хөрти. Мин әтигә хат артыннан хат юллыйм. Аңа бу эшенең кирәксезлеген аңлатырга тырышам. Бер авызың пеште бит инде, җитәр, син бит үзең дә дингә артык бирелгән фанатик түгел, синең менә дигән гражданлык һөнәрләрең бар, кайт, ничек булса да яшәрбез әле, дип язам.

Көннәрдән бер көнне әнием белән әтием Әстерханнан кайтып төштеләр. Ләкин бу бөтенләйгә кайту түгел икән әле. Аларның кайтулары улыбыз Илдарны өенә, әти-әнисенә тапшыру һәм икенче балабызны, оныкларын күреп китү өчен икән. Мин әтиемне күреп шаккаттым. Сакал җибәргән, өстенә җөббә кигән, башында түбәтәй, менә дигән мулла. Ә әнием тазара башлаган. Бичара, ачлык елларыннан соң тук тормышка таргач, бөтенләй башка кыяфәткә кергән. Хәер, моның сәбәбе авыруыннан булса кирәк. Ул, кайчаннан бирле инде, кан басымы белән газаплана.

Мин аларга үземнең эшләрем турында сөйлим, сүзебез аларның Казанга кайтырга тиешлеге турында башлана. Бәлки, бу бер караганда эгоизмдыр, минем бары үз карьерам турында кайгыртуымдыр. Мин аларның, Казанга кайткач, фатирсыз да, килерсез дә каласын аңламыйммыни? Әтинең пенсиясе бөтенләй юк, әнием инвалидлык пенсиясен аена бары кырык сум гына ала. Тик мин бу очракта киләчәктәге хезмәтемнең дәрәҗәсе илгә, халыкка кирәк булачагы белән генә үземне аклый алам. Әгәр миңа гыйльми хезмәткә һәм әдәби иҗатка юллар ачылса, мин илгә генә түгел, әти-әниемә дә кирәкле икътисади ярдәмне күрсәтә алам ич.

Әни фикерләрем белән килешә, ул үзенең әтине һаман Казанга өндәгәнлеген әйтә. Әти исә эндәшми, бер ноктага текәлгән килеш, борын тарткалап кына утыра.

Алар тиздән Әстерханга кайтып киттеләр. Мин эшемне дәвам иттерәм, лаборатория эшләре төгәлләнгәч, диссертация язарга утырам. Ул да төгәлләнде. Кеше аспирантлык эшләреннән бераз арынды. Миңа хәзер романымны язып бетерергә кирәк. Менә, ниһаять, караламада төгәлләнде ул. Өстемә өзлексез ташланып торган авыр тормыш дулкыннары арасында язылган хезмәтем, күптән язарга хыяланып та моңарчы тормышка ашыра алмаган әсәрем туды. Менә ул минем өстәлемдә ята. Уемча, әсәр ярыйсы булып чыкты. Моны укучы тәгаен яратып каршы алачак. Ә тәнкыйть, әдәбият түрәләре? Нигә, алар да, минемчә, җылы каршы алырлар. Романның исеме «Дустым Мансур». Анда вакыйгалар беренче бишьеллык чорын тасвирлый. Завод төзелеш. Моны журнал да, нәшрият та дүрт куллап кабул итәчәк!

49 нчы елның җәендә әтиләр Әстерханнан бөтенләйгә Казанга кайттылар.

Романымны язып бетердем. Хәзер аны машинкада бастырам. Әлегә барысы да әйбәт бара. Роман, машинкадан чыккач та, журналга тапшырылачак. Ул, мөгаен, киләсе ел саннарының беренчесендә басыла башлар, бәлки, киләсе елның урталарында инде басылып та бетәр, дип уйлыйм. Роман гонорарына әниләргә бер куыш сатып алырмын, картайган көннәрендә, бичаралар, кысан бүлмәдә күршеләр белән яшәп газап чикмәсләр. Инде диссертацияне дә яклап алсам, минем эш хакым да артачак.

Мин түземсезләнеп әсәремнең машинкадан чыгуын көтәм. Эшне тизләтү өчен, мөмкин булган саен, нәшриятка машинистка янына чабам. Аны ашыктырам, аның эшен җиңеләйтү өчен сәгатьләр буе текстны әйтеп торам.

Менә бусы да булды. Әсәр машинкада өч нөсхәдә басылды. Мин хәзер, институттан кайту белән, кульязмадагы хәреф хаталарын төзәтеп утырам. Ярый, берничә көндә бу эш тә очлана. Алда инде эшнең иң татлысы тора, ул да булса — романны редакциягә илтеп тапшыру. Институттан иртәрәк кайтып, редакциягә ашыгам. Күңелем шатлык тойгылары белән тулы. Әлбәттә, әсәрне журнал шатланып кабул итәчәк. Бик әйбәт булган, диячәкләр. Тәгаен, минем әсәргә «яшел урам» ачып, аның журналда басылып чыгуын ашыктырачаклар әле, бик ихтимал, якындагы саннарга ук кертүләре дә бар. И, яшьлек, и, тәҗрибәсезлек! Әйтерсең, бездә яшь язучыны китап, журнал тирәләрендә көтеп кенә торалар!

Әйе, мин беренче зур әсәремне журналга тапшыру бәйрәмен күңелемнән бик тантаналы рәвештә уздырдым. Ләкин, ләкин башы ук ничектер мин теләгәнчә булмады әле моның, артык гади килеп чыкты. Редакциянең җаваплы секретаре, минем фронтовик дус Габдрахман Әпсәләмов кульязманы бер дә алай күтәреп каршы алмады, хәтта мине әсәремне төгәлләү белән котламады да, ничектер сәер генә итеп елмайды. Хәер, мин моңа башта ул кадәр зур игътибар да бирмәдем. Минем дус бит, гомумән, артык эмоция кешесе түгел, эчендәгене тышына чыгарырга беркайчан да ашыкмый. Бераз кәефем кырылса да, шулай үземне тынычландырырга тиеш идем. Һәрхәлдә, әсәр журналга тапшырылды бит. Минем хәзер эчемдәге янар тауларым сүрелде, мин зур эш башкарылганнан соң гына була торган рәхәт тынычлану хисләре кичерә башладым. Инде журналда эшләүче иптәшләрнең әсәрне укып чыгасы, минем көтәсем генә калды.

Мин күтәренке күңел белән тагын диссертациягә тотынам, баш-аягым белән шул эшкә чумам. Бу вакытта инде мин Сорочи базарыннан соңгы җиде йөз сум акчама иске булса да әле эшкә ярарлык язу машинкасы алып, анда эшләргә өйрәнә башлаган идем. Диссертациямне шул машинкада басам. Әле аның эше күп күбен. Диссертация басылганнан соң, җитәкчем — профессор укып чыгарга тиеш. Бәлки, әле моңарчы партия өлкә комитетында эшләгән безнең доцент Зиннур Сафич та танышып чыгарга теләр. Аннан соң мин диссертациямне кафедра хезмәткәрләре тикшерүенә куярга тиеш булам. Шуннан соң гына, инде кирәкле төзәтүләр керткәч, оста машинисткадан әйбәт кәгазьгә бастырып, төпләтергә һәм оппонентларга тапшырырга була.

Әйтүе генә ансат, юл сикәлтәле. Нәрсә көтә мине? Оппонент агайлар нинди хөкем чыгарырлар? Бәлки, барып чыкмаган бу, егет, сиңа гыйльми дәрәҗә бирерлек нәрсә түгел бу, диярләр. Аннан — әлеге дә баягы — минем маңгайдагы мөһернең үз эшен башкаруы мөмкин.

Менә диссертация дә басылып бетте. Мин аны тагын бер тапкыр карап чыгам да, профессорыма тапшырырга ашыгам. Ул озак тотмый, эшемә «кул куя», фатихасын бирә, «барып чыккан бу, Агилла Кадыйрович», дип күңелне күтәрә. Ярый, ярый, мин шат, мең шөкер. Яшибез болай булгач! Профессорның биргән бәясе ул инде, уен түгел, эш пеште болай булгач!

Тик шашма, Агилла! Әле алда хезмәтеңне гыйльми совет әгъзалары алдында яклыйсың бар. Алай бик шатланырга ашыкма, дускаем!

Әйе, чыннан да, шулай икән шул. Миңа Ходай беркайчан да уңыш дулкыннарында тирбәлергә язмаган, ахры. Чөнки, күп тә узмады, минем башка һич көтелмәгән яктан бер шапалак төште. Ул көндәлек матбугат аша булды. Адәм юрар, язмыш көләр, диләр шул. Моның шулай икәнлеген миңа урыс телендә чыга торган «Красная Татария» гәзите аңлатты. Гәзиттә сүз әдәбият турында бара иде, хосусан анда минем күп өметләр баглаган беренче романыма кагылышлы сүзләр әйтелгән иде. Һәм бу сүзләр һич көтмәгәндә минем башыма тондырылган тукмак булып чыкты.

Гәзиттәге мәкаләдә әле күптән түгел генә шәһәр күләмендә уздырылган актив җыелышы турында мәгълүмат бирелгән. Анда минем фронтовик дусның чыгышы хакында да язылган. Ул әдәбият хәлләре турындагы җөмләләрендә, минем исемне дә телгә алып, мондыйрак сүзләр әйтә: Расих үзенең беренче күләмле әсәрен тузга язмаган вакыйгалар белән тутырган иде (сүз «Бәхет орлыклары» турында бара), хәзер исә ул безнең журналга бер яшь кеше турында мәгънәсез әсәр күтәреп килгән...»

Бу юлларны укыгач, мин өнсез калдым. Сүз минем романым турында бара, «Дустым Мансур» турында бара иде.

Тукай елмая төшә

Татар опера һәм балет академия театры бинасы ныклы адымнар белән тиз-тиз коммунизм төзегән чорда салына һәм шунлыктан бу уникаль корылманың идеологик бизәлеше бик тә әһәмиятле була. Казанлылар өчен легендар булган бу бина турында кайбер мәгълүматлар җыю нияте белән мин берничә китапханәне йөреп чыктым, әмма юньле-башлы хәбәр таба алмагач, Зур Совет Энциклопедиясен (БСЭ) кулыма алырга мәҗбүр булдым. «ТТ ОБ им. М.Джалиля открыт в 1939 году», диелгән анда. Аннары төрле елларда анда куелган опера һәм балет спектакльләре санап үтелә дә текст: «Здание театра построено в 1956 году, зрительный зал на 1029 мест», дип төгәлләнә. Моны укыган һәр аңлы кешенең аңы томаланып китүе ихтимал. Чөнки 1939 елны театрны Җәлил исеме белән атау берәүнең дә исенә килмәс иде, билгеле.

Мәгълүм булганча, театр бинасын төзү нигездә 1946 елны әсир төшкән немец солдатлары көче белән башлана. Ә төзелеп бетү елы — 1956. Ул чакта инде Сталин да, әсир немецлар да юк, Муса Җәлил дә «Ватанны саткан кеше»дән Советлар Союзы Героена әверелгән. Күрәсең, театрны төзүнең ике бишьеллыкка сузылуының сере дә Сталин исеме белән бәйледер. Мәгълүм ич: 1944 елны Кырым татарларын туган җирләреннән вәхшиләрчә куганнан соң ул Казан татарлары белән дә турыдан-туры шөгыльләнергә тотына. Казан татарларын Ватанны сатучылар дип туган җирләреннән куарга нигезе булмагач, ул безне «болгарлар»га әйләндерергә тотына. Казан татарларының килеп чыгышын ачыклау сылтавы белән Сталин ике тапкыр ВКП(б) Үзәк Комитеты Пленумын җыя (1944 һәм 1946 елларда). Бу эшкә ул күренекле этнографларны, антропологларны, тел галимнәрен тарта. Хәлбуки, бу вакытка Сталинның Казан татарларыннан хәтәррәк «дошманнар»ы калкып чыга (яһүдиләр һәм космополитлар) һәм гомеренең соңгы елларында гына Сталин безне куарга кирәк, дигән фикергә килә. Бәхетебез булгандыр, Газраил безне бу язмыштан коткарып кала. Әгәр дә Сталин тагын бер ун ел тәхеттә торган булса, без болгарларга әйләнеп, илебездән куылган булыр идек, Муса Җәлил дә Герой булмас иде һәм, табигый инде, опера һәм балет театры да аның исемен йөртмәс иде. Шунысы аяныч, Сталин үлгәнгә карап, аның идеологиясе каберга кереп ятмады, һәм 1946 елны әсир немецлар башлаган театр төзелешен үзебезнең татарлар очлап чыгалар.

Казанда булмаган кешеләр дә бу бинаны һәм аның каршысындагы Ленин һәйкәлен телевизордан еш күрәләр. Театрның кешө йөрми торган тыныч урамы ягында — бөек Тукай һәйкәле, ә теге якта кин урамнарны күзәтеп бөек урыс шагыйре Пушкин күкрәгенә кулын Наполеонча куеп тора. Театрны төзегәндә Пушкин...
кай «энекәше»нән идео...
өстенлеген истә тотканнар...
теле. Әмма һәр кеше һәйкә...
нен дөрес куелмаганлыгын ә...
чөнки Тукай Казанда, үз ха...
да Пушкинның «кече туг...
«энекәше» түгел. Бу — Рус...
башка төбәкләрендә генә...
кин булган караш. Театр би...
нын әлеге милли кимчелеге...
нда озак еллар эндәшми к...
ләр. Янәсе, коммунизм кил...
тар теле беткәч, барысы да...
булып күренәчәк. Ә урыс...
Тукай — ул Тукай түгел...
хәтта «Габдулла» да...
ә «Гриша» булып калачак.

Алай да, үзгәртеп корула...
леп, татар теле 50 процентк...
үләт статусын алгач, Тукай...
процентка үсеп киткәндәй бу...
Аның һәйкәле янына кеш...
җыела, чәчәкләр дә салына...
та кайбер яшь парлар ника...
каре итеп аның янында рә...
дә төшкәлиләр. Шул чакта Т...
да елмая төшә шикелле...

Локман ЗА...

ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ

Мәче тырнагы һәм артист җаваплылыгы турында

«Республика Татарстан» газетасының 22 август санында Мнир Соколовның «Мин нигә филармониядән киттем?» дигән мәкаләсе дөнья күргән иде. Бу хакта «Мәдәни җомга» атналык басмасында да хәбәр ителде. Инде менә Татар дәүләт филармониясенең бер төркем мөхтәрәм артистлары җавап мәкаләсе белән чыктылар («РТ», 183-184). Андагы хакыйкать табылганмы? Сезнең игътибарга тәкъдим ителә торган җавап хатыннан барысын да аңларсыз дип уйлыйбыз.

Мнир Соколовның «Мин нигә филармониядән киттем?» дигән язмасы иң беренче нәүбәттә хәзерге концерт оешмасы директорына каршы юнәлтелгән. Әмма шуның белән бергә — телиме моны автор, теләмиме — анда язылганнар турыдан-туры Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә дүрт дистәгә якын гомерен биргән кешеләргә дә кагыла.

Татарстанда филармония эшли башлауга инде алтмыш елга якын вакыт үтте. Ләкин соңгы вакытта аны «фаш итә» торган язмалар күбәя башлады. «Кимсетелгәннәр» һаман да шул бер сүзләрне тәкрарлап, газетадан газетага, тапшырудан тапшыруга йөриләр.

Бераз вакыт без түздек, сабырлык күрсәттек. Каршы әйтерлек сүзебез булмаганга түгел. «Кимсетелгәннәр»нең абруен төшерәсе килмәде. Ник дигәндә, алар «адашкан» кешеләр булсалар да барыбер безнең балаларыбыз бит, дип уйладык.

Иң башта Мнир Соколов җитәкләгән «Сюрприз квинтет» ансамбленең эстрада сәхнәсенә менү тарихына күз салыйк. Заманында ул студентлар коллективы булып, «Казан сувенирлары» дип атала иде. Аның консерватория каршында оешуы өчен сөенергә генә мөмкин иде. Укытучылар да, студентларның мондый активлыгын күреп, яшь башкаручыларга ярдәм итәргә әзер тордылар. Вакыт үтте, әмма ансамбль элеккечә Санкт-Петербургның «Терем-квартет»ын кабатлаудан ары уза алмады. Ни үз мәсләге, ни уен коралларында үзенчәлекле уйнау рәвеше, ни үзенә генә хас репертуары булмады «Казан сувенирлары»ның. Яшь башкаручылар чит музыкага да бик канәгать иде, күрәсең. Ә менә коллективка М.Соколов килгәч, алар һәм оркестрантлар арасында андый шартларда була торган бик тә табигый иҗади каршылыклар туа башлады.

Җырчыны ансамбльнең бик тә түбән башкару дәрәҗәсе белән килешергә нәрсә мәҗбүр иткәнен әйтүе кыен. Әллә җитәкче булаpак йомшаклык күрсәткән, әллә менә аның башкару манерасы сәбәпче булган. Ансамбльдә катнашучылар банкет мәҗлесләрдә һәм бәйрәм концертларында ирешкән минутлык уңышларны үзләренең сәнгатьләрен тану, дип кабул иткәннәр, күрәсең.

Тиздән М.Соколовның Бөтенроссия вокалистлар конкурсы лауреаты дигән исеме пәйда була. Ул бу исемне купшы җитдилек өчен үзе генә уйлап чыгарган. М.Соколовны алкышларга күмгән Алман иле, Финляндия, Франция, Төркия, Болгария тамашачылары да коры хыял җимеше генә. Ә менә «Сюрприз квинтет» гастрольләре маршрутының чын исемлегенә күз салыгыз: Чаллы, Лениногорск, Балык Бистәсе, Тәтеш, Биектау. Күрәсез, нерма бик зур.

Хәер, М.Соколов географиядә генә түгел, башка нәрсәләрдә дә бутала икән. Әйтик, ул тамашачыларга «Болгар» группасының таркалуы турында да ялгыш мәгълүмат биргән. Чынында исә бу группа, республикабызда нәкъ шундый исемле ике коллектив булу сәбәпле, исемен генә алыштырды. Хәзер ул «Заман» дип атала. Сүз уңаеннан шуны әйтеп узыйк: бүгенге көндә әлеге коллектив — филармониягә иң зур керем бирә торган группаларның берсе.

Эшне үзгәртеп корудан филармония дә читтә кала алмады. Юкса, хәзерге базар икътисады шартларында ул инде күптән таркалган булыр иде. Ә филармониябез, таркалудан бигрәк, тагын да үсте, ныгыды. Аның халыкара концерт оешмалары белән элемтәләре киңәйде. Күптән түгел генә А.Шутиков җитәкчелегендәге халык уен коралллары оркестры Австриядә һәм Алман илендә гастрольләрдә булып кайтты. Чиратта — симфоник оркестрның чит ил гастрольләре.

Дөрес, акча мәсьәләсендә авырлыклар бар-барын. Хөкүмәтебез ярдәм итә. Әйтсәк әйтик инде, хәзерге вакытта безнең республикада гына эстраданы дотация хисабына тоту мөмкинлеге тудырыла. Монда да зур коллективның хезмәтенә үзенчәлекле бәя бирү чагылыш таба.

Гаҗәп бит, хәтта филармониядән киткән артистлар да үзләренең афишаларына «Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» дигән сүзләрне язып куярга тырышалар. Бу җәһәттән шуны әйтик: без филармониядән читтә бәхетен сынап карарга теләгәннәрне һәм, ниһаять, кире әйләнеп кайтырга уйлаганнарны яңадан кабул итәргә әзер. Мондый хәлләр булгалады инде.

1997 елда Татар дәүләт филармониясе үзенең 60 еллыгын билгеләп үтәргә әзерләнә. Менә шунда инде барысы да күренәчәк. Тамашачыларны уйлап чыгарылган төрле дәрәҗәле исемнәр, чит ил тамашачыларының сок...
белән алдарга мөмкин, әл...
лыкта чын ихтирам казануга...
шмәгән һәм үз һөнәре өчен...
плылык хисе булмаган арти...
ркайчан да аншлаг җыя алм...

Без филармониядә инде ...
дистә елга якын эшлибез. ...
башка дәрәҗәлерәк концерт...
маларына да чакырганнары...
Әмма бөтен организмга зы...
термичә генә аны ниндидер...
әгъзасыннан мәхрүм итеп...
мый. Без филармониягә ке...
без белән беректек һәм үзе...
аның язмышы өчен җа...
итеп тоябыз. Әгәр безнең ...
ләкәт»тә нәрсә дә булса ...
чыкса, без тыныч кына, һ...
тавыш-тауга чыгармыйча ...
эшлекле төстә ярдәмгә а...
быз.

Филармониянең хәзерге д...
торы Ә.Сафин безне бор...
мәсьәләләрне ютән белә һ...
скей административ чарала...
ланып эшләргә ярамаганл...
бик яхшы аңлый. Сандугач...
рнакларын багырып, аның...
лаганын тыңларга теләгән...
турындагы мәсәлне ишетк...
бардыр. Күрәсең, бүген бар...
тистлар да иҗат ирегеннән...
файдалана алмыйлар, алар...
сында тырнакларны сагы...
лар да бар.

И.ШАК...
Русиянең һәм Татарст...
халык артисты, Татар ...
филармониясенең с...
шурасы...

А.АРСЛА...
Русиянең һәм Татарст...
халык ар...

Ә.АВЗА...
Русиянең атка...
Татарстанның халык а...

А.ШУТИ...
Русиянең һәм Татарст...
атказанган сәнгать эшл...

В.ВАРШАВС...
Татарстанның атказанган ар...
сәнгать шурасы әгъ...

Гомәр САТТАРОВ-МУЛИЛЛЕ

Ялгызлык исемнәре һәм безнең хәят

(Очерк-эссе)

(Дәвамы. Башы 9 нчы санда).

Тарихчы һәм телче галимгә, бигрәк тә топонимистка, халкыбызның этногенезы турында масштаблы итеп фикер йөрткәндә, төрки телләрдән үзара якын кардәшлектә торган татар теле белән башкорт теленең кыпчак телләренең кыпчак-нугай подгруппасына карамавын, бәлки кыпчак-болгар подгруппасына каравын беркайчан да истән чыгарырга ярамый.

Кайбер тарихчы һәм телче галимнәребез болгари тарихи асылыбызга хилафлык кылып, читкә тайпылганнар иде.

Безнең бабаларыбыз кемнәр? Этник тамырларыбыз кемнәрдән килә, без кемнәрнең варислары? Болар үтә тирән, мәгънәле, үтә житди, мөһим сораулар. Академик Әбрар Кәримуллин «Татарлар исемебез һәм жисемебез» (Казан, 1991) дигән китабында бик хаклы рәвештә язганча: «Халкыбызның исеме, аның килеп чыгышы мәсьәләсе — милләтебез тарихында иң нечкә, иң авырткан жир. Ул авыртуны тамымаска тырышу, дәваланудан качу аны тирәнрәк генә кертә, рак кебек бөтен халыкта метастаза таралуга китерә. Инде ул метастаза миллионнан артык татардан үзбәк, урыс, башкорт, казакъ... ясады. Менә болар «тарихын оныткан халык үләр, исемен оныткан милләт бетәр» дигән мәкальнең трагик чагылышлары» (155 бит). Үзен «татар» дип атаган чын татарны нык уйландырырлык саллы, үткер, житди, акыллы сүзләр болар.

2. ТАТАР АВЫЛЛАРЫ ҺӘМ ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясе һәм республикабызның башка гыйльми оешмалары галимнәре, тулаем фәнни жәмәгатьчелек алдында торган гаять мөһим һәм зур колачлы бурычларның берсе – «Татар энциклопедиясе»н төзү. Бу өлкәдә без элекке СССРда союздаш республика статусына ия булган һәм кимендә ярты гасыр әүвәл үз академияләрен барлыкка китергән халыклардан чирек гасырга артта калдык.

Моның төп сәбәбе — Татарстанның 1990 елның 30 августына кадәр автономияле республика кысаларында гына яшәвендә, юридик һәм икътисади хокук һәм мөмкинлекләренең ифрат тар һәм чикләнгән булуында, әлбәттә.

Фәннең гомум үсеш дәрәҗәсе һәм югары квалификацияле галимнәр белән тәэмин ителеш ягыннан байтак кына союздаш республикалардан югарырак дәрәҗәдә торсак та, автономия кысалары безгә Татарстан Фәннәр академиясен төзергә мөмкинлек бирмәде. Җөмһүриятебезнең 1990 елның 30 августы декларациясе нәтиҗәсендә генә Татарстан Фәннәр академиясен төзү мөмкин булды. Бу — суверен республикабызның зур бер казанышы.

Татарстан Фәннәр академиясе президиумы карамагындагы Татар энциклопедиясе бүлегенең (табигый ки, егерме кеше эшләгән бу бүлек энциклопедия кебек гаять зур күләм мохитен колачлый алмый иде) 1994 елның башында Татарстан Министрлар Кабинеты карары нигезендә махсус «Татар энциклопедиясе институты» итеп оештырылуы — әлеге хокук һәм мөмкинлекләрнең гамәли бер гәүдәләнеше. Бу институт штатында хәзер 44 фәнни хезмәткәр бар, тик әлегә анда кирәкле югары квалификацияле белгечләр, галимнәр житми.

«Татар энциклопедик сүзлеге» һәм күптомлы «Татар энциклопедиясе»нең бик күп проблемаларын фәнни нигездә хәл итәсе һәм гамәлгә кертәсе бар. Бу турыда соңгы вакытта татар матбугатында күргәзмәле байтак фикер-язмалар басылып тора. «Татар энциклопедик сүзлеге» һәм күптомлы «Татар энциклопедиясе«н төзү өчен хәл итәсе житди фәнни мәсьәләләрнең берсе һәм гаять әһәмиятлесе — Татарстан Республикасындагы барлык төр торак пунктларның (татар, урыс, чуваш, мари, удмурт, мордва һәм башка халыклар яши торган шәһәрләр, бистәләр-поселоклар, тимер юл станцияләре, разъездлар һ.б.) берсен дә калдырмыйча, һәрберсе турында анкета-белешмәләр тутыру һәм республикабыздан читтәге татар торак пунктлары (башлыча татар авыллары) турында кирәкле мәгълүматлар тупланган картотека (топонимик, тарихи, географик, этник, демографик-статистик, икътисади, мәгариф-мәдәни, биографик банкны) булдырудан гыйбарәт.

Милли энциклопедиябезне торак пунктлар турында гиешле фәнни мәгълүматлар белән хәзерге заман таләпләре югарылыгында тәэмин итүдә татар ономастикасы фәненең, тулысынча формалашып, эзлекле үсеш алуы гаять зур әһәмияткә ия.

Татар энциклопедиясе институтында әлеге мөһим һәм жаваплы фәнни тармакка караган мәсьәлә-гамәлләрне тиешенчә башкарып чыгу өчен, шушы юллар авторы баш мөхәррирлегендә, гуманитар фәннәрнең «Тарихи-географик проблемалар һәм топонимика» бүлеге оештырылды. 1992-1993 елларда Татарстандагы барлык торак пунктлар буенча (аларның саны 4 меңнән артык) тарихи, географик, топонимик, демографик-статистик, икътисади мәгълүматлар, мәгариф һәм мәдәният өлкәләренә караган белешмә-фактларны туплау һәм 8 пункттан торган үрнәк-схема буенча һәрбер торак пункт өчен аерым картотека тутыру, мәкаләләр язу эше шактый интенсив һәм нәтиҗәле алып барылды.

1994 елның мартыннан Татарстаннан читтәге республика, край һәм өлкәләрдәге татар авыллары турында мәгълүматлар туплау-язу эшенә керешелде. Бу жаваплы һәм кирәкле эшне башкару да мина тапшырылды. Иң әүвәл бер ярым миллионнан артык татар халкы яши торган Башкортстан Республикасындагы авыллар турында мәгълүмат туплау, картотека-мәкаләләр язу максатка ярашлы булыр дип табылды. Башкортстанда 1500гә якын татар авылы бар. Алфавит тәртибендә шуларның яртысына, төгәл итеп әйтсәк, 676сына кирәкле мәгълүматлар туплап, картотека-мәкаләләр яздык.

Аяныч вә кызганыч ки, Башкортстандагы татар авыллары буенча «Татар энциклопедик сүзлеге» һәм «Татар энциклопедиясе» өчен мәгълүматлар туплау, картотекалар тутыру эше «О» хәрефенә кергәч, финанс кыенлыгын сәбәп итеп алып, туктатылды (Татарстан Фәннәр академиясе үзенең хезмәткәрләре өчен ун коттедж салырга җыена («ШК», 4.04. 1995). Димәк, акча бар икән).

«Башкортстандагы татар авыллары турында кирәкле мәгълүматларны Башкортстан Фәннәр академиясеннән, башкорт галимнәреннән алачакбыз яки Уфага үзебезнең хезмәткәрләрне жибәреп туплаячакбыз», — дип белдерделәр.

Ай-һай, башкорт галимнәре Башкортстандагы татар авыллары хакында чынбарлыкта булганча объектив мәгълүматлар бирерләрме, Казаннан килгән хезмәткәрләргә объектив рәвештә кирәкле мәгълүматларны туплауда булышырлармы икән? Моңа бик нык шикләнергә туры килә. Шикләнүнең башкорт зыялылары тарафыннан милли сәясәткә әйләнгән теләк-омтылыш-максатлары белән бәйле житди сәбәпләре бар.

Бу хакта башта Башкортстанда яшәүче һәм эшләүче милләттәшләребезнең жан авазына колак салыйк.

«Билгеле булганча, Башкортстан — күп милләтле жөмһүрият. Анда 1 миллион 500 меңнән артык татар яши (республиканың нигезен тәшкил итүче башкортлар өченче урында, бу — Рәсәйдәге жөмһүриятләр арасында берләнбер очрак). Ләкин татар хакында Башкортстан Конституциясендә ник бер сүз булсын. Ни үзе, ни теле, ни хокуклары турында. Әйтерсең, республикада бу халык бөтенләй яшәми. Аны күрмәмешкә һәм белмәмешкә салыналар. Ул гына да түгел, аны кимсетәләр, кыерсыталар, хокукларын чиклиләр, әллә нинди тузга язмаган ялалар ягалар», — дип ачынып яза журналист Замир Низаметдинов («ВТ», 3.02.1995, 7 бит).

Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасы доценты Сәгыйт Хафизов бик хаклы рәвештә борчылып: «Үз вакытында башкорт әдәбиятчылары татарның борынгы әдәби мирасын үзләштерделәр. Ә хәзерге чорда мондагы бер төркем телчеләр Башкортстан татарлары телен «башкорт теленең көнбагыш диалекты» дип ышандырырга тырышалар. Бу гыйльми идея гамәлгә керсә, жөмһүрияттәге татар мәктәпләрен янә «башкортлашу» көтә. Дөресме, әллә ясалма гыйльми идеяме бу? Бер-ике сеннән гайре ник бүтән татар телчеләре, бигрәк тә Казан галимнәре эндәшми», — дип яза («КУ», 1 сан, 1995, 144 бит).

Эндәшмәү газиз татар халкына, милләтемә хыянәт вә жинаять итү булыр иде һәм менә ни өчен?

Башкорт телче-топонимисты Азат Камалов «Башкирская топонимия» (Башкирское издательство «Китап», Уфа, 1994, 304 бит) дигән монографиясендә башкорт әдәбиятчыларының һәм башкорт телче-диалектологларының татарныкын башкортныкы дип дәгъва итүдәге «эшчәнлекләрен» тагын да арттырып жибәрә.

Соңгы елларда Башкортстандагы байтак кына татар авылларын башкорт авыллары дип күрсәтү, хәтта дәүләт документларында, белешмәләрендә шулай рәсмиләштерү башланды. Аларда башкорт теле, әдәбияты, тарихын һәм мәдәниятен укыту-өйрәнү белән генә чикләнәсе, канәгатьләнәсе килми башкорт телче-топонимист һәм тарихчы галимнәренең.

А.Камалов әфәнде югарыда исеме аталган китабының азагында «Список коренных башкирских деревень, находящихся в соседних областях, республиках и населенных пунктов, в которых компактной группой проживает башкирское население» (248-295 битләр) дигән махсус кушымта бирә. Биредә Азат әфәнде, чынбарлыкка хилафлык итеп, аны фальсификацияләп булса да, Башкортстан белән чиктәш Курган, Ырынбур, Пермь, Самара, Чиләбе өлкәләрендәге байтак кына татар авылларын да, Татарстан Республикасындагы 222 татар авылын да башкорт авыллары итеп карау юлына баса.

Пермь, Курган, Свердловски, Самара, Чиләбе һ.б. өлкәләренең А.Камалов хәзер дә башкорт авыллары дип караган күп кенә авыллары башкорт авыллары булмыйча, татар авыллары булуын, бу авыллар халкының үзләрен татар дип атауларын рәсми чыганаклар, документларга нигезләнеп раслый алабыз.

А.Камалов әлеге хезмәтендә Башкортстаннан читтә (Русия Федерациясе өлкәләрендә һәм Татарстан Республикасында) барлыгы 580 башкорт авылы бар дип карый. Мондый «башкорт авылларының» иң зур күпчелеге Татарстан Республикасында икән. Ул Татарстандагы 222 татар авылын (алар «Татарстан Республикасының административ-территориаль бүленеше» белешмәсендә (Казан, «Барс» нәшрияты, 1992 ел) һәм элегрәк чыккан шундый рәсми белешмәләрдә милләт графасында барысы да татар авыллары дип теркәлгән) башкорт авыллары дип саный.

Азат әфәнде Татарстан Республикасының Әгерже районындагы — 10, Азнакай районындагы — 18, Актаныш районындагы — 79 (ягъни Татарстанның Актаныш районы башлыча башкорт авылларыннан тора дип), Әлмәт районындагы — 7, Бөгелмә районындагы — 1 (хәзерге Карабаш эшчеләр бистәсен), Баулы районындагы — 16, Алабуга районындагы — 3, Лениногорски районындагы — 5, Минзәлә районындагы — 33, Мөслим районындагы — 21, Октябрь районындагы — 3, Сарман районындагы — 25, Чаллы районындагы (Тукай районы) — 4 авылны (Чаллыны да кертеп) хәзер дә башкорт авыллары дип күрсәтә (270-284 битләр). Актаныш районында башкортныкы булмаган бер дистәдән артык кына татар авылы бар булып чыга.

Азат әфәнде Камалов республикабызның Актаныш районындагы авылларны «башкортлаштыру» белән шулкадәр мавыгып китә ки, Терпеле дигән мари авылын да башкорт авылы итеп күрсәтә. Татар Суксуы авылы исемен жәяләр эчендә булса да, Башкорт Суксуы дип үзгәртеп бирә. Түбән Кама сусаклагычы барлыкка килгәч, урыннарын су басу аркасында таркалып юкка чыккан Иске Семиострово (Ушар, Сауз), Яңа Семиострово (Пузырево, Чиялек), Мәчти һ.б. авылларны да башкорт авыллары итеп саный.

Башкорт телче-топонимисты А.Камаловның теләк-нияте, нәфесе бик зурдан. Башкортстаннан читтәге башкорт авылларының күбесе хәзер башкорт авыллары булмыйча, татар авыллары булса да, алардан «башкорт» авыллары ясап, берәмтекләп махсус исемлеккә жыю-туплауның асыл максаты 2 нче кушымтада бирелгән аңлатмада ачык чагылыш таба: «В этот список включены только те башкирские деревни, которые в территориальном отношении относятся не к Республике Башкортостан, и принадлежат соседним областям Российской Федерации и Республике Татарстан. Это сделано с целью установления полного перечня коренных башкирских деревень, продолжающих свое существование в настоящее время... Эти сведения нужны для изучения современного состояния и территориального распространения башкир. Кроме всего прочего преследуется еще практическая цель, а именно поставить вопрос об охвате башкирских детей родным языкам обучения и приобщение их к изучению родной истории и культуры» (248 бит)

Менә сиңа мә! Юкәдә икән чикләвек. Башкорстандагы татар районнарының татар мәктәпләрендә башкорт телен һәм әдәбиятын, тарихын һәм мәдәниятен укыту белән генә чикләнмичә, Татарстанда да А.Камалов «башкорт» авыллары дип санаган 222 татар авылында, татар балаларына башкорт телен, әдәбиятын, тарихын һәм мәдәниятен укыту мәсьәләсен көн тәртибенә куярга вакыт житкән икән ләбаса! Никадәр еракка китә һәм күпме өмет итә торган астыргын фәнни-гамәли максат-нәтиҗәләр ята биредә.

(Дәвамы бар).

Д АҺИ ШАГЫЙРЕБЕЗ ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ

Рабит БАТУЛЛА

Кылдан нечкә,

(Ахыры. Башы 8, 9 нчы саннарда).

Бу аңламау яки аңламаганга салышу Тукайның ачуын чыгарды.

— Кушылмаган килеш безгә аерылышырга кирәк!

Ниһаять, Тукайның кинаясе Зәйтүнә туташның башына барып җитте, ул, чарасыз калып, башын иде һәм салмак кына:

— Ни нәрсә үзгәрде шушы арада? — дип куйды. — Без икебез дә бер җан кебек идек бугай бит...

Тукай инде авызлыкны тешләгән, аны бу бүлмәдә туктатыр көч юк иде.

— Ул сезнең фантазиягез, туташ, ул сезгә шулай тоелган гына. Ялган романтика! Без икебез ике кеше, ике аерым җан. Юллар аерым безнең, юллар...

Туташ аягүрә басып, кинәт каты тавыш белән:

— Ышанмыйм! — диде. — Туры Тукай ул вакытта алдамады. Икесенең берсе ялган! Күземә карагыз, Тукай. Туры карагыз! Сезгә гайбәт ишеттергәннәр. Шулаймы? Сез мине Тукайга тиң санамыйсыз!.. Минем хакта гайбәт булалмый. Алайса ни сәбәп?..

Туташ кызганнан-кыза барды, хәзер ул инде әдәп-итагать сакларга да тырышмый, киресенчә, ул үзенең мәхәббәте өчен соң мәртәбә көрәшкә ташланды.

— Беләм, Тукай, — диде туташ яшьләрен чак-чак тыеп. — Беләм, миңа сезнең белән бик кыен булачак. Сезнең холкыгыз фәрештә холкы түгел. Дошманнарыгыз күп. Сезгә яшәве көннән-көн кыен булачак. Сезгә дә, сезнең белән яшәүче хатынга да, беләм... Белгәнгә күрә мин сезне сөямен!

Тукай үкереп җыларлык, шашып күләрдәй сәер халәттә иде. Зәйтүнә тагын бер-ике сүз әйтсә, ул аның аягына егылачак һәм икесе дә харап булачак иде. Тукай кинәт сикереп торып басты да, каты тавыш белән:

— Мин сезне сөймим! — дип кычкырды.

Мең көзге ватылгандай, һава чәлпәрәмә килде, чәлпәрәмә килде дә бүлмәдә табигый булмаган тынлык урнашты. Тукай кычкыруы өчен гафу үтенгәндәй, сабыр тавыш илә:

— Шуны аңладым шушы вакыт арасында, Зәйтүнә туташ, — диде.

Туташ та инде сабыр иде.

— Туры Тукайның беренче һәм соңгы ялганы! — дип җавaплады ул.

Һәм бүлмәдән тәвәккәл атлап чыгып та китте. Тукай ул киткәч тә байтак кына хәрәкәтсез утырды. Аннары, өстеннән олы йөк төшкәндәй, әйтте:

— Хуш, бәгърем, мәңгегә бәхилләү бу ялганымны! — диде. — Мәхәббәт шигырьләремнең илһамчысы, хуш, бәхил бул! Әлвидаг, туташ, әлвидаг! Әлвидаг, туташ, әлвидаг!

Ул мендәренә капланды, аның арык җилкәсе әллә ютәлдән, әллә җылаудан җиңелчә генә калтырана иде.

Фатих Әмирхан Зәйтүнә туташның Тукай бүлмәсендә икәнен белә иде. Ул ике яшь йөрәкнең бергә кушылуын бөтен җаны-тәне белән теләп, Аллаһка ялвара иде. Туташ белән Тукай сөйләшеп бетергәнче, ул Кабан күле буйлап әйләнеп кайтырга булды. Мәхмүт арбаны коридорга алып чыкты, инде киттек дигәндә генә Тукай бүлмәсенең ишеге ачылды, аннан Зәйтүнә туташ күренде, кеше күзенә чалынмаска тырышып, битен кечкенә сумкасы белән каплап, йөгерердәй булып, тиз-тиз атлап баскычка төшеп китте. Фатих Әмирхан аның белән исәнләшергә дә, туктатып сораштырырга да өлгермәде. Мәхмүт аңлады, арбаны урамга түгел, Тукай бүлмәсенә таба этәргә кирәк иде.

— Тукай, бу ни эшең? — диде Фатих керә-керешкә. — Туташ тыела алмыйча җылый-җылый битен каплап китеп барды. Синме аны рәнҗеттең?

Фатихның бу эшкә килеп катышуын Тукай өнәп бетермәде, ул канәгатьсезлеген яшермичә:

— Синме булдың адвокат! — диде. — Югыйсә син бит высший круг кызларын югарыга мәһирсең!

— Тукай әфәнде! — дип кычкырды Фатих Әмирхан. — Минем белән шундый тонда сөйләшергә кем рөхсәт итте? Изволье аңлатырга? Нигә җылый кыз бала? Аның ни гаебе бар?

Мин җыламыйммы, Фатих! Күр! Мин аннан да катырак җылыйм лабаса. Минем күз яшьләрем аныкыннан мең кәррә ачырак.

Булды, икесе дә бер-берсенә кычкырды. Җитте. Инде сүрелергә вакыт. Фатих Әмирхан киеренкелекне киметер өчен Тукайга якынрак килде.

— Ни өчен ачуланыштыгыз? Хәер, татулашырсыз әле.

Тукай да үзен бераз гаепле саный иде Фатих каршында. Ул сабыр гына:

— Без ачуланышмадык, Фатих, — диде. — Кушылмыйча аерылдык. Шулай мәгъкуль. Кем мин? Ул әйтә, күземә туры кара, ди. Ә миндә... — Тукай уң күзенә уч төбе белән сугып алды. — печать проклятья! Ул нәзик хисләр иясе. Ул нәфислек алиһәсе. Мин чир баскан, шик баскан бер буйдак.

Фатих Әмирхан дустының холкын бик яхшы белә иде. Юкка кимсетә Тукай үзен. Ул беркемнән дә ким-хур түгел. Ул әйләнә-тирәдәгеләрнең барысыннан да югары кеше. Шагыйрьнең бу сүзләре хәйлә генә булырга тиеш. Туташ белән ара өзүнең башка бер җитди сәбәбе бардыр. Аның уйларына җавап шикелле Тукай сүзләре ишетелде:

— Шул фәрештәгә өйләнеп, аны бәхетсез итимме? Ул — гүзәлләр гүзәле, ул — газәлләр газәле, олуг бер мәхәббәткә ия булырга лазем.

Чынлыкта Зәйтүнә туташ өчен Тукай мәхәббәтеннән дә олуг мәхәббәт юк иде. Туташ Тукай белән бәхетсез булуны бәхет саный иде кебек.

— Кире кайтарыйммы? — диде Фатих арбасын ишеккә таба борып.

Тукай кискен генә итеп:

— Юк! — диде. — Юк, уйнама, Фатих! Киселде, мәңгегә киселде бу җеп. Киселде бу бәгырь. Киселсен. Бәгырем киселгәндә, мәхәббәтнең сагышлы бер кылы өзелеп зың-ң-ң итте. Их, Фатих дустым, шушы сөюем мине бәхетле итә дә, әнә шул өзелгән кылның сызып-сызып зеңгелдәве әче бер ләззәт тә бирә. Белмисез шул сез яшерен сөюнең, тормышка ашмас мәхәббәт газабының ләззәтен, белмисез!

— Алайса, нигә кирәк иде туташ белән бу күрешүләр?

— Бүген генә, хәзер генә аңладым... мәңгегә кисәргә кирәк икәнен... Туташка өйләнүем зур гонаһ булыр иде. Башкага мин өйләнә алмыйм. Өйләнер идем, куркам. Кем булып чыгар минем хатын? Шайтан белә! Өйләнерсең — бала-чага. Үстер, укыт, тәрбия кыл. Хатын коенә бие. Туганнары белән талаш. Мин бала яратам, хатынны чит күрмәс идем. Юк! Минем өчен түгел андый тормыш. Мин тулаем халыкныкы, Фатих! Башым, иҗатым, авыруым белән мин кире кайтарып алмаслык итеп халыкка тапшырылган зат. Мин гаиләдә вакланып бетсәм, халыкка ни калыр? Шуңа күрә мин беркайчан да өйләнмәскә уйладым.

— Хәйләкәр Тукай! — диде Фатих, юри бармак янап. — Дәлилләр уйлап чыгарырга оста син. Ләкин боларның барысы да сылтау гына. Сәбәп тирәнрәктер.

— Әйттерммә, Фатих! — диде Тукай кискен генә. — Мин туташны сөйгән кебек берәү дә сөя алмый. Шушы арык тәндә тауларга сыя алмаслык тыйшык дәрте ята. Ләкин минем туташны бәхетсез итәсем килми!

— Тукай! — диде Фатих, ачынып. — Син...

— Дәшмә! Күз алдыңа китер, яшь-яшь, гүзәл гүзәл хатын аягүрә өрәм булачак бит. Мин үлемгә хөкем ителгән, Фатих. Дәшмә! Шулай! Син генә бел! Ә хәзер кит! Ялгыз калыйм!

Фатих Әмирхан кыйнап ташлаган кебек иде. Ул инде чарасыз. Тукай ике сөйләшмәячәк. Чыгып китү хәерлерәк булачак иде.

Агар артыннан ишек ябылгач, Тукай әрле-бирле йөренеп алды да чәчәкләргә карап:

— Менә шулай җиңелрәк булыр, Апуш! — диде. — Тукайга әверелә барган саен йөгең авырая. Язмыш шулай кысты синең, Апуш. Дөньяда үз мәхәббәтеннән качкан тагын берәү булырмы? Үз мәхәббәтен табалмыйча үлеп киткән бичаралар бихисаптыр. Ә мин мәхәббәтемне таптым. Сөйдем. Сөйгеле булдым. Аннары үз кулларым, үз сүзләрем белән кире эттем. Әйт син, Апуш, бер мизгел мәхәббәт ләззәте өчен корбан итә ала идемме мин туташны? А-а, юк! Үкенмә! Кылган батырлыгыңа үкенмә!

Зәйтүнә туташ белән соңгы сөйләшү вә аның сагышлы нәтиҗәсе Тукайны тәмам бөкте. Ул инде отыры хастага әйләнә бара иде. Әнә шулай авырып яткан көннәрнең берендә аның бүлмәсенә тагын Шәүлә килеп керде. Аны күрүгә, Тукай ризасызлык илә:

— Мин өйдә юк! Мин авырыйм! Йөрмә монда, карачкы Шәүлә! — дип кычкырды.

Ләкин Шәүләнең моңа һич исе китмәде, ул бүген бөтенләй башка кыяфәттә иде, бөкреләге дә әллә кая киткән, йөреше дә городовойныкы кебек иде.

— Монысында без синнән сорап тормаска булдык, Тукаев әфәнде! — диде Шәүлә түргә уза-уза.

— Кем инде ул «сез»? Николай патшамы?

— Без! — диде горур хәерче. — Николай патша булмасак та, жандармерия идарәсенең өченче бүлеге әһелләре!

Шулчак бүлмә эчендә могҗиза булып алды. Шәүлә өстендәге әләм-сәләмнәрен салып ыргытты. Элеккеге йолкыштан мәһабәт бер кешегә әверелде. Тукай, циркта утыручы тамашачы кебек, авызын ачып карап тора башлады. Ул әле һаман Шәүләнең бу әверелешен бер кәмит кенә дип уйлый иде, ахрысы.

— Чираттагы әверелешеңме, күрәзәче Шәүлә?

— Юк! — диде кәттә кыяфәтле ир. — Чираттагы эшемнең ахыргы нәтиҗәсе, Тукаев әфәнде. Күрәсез ки, мин үз эшемне шактый оста башкарам. Бу операциягә нокта куярга вакыт җитте!

Ул Тукай йөзенә ниндидер бер катыргы төртте. Тукай барысын да аңлады.

— Аһ, шулаймыни? Елан тек елан...

Тукай көлә башлады.

— Рәхмәт, әфәндем, — диде кунак. — Бу миңа бик зур комплимент. Мәдхия!

Тукайга көлүдән башка чара калмаган иде шул. Ул һаман елмаеп Шәүләгә карап тора, үзе сөйләнә:

— Хәшәрәт! Казы белән сыйладым бит мин бу хәерчене, кызганып. Күрәзә караган саен берәр сум көмеш бирдем бит шул сатлыкҗанга.

Шәүлә бу сүзләргә җавап бирмәде.

— Беләсеңме, — диде ул. — Барыбер мин сине яратам, Тукай. Сүксәң дә, типкәләсәң дә, яратам.

— Сөя-сөя суясың, ярата-ярата таркатасың, юха елан.

Шәүлә Парижларда гына тектерелә торган кәчтүн кигән, ап-ак крахмал якадан, кыйммәтле ефәк муенчак бәйләгән, ике кулында ике балдак елкылдый, кулында нәзек, затлы таяк уйный. Оста уйната ул таягын, ике бармагы белән өзлексез әйләндереп тора ала. Әйтерсең лә ул Тукай алдында цирк номерлары күрсәтергә килгән. Осталыкларын күрсәткәннән соң, Шәүлә, назлы тавыш белән Тукайга эндәште:

— Син, Тукай, бик тә сихерле кеше бит. Синең артыңнан шымчылык итәргә алынган агент үзеңне ярата башлый. Синең өстән язарга телимен, сине яклый башлый. Сагышлы Сагыйть Рәми качты. Бикчура асылынды. Полковник Жуховицкийдан миңа боерык булса да, мин сиңа кагылмадым. Мин сине харап итәр урында саклап йөрдем. Әйе, әйе, мин булмасам, сине әллә кайчан бетерәләр иде. Үзегез-

кылычтан үткер

некеләр ук. Яңа Бистә. Печән базары әһелләре сине мең тапкыр үтерә иде. Мин аларның юлын кисә бардым. Тукайга кагылсагыз, бөтенегезне кырып бетерәм, дидем. Кагылмадылар.

— Рәхмәт инде! — диде Тукай, мыскыллы елмаеп. — Үзең үтерер өчен башкалардан саклап калганыңа күрә, мең шөкер. Хезмәтең өчен, әнә, өстәлдә сынык казы белән илле тиен бакыр бар, ал!

Шәүлә рәхәтләнеп көлә башлады.

— Тукай һаман Тукай булып кала!

— Хәзер сәбәбен әйт инде, Шәүлә! — диде Тукай.

— Тукай мәшһүр, Тукайга тартылалар! Тукай миңа җим буларак кирәк иде. Алдавыч җим — ул Тукай. Государственный преступник Хөсәен Ямашевны розыск ничә еллар тота алмады. Ә мин тоттым. Әһә, минәйтәм, бу хәйләкәр төлке Хөсәен Ямашев Тукай дигән җимгә килми калмас. Һәм хак, чиертте Ямаш Тукай дигән җимгә. Килде Хөсәен Тукайга һәм тотылды... Авыр туфрагы җиңел булсын. Менә ни өчен мин Тукайны җаным кебек сакладым.

— Революцияне буучы палач син! — диде Тукай нәфрәт илә.

Ләкин Шәүләнең ачуын чыгарып булмый иде. Ул елмая-көлә сүзен дәвам итте.

— Ялгышма, Тукай! Чын революцияне яклаучы мин. Революция ясаучыларның туксан проценты надан була. Биш-ун хыялыйның идеясенә ияреп, наданнар баш күтәрә. Баш күтәрү вакытында акыллылары үлеп бетә. Революция юлы уртасында шыр наданнар гына торып кала. Баралар наданнар, кая барганнарын белмиләр. Кая барабыз соң без, барабыз да барабыз, дип сораганнарны әлеге наданнар революция исеменнән кырып ташлыйлар. Зыялылар бетә, асл фикерләләр агыла, шикләләрне асалар. Алай-болай булмагае, дип һич гаепсезләрне дә төрмәләргә тыгып бетерәчәкләр. Илне шом, деспотизм шаукымы басачак. Һәр палач гөнаһсыз башны чапканда, бисмилла урынына: «Яшәсен революция!» — дип акырачак. Менә нәрсә ул әзерлексез революция. Ямашев Хөсәен хыялланган революция ул революция түгел, ул ирексезләү, көчләү хәрәкәте генә булып калачак. Әгәр дә Ямашлар җиңә калса, Русияне «грядущий хам» — тупаслык, әдәпсезлек басачак. Русия әле чын революциягә әзер түгел. Мин менә шуннан куркам, Тукайҗан. Әнә шундыйлар, Ямашлар, Ленинпар Русия халыкларын ялгыш юлдан алып китмәгәйләре, дип бөтен көчемне, талантымны җигеп көрәшәм.

— Революция җиңсә, революцияне буып торучы Шәүлә ни кылыр икән?

— Сабый син, валлаһи. Һәр хөкүмәткә өченче отделение кирәк булачак. Любой власть алмашыначак, без алмашынмабыз. Без яңа властька да хезмәт итә алабыз бит. Без, Тукай әфәндем, принципсызлыкны принцип итеп алган бәндәләр. Даһиларны даһи иткән — без. Без булмасак, сезнең кадер булмас иде...

Тукай үз гомерендә сафсата сатучыларны күп күрде, ләкин әле кабахәтлекне бөеклек дип, һәр караны ак дип әйтүчеләрнең моңдаен очратканы булмады. Ул аптырашта иде.

— Кыенлык күрмәгән шәхес зур шагыйрь була алмый, — диде Шәүлә. — Шагыйрьне биографиясе бөек итә. Ә сезнең биографияне без ясыйбыз, туган. Сезгә кыенлыклар тудыру һәм сезне бөек итү безнең төп максатыбыз. Булгарин булмаса, Пушкин булмас иде. Булгарин — стимулятор. Булгарин — катализатор. Дошманнары булмаса, Пушкин Пыскын булып кына калыр иде. Пушкин дошманнарына үч итеп, Булгаринпарга ачу итеп, аларны талантлы белән, әсәрләре белән күмеп ташларга теләп иҗат итә, сугыша, эпиграммалар яза, ягъни үзенә һәйкәл әзерли. Моцарт булмаса, Сальери, шулай ук Сальери булмаса, Моцарт була алмас иде. Кем соң ул Герострат? Изге храмга ут төртеп, дан яуламакчы булган бер бәндә. Ә исеме чыннан да тарихта калган бит. Ә мин кем соң? Бер шәүлә. Әмма ләкин Тукайны даһи итәргә алынган шәүлә. Тукай белән беррәттән минем шәүләм дә еллар, гасырлар буе ияреп йөрер...

— Никадәр көч сарыф ителә, никадәр акча түгелә. Барысы да бер Тукайны бетерер өчен...

— Ялгышасың. Тукайны гына түгел, татар халкын бетерер өчен.

Татар халкы белән Тукай тәңгәлмени?

Урыс халкының иң зур дошманы — татар. Ә шул татар-дошманның җаны син — Тукай.

— Татар халкы урыска дошман түгел.

— Тукай дошман һәр урыс әйберсенә. Диненә, культурасына, халкына. Син татар халкын да урыска каршы котыртасың.

— Мин Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам. Толстойны егылып укыйм. Шаляпинның сәнгатенә гашыйкмын.

— Пушкин да, Лермонтов та монархиягә каршы. Шаляпин да күзәтү астында. Ул да маевкаларда катнашкан җинаятьче. Шуларга теләктәшлек белдергән өчен генә дә синең муеныңа кызыл камыт кидерергә була.

— Димәк, татар урыс халкына тулаем каршы түгел!

— Татар дошман урыска. Бар фетнәнең башында татар тора. Разин, Пугачевлар артыннан сиксән процент татар күтәрелде хөкүмәткә каршы. Бүген дә татар халкы Пугачевны көтеп ята. Син Пугачев белән Разиннан да куркынычрак хәзер самодержавие өчен. Менә ни өчен Тукайны изеп бетерү кирәк иде!

— Петрның Персиягә походында да, Наполеонга каршы да, Порт-Артур сугышларында да бихисап татар халкы урыс җире өчен һәлак булганлыгын сез күрмәмешкә салышасыз, әфәндем. Татар фетнәче түгел, тыныч вакытта ат кебек, ишәк кебек Русиягә эшләп, сугыш чыкса, җаны-тәне белән Русияне дошманнардан саклаучы тугры эт ул татар, әфәндем. Татар булмаса, урыс халкы нишләр иде икән тарихта! Халыкка каршы халыкларны сез котыртасыз. Сез бөтен фетнәнең башында.

— Менә монысы дөрес, фетнәләр башында мин. Мин Бикчураны шул хәлгә китереп җиткерүче... Дөрес, сагышлы Сәгыйть Рәми качты. Бездән алай гына качып котылып булмый. Ул анда озак тора алмаячак. Театрларын, журналларын ябып бетергәч, өненә егерме чиләк су салган әрләндәй, ул өскә калкачак. Дөрес, Хөсәен Ямашны да... урыны җәннәттә булсын... без юк иттек.

— Хәзер чират миңамы?

— Хәзер чират синеке, Тукай! — дип Шәүлә кесәсеннән кәгазь чыгарды. — Менә сине алырга ордер! Ләкин мин сиңа кагылмаячакмын.

— Ни өчен? Казы белән сыйлаганыма күрәме?

— Юк! Син үлемгә хөкем ителгән инде!

Тукай җәт кенә Шәүләгә бакты. Юк, Шәүлә шаяртмый иде.

— Мин докторлар белән сөйләштем. Беләм. Бөтен җиргә телеграммалар сугучы да мин. Һәм Хөсәен Ямашны шул телеграмма чакырып кайтарды. Синең соңгы сәгатьләрең, Тукай! Шуңа күрә мин сиңа бөтен нәрсәне ачык сөйләргә тиешмен. Тагын бер хәбәр бар синең өчен...

Шәүлә юри туктап сүзен өзде, ул Тукайга соңгы үлем җәрәхәтен әзерли иде. Тукай сагайды, шомланды.

— Нинди хәбәр ул? Әйт тизрәк! Мин барысына да әзер!

Шәүлә серле озаграк тотып торырга тырышып, бүлмә буйлап йөренеп алды, аннары кылыч белән чәнчегәндәй хәрәкәт ясап:

— Моннан чыгып киткән туташ үзен үзе суга ташлаган! — диде.

Тукай сабыр иде.

— Ялган! — диде ул тыныч кына.

— Хакыйкать, Тукай!

Тукай үзен-үзе белештерми Шәүләгә ташланды.

— Ялга-ан!

— Туташ үзен үзе суга ташлаган! — дип кабатлады Шәүлә.

Тукай чыннан да бәгъренә пычак чәнчелгән кебек, сыны катып торды, аннан соң бөгелеп төште. Шәүлә каушап калды, ул моны ук көтмәгән иде, ахрысы, ишек ягына карап:

— Әй, кем бар анда? — дип кычкырды.

Аңа җавап бирүче булмады. Ул бөгелеп төшкән Тукай янына килеп, иң өстенә кулы белән кагылды.

— Тукай, сиңа ни булды? Мин юри әйттем, Тукай!

Тукай әкрен генә аягына басты, турайды, күкрәк тутырып сулыш алды да шашкандай көлеп җибәрде.

— Шүрләдеңме, Шәүлә? Үлде бу дип курыктыңмы? Юк, мин үлмәдем әле. Мин акылдан да язмадым, курыкма... Мин үләсемне докторларга кадәр дә, сиңа чаклы да яхшы белә идем. Син мине үлем белән куркыта алмыйсың хәзер. Үлемгә мин җырлап барачакмын. Чөнки мин беләм, без түккән тирләр, коелган каннар бикяр булмас! Безнең көрәш файдасыз калмас, иншалла. Мин үләм, татар дөньясында Әмирханнар, Рәмиләр, Карилар, Сәхипҗамаллар, Камаллар кала. Барыбызны да үтереп бетерә алмассыз. — Тукай иркен, көчәнүсез, рәхәт көлә иде. — Соң, шулай булгач, мине үлем белән куркыта аламы, дивана Шәүлә! Базар карачкысы, жандарм күсесе. Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса, шул минем максагым, теләгем һәм бәхетем...

Кыйналып-суелып бетмәгән, Шигъри динем, исән бул!

Изелеп-кырылып үлмәгән, Татар халкым, исән бул!

Шул чак ишектә Мәхмүт күренде.

— Тукай абый, аста сине җигүле атлар көтә!

Тукай ачык ишеккә таба атлады һәм Шәүләгә борылып, басынкы, каты тавыш белән әйтте:

— Татар халкы ул алабута, Шәүлә! Алабутаны бетерер өчен аны йолкыйлар, йолкыганда алабута орлыклары читкә чәчелә, икенче елны шул урынны тагы алабута баскан була. Алабута үрчетәсең килмәсә, аңа кагылмаска гына кирәк. Кагылмагыз татарга!

Тукай чыгып киткәч, бүлмәгә хуҗа булып Шәүлә калды, ул ашык-пошык актарына башлады. Менә ул Тукай ятагын туздырып ташлады. Ятак тактасына олы гына хач-тәре ясалганын күреп ул шаккатты. Аннан соң Шәүлә язу өстәленнән ашъяулыкны тартып төшерде. Өстәлдә дә аркылы-торкылы сызык — хач күреп шаша язды. Почмакта торучы тартма өстеннән китапларны себереп түкте, тартмага да хач сурәте ясалган иде. Шәүлә кинәт шашып көлә башлады.

— Тукай гомере буе хач-тәре өстенә ятып яшәгән, хач-тәре өстенә басып иҗат иткән ләбаса!

* * *

Казан өстендә азан тавышы.

— Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр.

Мәчетләр манзарасы. Мәһабәт манаралар, айлар балкый... Мөселманнар мәчеткә бара.

Бер теләнче:

— Ишеттегезме әле, Тукай вафат иткән! — ди.

— Әстәгъфирулла! — ди икенчесе.

— Тукай үлгән! — ди берәүсе.

— Иннә лиллаһи вә иннә иләйһи раҗигун вә иннә ила раббина ләмун кабилун, — дип дога кыла башкалары.

Казан урамнары буйлап матәм агыла. Мәрхүмне озатырга килгән халыкның очы-кырые күренми. Монда дин әһелләре дә, шәкертләр дә, курсисткалар да, жандармнар да, франтча киенгән ирләр дә бар.

— Кемне җирлиләр? Бу кем җеназасы?

— Тукай! Габдулла Тукай үлгән!

— Тукай үлмәс! Тәне үлсә дә, аның каны, аның иҗаты үлемсез!

— Иннә лиллаһи вә иннә иләйһи раҗигун вә иннә ила раббина ләмун кабилун!

— Урының Җәннәттән әйләсен!

Амин!

Сандугач кунды талларга

Шәриф Биккол. Сандугач кунды талларга». Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1995. 527 бит.

Татарстан китап нәшрияты Башкортстан Республикасының Г.Сәләм исемендәге дәүләт бүләге иясе, танылган шагыйрь Шәриф Бикколның шундый исемдәге китабын бастырып чыгарды. «Каләмнәр туганлыгы» сериясе белән нәшер ителгән бу китапта шагыйрьнең төрле елларда язылган шигырьләре, поэмалары тупланган.

Шәриф Биккол — күп еллар буена татар һәм башкорт халыклары арасындагы туганлыкны якынайтуга, үстерүгә зур өлеш кертеп килүче шагыйрь. Ләкин шулай да әлеге китап аның татар теленә тәрҗемә ителеп һәм басылып чыккан беренче китабы.

Шәриф Бикколның әдәбиятка килүенә инде шактый вакыт үтсә дә, ул — хәзерге заман шагыйре. Аның фикерләве дә, уйлары да безнең заманча, иҗаты исә — үз чорының чагылышы. Әлеге китабын укыгач, шагыйрь шигъриятенең кайвакыт таң җиле кебек талгын гына, кайчак давыллы дингез кебек ярсулы һәм укучының күңеленә үтеп керерлек нечкә хисләр тудыра алуын, ышандырырлык итеп язуын сиземлисең. Шагыйрь үз җанында, йөрәгендә кайнаган, үзенең эчке дөньясын биләгән уй-фикерләрен, хисләрен бөтен матурлыгы белән шигырьләренә күчерә. Ул әйтәсе сүзен туры һәм үткер әйтә, анда ясалмалык юк.

Шәриф Биккол лирикасының йөзек кашы — җыр. Башкортстанда гына түгел, Татарстанда да аның җырларын яратып башкаралар. Аның сүзләренә безнең композиторларыбыздан М.Мозаффаров, С.Садыйкова, Р.Яхин, Ә.Бакиров, Ф.Әхмәт һәм башка бик күп композиторлар музыка язган. «Язлар җиткәч кайтырмын...», «Бер минут», «Сандугачым-былбылым», «Әле дә син бар...» кебек җырларның шигырь авторы Шәриф Биккол икәнлеген укучыларыбызның кайберләре белмидер дә әле.

Кыскасы, безнең талларга Шәриф Биккол исемле сандугач кунды. Китапны башкортчадан шагыйрь Харрас Әюп тәрҗемә иткән.

Илдар ХӘСӘНОВ,
Татарстан китап нәшрияты редакторы.

РЕДАКЦИЯДӘН:

Шушы китапның чыгуына сөенеп йөргән көннәребездә безгә Шәриф Бикколның вафаты турында кайгылы хәбәр килеп иреште. Белүебезчә, ул үзе бу китабының чыгып җитүен ишетеп киткән.

Шәриф ага Биккол безнең яраткан шагыйребез генә түгел, яраткан җизнәбез дә иде. Ул — Татарстан кияве. Аның җәмәгате Рәйсә ханым һәм кызы Ләйсәннең, шагыйрьне яраткан барлык шигырь сөючеләрнең тирән кайгысын уртаклашабыз.

Четерекле сорау бирүчегә җавап

Ф.Галимуллин, «Офыкларны алдан күреп». Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1995, 200 бит.

Татарстан китап нәшриятында шушы көннәрдә генә басылып чыккан тагын бер яңа китапның авторы — тәнкыйтьче, галим Фоат Галимуллин. «Офыкларны алдан күреп» дигән исем, әлбәттә, китапның үзенә дә, темасы һәм эчтәлегенә дә күп мәгънә салган. Чыннан да, тәнкыйтьче үзенең бу китабында татар әдәбиятына, аның соңгы еллардагы тарихына яңача күз ташларга, күп кенә күренешләрне яңача бәяләргә омтыла. Шул ук вакытта бүгенге әдәбиятның хәл-әхвәлен дә күзалларга тырыша.

Автор иң беренче чиратта өлкән буын каләм әһелләре Х.Туфан, Ф.Хөсни, М.Гайнуллин һәм башкаларның иҗат эшчәнлеген бүгенге карашлар яктылыгына куеп карый, кайчандыр әйтелгән, кайчандыр туган тудырылган гыйбарәләрнең, образларның вакыт сынавына ныклыгын җентекләп күзәтә.

Китапта шулай ук Ә.Баян, Г.Ахунов, М.Маликова, М.Хәбибуллин, Х.Әюп, Р.Мөхәммәдиев кебек шагыйрь-язучыларыбызның иҗат үзенчәлеге хакында аерым-аерым язма-мәкаләләр урын алган.

Китапта авторның фикерләре тәгаен вакыйгалар, истәлек-сурәтләр белән баетылып бара. «Чирмешән районында йөргәндә Кара Чишмә дигән авылда бер агай миңа бик четерекле сорау бирде:

— Мин үзем китап укырга бик һәвәс кеше. Төрлесен укып барам. Укый торгач, бер шик туа башлады. Кайчакта язучылар арасында да тормышка яраклашучылар бар кебек тоела миңа. Күңелендәген әйтми, сүзләрнең түрәләр йөрәгенә сары май булып ятардайларын уйлап чыгара. Ә уйлап чыгарган, тыңларга матур булса да, хакыйкать түгел инде.

Мондый сүзләр мине беразга аптырашта калдырды. Биредә тота-каба гына җавап бирү әңгәмәдәшне ышандырмаячак, мәсьәлә шактый гына катлаулы, димәк, җавап та дәлилле булырга тиеш...»

Менә шул рәвешле Фоат Галимуллин, әйтерсең, бу китабында конкрет бер укучы, конкрет бер кеше белән әңгәмә кора, әдәбиятыбызның югалту-табышлары, үрләре-офыклары хакында уйлана, үзе өчен дә, башкалар өчен дә четерекле бер сорауга җавап эзли.

Нәҗип РӘШИТОВ.

А.М.Рәхмәтуллин, Н.С.Дорофеева. «Нәфис». Продолжение традиций. 1855-1945», Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1995. 190 бит.

Сүнми торган шәм

Әйе, сүз чыннан да чисталык-матурлык, нәфислек турында бара. Әлеге китап — Вахитов исемендәге химкомбинатының, ягъни «Нәфис» акционерлык җәмгыятенең 140 еллык бәйрәменә багышланган өч томлыкның беренче китабы. Казанда тарихи биналар күп. Вахитов исемендәге химия комбинаты да — шәһәр язмышы, шәһәр тарихы белән кызыксынучылар, халкыбызның узган-үткән юлы белән кызыксынучылар өчен гаҗәеп вакыйгалар дөньясы ул. Комбинатның тууы, төзелүе, анда хезмәт иткән кешеләр, алар хакында иң якты, җылы истәлекләр — болар барысы да авторлар тарафыннан зур хезмәт башкарылуын сөйли.

Кабан күле буенда, Татар бистәсендә, 1855 елда, шәһәр читендә төзелә башлаган шәм заводының тарихы китапта документлар һәм документаль рәсемнәр белән дә яктыртылып барылган. Юк, андагы язмалар һич тә завод хакында гына түгел. Монда Казан — Мәскәү аралары да, Мулланур Вахитов, Гыйлем Камай кебек шәхесләребез дә сурәтләнгән. Кыскасы, эшлекле, эшчән халкыбызның зур җитештерү үзәге булган сабын заводы аның рухи тормышыннан да аерылгысыз икән. «Нәфис» акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре дә, укучылар да шатлана ала: нәфислеккә мәдхия уку кирәктер ул.

Репат ЯРУЛЛИН.

ДҮШӘМБЕ

25 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.30 Балалар өчен «Тамчы». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.40 «Түгәрәк өстәл». Реформалар программасы: ул нинди булырга тиеш? 20.20 «Әлли-бәлли-бәү». 20.30 «Берләшкән Милләтләр Оешмасы хәзерге дөньяда». Тапшыруда Татарстан Республикасының Дәүләт Советы рәисе В.Н.Лихачев катнаша. 21.00 «Гашыйклар телеканалы». 21.35 «Нәфис сүз кичәсе». Диләрә Ильясова. 21.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Волшебник Изумрудного города». 4 нче серия. 7.30 «КиноМеню». 8.00, 10.55 «Юл патрулә». Атналык йомгак. 8.10, 11.40 «Даруханә». 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.20, 13.35 «90х60х90». 9.35 Мультфильм: «Вольная птица». 10.00 Балалар өчен сериал: «Неоновый всадник». 11.10 Спорт атнасы. 11.50, 13.50 «Валюта бәясе». 11.55 «ПОСТ» - музыка яңалыклары. 12.15 Нәфис фильм: «Богач, бедняк». 4 нче серия. 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 Атна һәлакәтләре. 15.00 «Фитиль». 15.10 Нәфис фильм: «Умирать не страшно». 17.05 «Минем йолдыз». Софья Головкина. 17.35 Луи де Фюнес «Мания величия» нәфис фильмында. 19.35 «Эфирда - музыка». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 22.55 «Шәһәр» информацион программасы. 20.45 «Камиллек». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Нәфис фильм: «Прах и кровь», 4 нче серия. 22.30 «Криминаль хроника тележурналы». 23.50 Нәфис фильм: «Убийство» (АКШ - Гонконг).

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.25 «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Могҗизалар кыры». 11.00 «Кеше һәм закон». 11.25 Мультфильм: «Испорченная погода». 11.35 «Ел буе - яшелчә бакчасы». 12.20 Эфирда - «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Сериал: «Овод». 1 нче серия. 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.25 «Спортның җиде ко...». 16.00 Мультсериал: «Отверженные». 16.25 «Йолдызлар сәгате». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.30 «Тет-а-тет». 18.00, 21.00 - «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.05 «Әгәр». В.Позрерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Э.Быстрицкая һәм С.Бондарчук «Неоконченная повесть» фильмында. 23.40 «Юрамалар». 23.35 «Футбол күзәтүе».

«РОССИЯ»

7.30 Эшлекле кешеләр вакыты. 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.35 Клип-антракт. Джимми-Джи. 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 Мульти-пульти: «Скипопас». 9.15 Нәфис фильм: «Цена любви». 10.40 Телегазета. 10.45 «Яңа тармак». 11.05 Милиция хроникасы. 11.15 Россиянең телевизион театры. Н.Николай. «Бабочка... бабочка...» 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «РОСТ» компасы. «Тозлы жил». 16.50 Мульти-пульти: «Ночное приключение». 17.20 Яңа тармак. (Жуковский һәм Рязань шәһәрләре). 17.50 «Музыкаль экспромт». 18.05 «Алыргамы - алмаскамы». 18.15 «Политикага булмаган тема». 18.30 «Котка-911». 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 «Дүшәмбе детектив». «Инспектор Морс» сериалыннан нәфис фильм: «Адская кухня» (Бөекбритания) 1 нче кисәк. 21.40 Спортер. 22.00 «Бизәүсез». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Нәфис фильм: «Берлин. Александр Платц». 0.55 «Роксетт» дөнья тирәли сәяхәте.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.20 «Гүзәллек». 9.40 «Күңел». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Такмаклар». «Коллекционерлар». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.25 А.П.Чехов. «Произведение искусств», «Злоумышленник», «Предводителя» әсәрләрен А. Феофанов укый. 13.50, 15.40 Музыка мизгеле. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.45 Нәфис фильм: «Белый свет». 17.35 Мультфильм. 17.55 «Рязань-95» телевизион программалар фестивале. «Хыянәтсез кеше мә... калсын». «Шәһәр эшләре». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Парадлар парады. Музыкаль шоу. 0.10 Документаль фильм: «Портрет Сигрид Ундсен» (Норвегия). 1.00 Фильм-концерт: «Яшьләр

СИШӘМБЕ

26 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00- 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.20 Мультфильм. 18.30 «Яшьләрне көтәбез». Казан медицина колледжыннан репортаж. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Теплоконтроль. Базарга адымнар». 19.55 «Әлли-бәлли-бәү». 20.15 «Тукталыш». 20.30 Күп серияле нәфис фильм премьерасы: «Тарзан». 14 нче һәм 15 нче серияләр (Мексика - Канада - Франция). 21.15 «Пульс». Медицина программасы. 21.30 «Очрашулар». Разил Вәлиев, Надир Дәүләт. 22.10 «Китәсез дәмени, аккошлар...» Концерт. 22.50 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!». 7.10 Мультфильм: «Волшебник Изумрудного города». 5 нче серия. 7.30, 20.20, 22.55 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (25 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.15, 13.35 «90х60х90». 9.30 Мультфильмнар: «Лесные путешественники», «У страха глаза велики». 10.05 Балалар сериалы: «Неоновый всадник». 11.00 «Юл патруле». 11.10 Атналык фаразлар. 11.35 «Даруханә». 11.45, 13.50 «Валюта бәясе». 11.50 «ПОСТ» - музыка яңалыклары. 12.10 Нәфис фильм: «Вариант «Омега». 1 нче серия. 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Минем кино». Ольга Кабо. 15.50 «Музыка һәм матбугат». «Каләм осталары». «ЧАЙФ» группасы. 15.55 Вера Васильеваның юбилеена карата. Сатира театры спектакле: «Безумный день или женитьба Фигаро». 18.30, 21.05 Эфирда - музыка. 18.40 Сериал: «Против течения». 4 нче серия. 19.30 «Хокук каналы». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 «Коммерция әйләнмәсе». 21.15 Телеэкспресс 21.35 «Татсоцбанк»: читтән караш. 21.40 Русия кинносы көне. Нәфис фильм: «Русские братья». 23.20 «TAP RECORDS» коллекциясеннән: Вудсток-94. 1 нче кисәк.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.00 «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Әгәр». В.Познерның авторлык программасы. 10.35 Хайваннар дөньясында. 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда - «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Сериал: «Овод». 2 нче серия. 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 «Кара, тыңла». 16.20 «Кактус һәм К». 16.30 «Кварьете - күңелле квампания». 16.40 «Марафон-15». 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Джем». 18.00, 21.00 «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 «Беренче куллардан». 22.05 Футбол. УЕФА кубогына. 1/32 финал. «Ливерпуль» (Англия) - «Спартак-Алания» (Владикавказ). Англиядән трансляция. Тәнәфестә (22.55) - «Юрамалар». 0.10 «Останкино» хит-парады. 1.20 Телесериал: «Улицы Сан-Франциско». 2.10 «Спортның җиде көне».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 Клип-антракт. М.Шуфутинский. 8.50 «Кирәк... кирәк...» 10.55 «Телегазета». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 Сергей Есенин. «Соңгы шагыйрь». 5 нче тапшыру. 11.35 Музыкаль экспромт. 11.50, 17.45 Мультсериал: «Камень сновидений». 12.15, 16.20 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.50 «Ай тотучы». 17.20 «Көн дә бәйрәм». 17.30 «РОСТ» компасы. «Тозлы җил». 18.10 Әдәби-публицистик цикл премьерасы: «Русия. Мәхәббәттә аңлашу». 18.40 «Ле Монти» сәүдә йорты. 18.55 Шахмат буенча дөнья беренчелегендә. Г.Каспаров — В.Ананд. 19.10 «L» клубы. 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Күңел ачу программасы: «Шәһәрчек». 21.10 Футбол. УЕФА кубогына. 1/32 финал. «Локомотив» (Мәскәү) - «Бавария» (Мюнхен). «Локомотив» стадионыннан тапшыру. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «Криминаль хәбәрләр экраны». 23.50 Нәфис фильм: «Берлин, Александр Платц» (ГФР). 10 нчы серия.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 9.40 «Рекордлар». 10.00 «Төш юрау». 10.45 «Кумирлар». 11.15 «Аукцион». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.25 Мультфильмнар. 13.50, 15.40 «Музыка мизгеле». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.45 «Кеә» кинокана-лы. Нәфис фильм: «Военно-полевой роман». 17.20 «Бөтен Русия буйлап». 17.30 «Рязань-95» телевизион программалар фестивале. «Яраткан Русь һәм Мордва». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Нәфис телефильм: «Нежный образ твой». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 1.00 Төнге детектив: «Три ненастных дня». Режиссер Л.Цуцульковский. 2.15 Рус композиторлары романслары.

ЧӘРШӘМБЕ

27 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00- -8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «Татарстан». 19.30 Нефтьчеләрнең аграр цехлары. «Татнефть» акционерлык җәмгыяте. 20.05 «Әлли-бәлли-бәү». 20.25 Сәнифә Рангулова җырлый. 20.45 Нәфис фильм: «Ашик-Кериб». 21.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

6.55 «Зарядкага басыгыз!» 7.05 Мультфильм: «Волшебник Изумрудного города». 6 нчы серия. 7.30, 20.20, 23.55 «Шәһәр» информацион программасы. 7.50 Телеэкспресс (26 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 Документаль фильм: «У магнита есть секреты». 8.35, 10.05 Балалар өчен сериал: «Неоновый всадник». 17 нче һәм 18 нче серияләр. 9.25, 13.35 «90х60х90». 9.45 Мультфильм: «Крепыш». 11.00, 18.25 Юл патруле. 11.15 «Атна низагълары». 11.40 «Даруханә». 11.50, 13.50 «Валюта бәясе». 11.15, 18.10 «ПОСТ» - музыка яңалыклары. 12.15 Нәфис фильм: «Вариант «Омега». 2 нче серия. 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Мане яки ирексездән яңалык кертүче». 15.00 Нәфис фильм: «Все Вермееры в Нью-Йорке» (АКШ). 16.30 Мажаралы сериал: «Мегрэ колеблется». 2 нче серия. 18.35 Эфирда - музыка. 18.55 «Элекон» тәкъдим итә. 19.00 Актуаль әңгәмә. Студиядә - Татарстан Республикасы Премьер-министры Ф.Мөхәммәтшин. 19.25 «Поза». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 «Enter club». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 «Үз кешеләр». 22.10 Триллер: «Даже ангелы падают с небес». 0.20 «TAP RECORDS» коллекциясеннән. Вудсток-94. 2 нче кисәк.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.15 «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Тема». 10.50 «Сәяхәтчеләр клубы». 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Сериал: «Овод». Соңгы сериясе. 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 «Күңелле ноталар». 16.20 «Читлектәге балалар». 16.30 «Күңелле җырлар» конкурсы. 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Тин-тоник». 18.00, 21.00 - «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Киномандзара». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 0.00 «Юрамалар». 0.30 Футбол. Чемпионнар лигасы. 7 матчка күзәтү. 1.55 Сериал: «Улицы Сан-Франциско».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Телегазета». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Төп мизгел». 9.05 «Пилигрим». Русиянең сәяхәтләр бюросы. 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 «Беркем дә онытылмаган». 11.20 «Ике тормыш һәм бер язмыш». 11.45 «Клип-антракт. 11.50, 17.50 Мультсериал: «Камень сновидений». 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Кайсы як?» 17,20 Яңа тармак. «Ерак Көнчыгыш». 18.15 «Җиңү адымнары» телемарафоны (Калач-на Дону шәһәре). 18.55 Шахмат буенча дөнья беренчелегендә. Г.Каспаров - В.Ананд. 19.10 Сезне «Савва» фирмасы чакыра. 19.25 «Үз уены». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Рек-тайм». 22.05 «Губернаторлар клубы». 22.45 «Криминаль хәбәрләр экраны». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Киномарафон. Нәфис фильм: «Охота на лис».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45. 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.20 «Гүзәллек». 9.40 «Күңел». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Такмаклар». 11.15 «Аукцион». 12:10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.25 Рус композиторлары романслары. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.20 Бакчачыларга киңәшләр. 15.40 «Музыка мизгеле». 15.45 В.Виноградов фильмнары: «Русский дом». 2 нче фильм. 16.55 Г.А.Товстоногов турында телефильм: «Жить, думать, чувствовать, любить». 17.45 «Рязань-95» телевизион программалар фестивале. «Мещора уйдырмалары». 22.05 «Вариацияләр». Ж.Бизе музыкасына балет. 22.20 «Хатирәләребез җырлары». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 «Гыйбадәтханә». 23.40 «Туган көнем сезнең белән бергә». Эдита Пьеха. 0.40 Төнге детектив: «Третий дубль». 1 нче серия. Режиссер Л.Цуцульковский.

ПӘНҖЕШӘМБЕ

28 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.40 Мультфильм. 18.50 «ГАИ мәгълүматлары». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Хокүмәт сәгате». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.20 «Шигърият». 20.40 «Торналар киткәндә». Мирсәет Сөнгатуллин җырлый. 21.00 «Бола клубы». 21.30 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Волшебник Изумрудного города». 7 нче серия. 7.30, 20.20, 23.55 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (27 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Гасырлар чоңгылыннан». «Хакимият, дәрәҗә һәм байлык». 9.20 Мәскәү музейларының сәнгати байлыклары. 9.45 Нәфис фильм: «Джаз в Джексонвиле». 2 нче серия. 10.45 «Билгеләр». 11.15 «21 нче параграф». 11.40 «Бөтенләй башкалар: караңгы залда яктылык нуры». 12.15 «Барысын да белергә телим». 12.30 Нәфис фильм: «Вариант «Омега». 3 нче серия. 13.50 Ток-шоу: «Мин үзем». «Миңа бала кирәк». 14.45 Нәфис фильм: «Ожидание». 16.00 Мажаралы сериал: «Мегрэ у министра». 17.20 «ПОСТ» - музыка яңалыклары. 17.35 «Юл патруле». 17.45 «Мәхәббәт көйләре». 18.15 «Видеогид». 18.35 «Кыюлар һәм матурлар». 19.05 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә. 19.10 «Турыдан-туры элемтә». Студиядә - Казан мэры. Тема: «Кышка әзерлек ничек бара?» 20.45 «Коммерция әйләнмәсе». 21.05 «Казанские ведомости» нәрсә турында сөйләде». 21.10 Эфирда - музыка. 21.15 «Телеэкспресс». 21.35 «Бары тик көлке өчен генә». 22.05 Атна фильмы. Нәфис фильм: «Лукреция Борджиа» (Франция — Италия). 0.20 «Битлекләр» «Опера-2»дә.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.10 «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 Футбол. Чемпионнар лигасы. «Спартак» (Мәскәү) - «Легия» (Варшава). 2 нче тайм. «Ювентус» (Италия) - «Стяуа» (Румыния). 2 нче тайм. 12.20 Эфирда - «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Нәфис фильм: «Последнее дело комиссара Берлаха». 1 нче серия. 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 Мультитроллия. 16.20 «Золушкада балда». 16.40 «Компьютер-холл». 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята». 17.30 «16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәкләр...» 18.00, 21.00 «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 «Лотто-миллион». 20.00 «Хәтерләсеннәр өчен...» Л.Фетисова. Л.Филатов алып бара. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Мәскәү. Кремль. 22.10 Лукино Висконти фильмы: «Чувства». 0.25 «Юрамалар». 0.40 «Яңа обывательләр». 1.30 Сериал: «Улицы Сан-Франциско». 2.20 «Спортның җиде көне».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Телегазета». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Төп мизгел». 9.05 Документаль фильм: «Четвертая жизнь Кувейта». 9.35 «Сәүдә йорты». 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 Музыкаль телефильм: «Марина». 11.45, 17.50 Мультсериал: «Камень сновидений» (Бөекбритания). 12.10 «Яңа тармак». 12.25 «Беркем дә онытылмаган». 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «РОСТ» компасы. «Исәнмесез!» 17.20 Яңа тармак. «Бүгенге фән». 18.15 «Сезнең партнер». Русиянең тимер юллары. 18.30 «Әйдән баручы фаразы». 18.55 Евгений Светланов. «40 елдан соң». 19.25 «Барлык кешеләр музыкасы». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.35 «Хроно. Авто һәм мотоспорт дөньясында», 22.05 XX гасыр кадрда һәм кадр артында. «Билгесез Ромм». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 Футбол. Кубоклар иясе кубогына. 1/16 финал. «Арарат» (Ереван) - «Динамо» (Мәскәү). Ереваннан тапшыру.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 9.15 «Гүзәллек». 9.40 «Рекордлар». 10.15 «Төш юрау». 11.15 «Аукцион». 12.15 «Спартак». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.25 Фильм-концерт: «Яшьләр дуэты». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телесериал: «Мануэла». 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.40 Музыка мизгеле. 15.45 Балалар өчен нәфис фильм: «Соловей». 17.15 Мультфильм: «Бюро находок». 3 нче һәм 4 нче фильмнар. 17.20 «Бөтен Русия буйлап». 17.35 «Рязань-95» телевизион программалар фестивале. «Язмышлар китабын актарганда» (Пенза). 22.15 Музыка мизгеле. 22.20 «Наобум». Армен Джигарханян. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 «Бу исемне онытма». Татьяна Сержан һәм Анатолий Рыбалко. 23.40 Төнге детектив: «Третий дубль». 2 нче серия. Режиссер Л.Цуцульковский. 1.00 Музыкаль телефильм: «Романса трепетные звуки».

АТНАЛЫК МАНЗАРА TV

ҖОМГА

29 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «Татарстан». 19.30 Хоккей. МХЛ чемпионаты. «Ак Барс» (Казан) — «Нефтехимик» (Нижнекамск). Тәнәфестә — «Әлли-бәлли-бәү». 20.45 «Ислам чакыруы». 20.55 «Җомга көн кич белән». Альманах. 21.25 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Волшебник Изумрудного города». 8 нче серия. 7.30, 20.20, 0.25 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 «Турыдан-туры элемтә» (28 сентябрь тапшыруын кабатлау). 9.00 «Телеэкспресс» (28 сентябрь тапшыруын кабатлау). 9.20 «Эфирда — музыка». 9.35, 13.35 «90х60х60». 9.55 Балалар өчен сериал: «Неоновый всадник». 10.50, 18.10 Юл патруле. 11.00 «Атнага бер тапкыр» юмористик программасы. 11.30 «Даруханә». 11.40, 17.50 «ПОСТ — музыка яңалыклары». 11.55, 13.50 «Валюта бәясе». 12.05 Нәфис фильм: «Вариант «Омега». 4 нче серия. 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Нью-Йорк, Нью-Йорк». 15.00 С.Бондарчук фильмы: «Бархатный сезон». 16.45 Маҗаралы сериал: «Мегрэ у министра». 2 нче серия. 18.20 Мультфильм: «Приключение кузнечика Кузи». 18.40 «Суперспорт». 19.00 Сериал: «Корабль любви». 4 нче серия. 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 «Галәмдәге балкон». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Сериал: «Сирены» (АКШ). 22.30 Патрик Суэйзи «Дом у дороги» боевигында. 0.50 Куркыныч фильм: «Муха».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.50 Яңалыклар. 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Хәтерләсеннәр өчен...». Л.Фетисова. Л.Филатов алып бара. 10.50 «Бәллүр башмак». 10.40 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Нәфис фильм: «Последнее дело комиссара Берлаха». 2 нче серия. 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 Балалар өчен телесериал: «Белый клык». 16.25 «Орфей йолдызлыгы». 16.35 «Яңа чынбарлык». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 «Рок-дәрес». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Кыргый кыр». 19.25 «Кеше һәм закон». 19.55 «Могҗизалар кыры». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Телесериал: «Рейли — король шпионов» (Бөекбритания). 22.55 «Юрамалар». 23.10 «Караш». 0.05 Музыка күзәтүе. 1.10 Телесериал: «Улицы Сан-Франциско». 2.00 «Спортның җиде көне».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 Клип-антракт. Н.Платицына. 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Үтә яшерен». 9.45 «Телегазета». 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 Телевизион фестиваль призерлары. Документаль фильм: «Только имя да эхо...» 12.10 «Яңа тармак». 12.15 «1995 ел укытучысы» Бөтенрусия конкурсы көндәлеге. 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «РОСТ» компасы. «Балалар елмайсыннар». 16.50 «Ай тотучы». 17.20 «Җомга саен Дисней». Нәфис фильм: «Скандальный Джон». 19.20 «Клип-антракт». 19.25 Вертикаль. «Хөкүмәтнең эш көннәре». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 Бию-экспресс. 21.45 Шахмат буенча дөнья беренчелегендә. Г.Каспаров — В.Ананд. 22.05, 23.45 «Азия тавышы». Популяр музыка һәм җырларның 6 нчы халыкара конкурсы. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 «Балалар өчен». 9.20 «Гүзәллек». 9.40 «Күңел». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Кумирлар». 10.45 «Такмаклар». 11.15 «Коллекционерлар». 12.10 Джаз. 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.25 Мультфильм: «Бюро находок». 1 нче һәм 3 нче фильмнар. 13.50, 15.40 «Музыка мизгеле». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телесериал: «Мануэла». 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.45 Ура, комедия! Нәфис фильм: «Жених из Майами». 17.05 ТВ мәгълүматлары. «Европа калейдоскобы». 17.35 «Рязань-95» телевизион программалар фестивале. «Иске җырның гомере озын» (Мурманск).

22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Чит ил киносы антологиясе. Нәфис фильм: «Величайшая битва» (АКШ). 0.50 Төнге детектив: «Среда обитания». Режиссер Л.Цуцульковский. 2.00 Ретро. Музыкаль телефильм: «Городская фантазия».

ШИМБӘ

30 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Видеоспорт». 19.45 «7 нче стиль». 20.10 «Әлли-бәлли-бәү». 20.15 «Гадәти шимбә». 20.55 Сания Хантимерова бенефисы. 22.10 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Волшебник Изумрудного города». 9 нчы серия. 7.30 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (29 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.10 «Коммерция әйләнмәсе» (26 сентябрь көнендәге тапшыруны кабатлау). 8.30 «Видеомода». 8.50 «Камиллек». 9.20 «700 нче клуб». 9.50 «Хокук каналы». 10.10 «Поза». 10.35 «Үз кешеләр». 11.10 Мультфильм: «Аргонавты». 11.35 «Чаплиниада». «Хатын-кыз». 12.00 Хәрби телевидение. 12.40 «Спорт атнасы». 13.15 Мультфильм: «Следствие ведут знатоки». «Без ножа и кастета». 15.45 «Павловск турында хатирәләр». 16.15 «Эфирда — музыка». 16.25 Телесериал: «Тропическая жара». 17.20 Телесериал: «Детективы на полставки». 18.15 «Яшерен йомыш». 18.40 «Йозак тишеге». 19.00 «Исәнмесез!». 21.00 «Мавыгулар дөньясы». 21.30 Сериал: «Сирены» (АКШ). 22.30 «Диңгез ярында аттракционнар». 23.00 «Музыкага чикләр юк». 0.00 Нәфис фильм: «Тело-двойник».

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 8.45 «Пастырь сүзе». Митрополит Кирилл. 9.00, 15.00, 0.55 Яңалыклар. 9.20 «Иртә таңнан». 9.50 Балаларга фильм: «Кешка и гуманоид». 10.10 Мультфильм: «Синица, роща и огонь». 10.30 «Иртәнге почта». 11.00 «Татлы». 11.20 «Сәламәтлек». «Үзеңә үзең булыш». 11.50 «Кабардино-Балкариянең бүгенгесе һәм киләчәге». 12.20 «Бомонд». 12.40 Вера Васильева «Свадьба с приданым» кинокомедиясендә. 14.25 «Көзге». 15.20 «Зур узышлар». 15.45 Елена Проклова «Ключ без права передачи» фильмында. 17.20 «Хайваннар дөньясында». 18.00, 21.00 «Вакыт». 18.20 «Америка М.Таратута белән». 18.50 Маҗаралы детектив: «Золото партии». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Телесериал: «Рейли — король шпионов». 22.55 «Брейн-ринг». 23.40 «Һәркемнең телендә». Н.Дарьялова алып бара. 0.10 Баскетбол. Суперлига чемпионаты. Ир-атлар. «Динамо» (Мәскәү) — «Спартак» (Мәскәү). 1.00 Телесериал: «Улицы Сан-Франциско». 2.05 «Манхэттен-трансфер» Мәскәүдә.

«РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Шөреп»тән башлап». 8.45 «Мазай бабай кунакханәсе». 9.00 «Шәп авыл». 9.30 Пилигрим. Русиянең сәяхәтләр бюросы. 10.15 «Октябрь аенда кино». 10.30 «Алтын шпор». 11.00 А.Гурнов. «Саф инглизчә репортаж». 11.10 «Мәскәүгә кадәр ерак». 11.55 Көндезге сеанс. Нәфис фильм: «Большое золото мистера Гринвуда». 13.05 «Тайны животных» телесериалыннан документаль фильм: «Экстрамадура — забытые леса Испании». 14.20 «Де факто». 14.35 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм: «Буря над Ла-Маншем». 15.20 Мультконцерт: «Романтики с большой дороги». 15.45 Русиянең телевизион театры. «Жить до страха и воли...» С.Есенинның тууына 100 ел тулуга карата. 16.55 Футбол. Русия чемпионаты. «Локомотив» (Түбән Новгород) — «Локомотив» (Мәскәү). Түбән Новгородтан трансляция. 18.55 Шахмат буенча дөнья беренчелегендә. Г.Каспаров — В.Ананд. 19.05 «Ике катлы портрет. 20.25 Телеэкран премьерасы. Нәфис фильм: «Дама с камелиями» (Польша). 20.20 Клип-антракт. О.Газманов. 22.25 Джентльмен-шоу. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «А» программасы. 0.40 Төнге сеанс. Нәфис фильм: «Жажда страсти».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.30 «Христос — бөтен дөньяда». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан-туры элемтә». 10.00 «Әйләнә-тирә мохит атнасы». Документаль фильм: «Бумага». 10.25 Фильмоскоп. Нәфис фильм: «Райская птичка». 12.35 «Минем музыка». 13.05 «Теледоктор». 13.25 «Палитра» циклыннан телефильм: «Тулуз-лотрек» (Франция). 14.00 Тест. 14.15 «Тарихи альманах». 14.15 Нәфис фильм: «Я вижу солнце». 16.15 Тынлы оркестрлар фестивале. 16.45 Мультфильм: «Бим, Бам, Бом и Волк». 17.00 «Чуар эт». 17.20 «Зебра»га музыкаль остәмә». «Буй-буй хит». 17.50 «Музыка мизгеле».

22.20 «Теле-граф». 22.40 ТВ мәгълүматлары. 23.00 Нәфис фильм: «Зона смерти» (АКШ). 0.25 «Алкышлап». «Парадлар парады» Лев Лещенконы тәкъдим итә.

ЯКШӘМБЕ

1 ОКТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «ТОН» (атналык телекүзәтү). 19.35 «Автокалейдоскоп». 19.50 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «Көлке капчыгы». Юмористик-музыкаль тапшыру. 22.00 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау). 8.30 «Коммерция әйләнмәсе» (28 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.50 «Бары тик көлке өчен генә». 9.20 «Видеогид». 9.40 «Суперспорт». 10.00 «Enter club». 10.30 «Мавыгулар дөньясы». 11.00 «Йозак тишеге». 11.20 Мультфильм: «Конек-Горбунок». 12.30 Телесериал: «Подводная «Одиссея» команды Кусто». 13.25 «Ералаш». 14.10 Нәфис фильм: «Командир счастливой «щуки». 15.50 «Канун». Православие чиркәвенең ингезләре турында әңгәмә. 16.20 Нәфис фильм: «Молчание доктора Ивенса». 17.50 «Элекон» тәкъдим итә». 17.55 Телесериал: «Тропическая жара». 18.50 Телесериал: «Детективы на полставки». 19.45 «КиноМеню». 20.15 «Җирле вакыт». Информацион программа. 20.45 Нәфис фильм: «Деловые женщины» (АКШ). 22.30 «Исәнмесез!» (30 сентябрь тапшыруын кабатлау). 0.30 Нәфис фильм: «Муха-2».

1 НЧЕ КАНАЛ

8.00 «Уяныгыз!» телеканалы. 10.30 «Бар да өйдә чакта». 11.05 «Иртәнге йолдыз». 11.50 «Русиягә хезмәт итәм». 12.20 «Уйна, гармун». 12.50 «Пи» билгесе астында. 13.30 «Алтын кадр». Ираклий Андроников Сергей Есенин турында. 13.55 «Неагара шарлавыгы». 14.35 «Африка арысланнары». Цирк программасы. 14.50 Мультфильм: «Большой Ух». 15.00, 18.00, 1.20, Яңалыклар. 15.20 Музыка көне. 16.15 Сәяхәтчеләр клубы. 17.00 Мультсериал: «Остров сокровищ» (Бөекбритания), «Наездники на динозаврах» (Австралия). 18.20 «Футбол күзәтүе». 18.50 «Күзгә-күз». А.Любимов алып бара. 19.15 «Ак попугай» клубы. 20.05 Елның иң яхшы анимацион фильмнары: «Гагарин». 20.10 Арнольд Шварценеггер һәм Шарон Стоун «Вспомнит все» фантастик боевигында. 22.00 «Якшәмбе». 23.00 Телесериал: «Рейли — король шпионов». 0.00 «Бер күрүдә ярату». 0.35 Баскетбол. Суперлига чемпионаты. Ир-атлар. ЦСКА — «Автодорожник» (Саратов). 1.40 Сериал: «Улицы Сан-Франциско». 2.30 «Кумирлар, кумирлар...» И.Понаровская.

«РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Беренче дубль». 9.00 «Футболга чикләр юк». 9.45 «Хәерле иртә, Европа». 10.15 «Беренче нөсхә». 10.25 «Аты-баты...» 10.55 «Консолидация». 11.00 «Рус лотосы». 11.45 Нәфис фильм: «Небо нашего детства». 13.15 Шахмат буенча дөнья беренчелегендә. Г.Каспаров — В.Ананд. 13.30 Кипрас Мажейка. «Параллельләр». 13.45 «Кайнар уңлык». 14.20 «Кисеп бетерә алмаслык». 14.35 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм: «Буря над Ла-Маншем». 2 нче кисәк. 15.25 «Синең мөмкинлекләрең, кеше». 15.55 «Формула-1» классында автоузышлар буенча дөнья чемпионаты. Аурупа Гран-прие. Нюрбургрингтан трансляция (Германия). 18.00 Мультфильмнар: «Чокнутый», «Новые приключения Винни Пуха». 19.00 «Шарман-шоу». 20.25 Телеэкран премьерасы. Нәфис фильм: «Нулевой допуск» (АКШ). 20.00 Клип-антракт. «Ф.Киркоров белән чәй янында». 22.10 «Тапшырулар тартмасы». 22.25 «Ксюшада кунакта». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «Киноафиша». 23.55 Оста классы. Л.Долин.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Бу сезнең көнегез». 7.30 «Шифалы сүз». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан-туры элемтә». 10.00 Мультфильм: «Еж, пес и мальчик Нико». 10.30 Телеэкранда детектив. Нәфис фильм: «Джанго» (Италия). 12.00 «Якшәмбе лабиринты». 13.10 «Страсти-мордасти». 13.25 Документаль фильм: «Суворовцы». 13.55 Фильм: «ЮАР: дорога к процветанию». 14.10 «Классика-5» Гэри Карр. 15.30 Депутатларга сүз бирәбез. 16.00 «Балалар телевидениесе». «Ыргыт, әйдә». 16.45 Телефильм: «На струнах осени». 16.55 Футбол буенча Италия чемпионаты. Турыдан-туры трансляция.

22.05 «Датасыз хатирәләр». 22.45 ТВ мәгълүматлары. 23.10 «Адәм алмасы».

ДҮШӘМБЕ, 25 СЕНТЯБРЬ

6.00, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 20.38 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.00 Информацион-музыкаль программа. 7.45, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 18.30, 20.45 — Радио-1. 17.45 «Язучылар — балаларга». 18.15 «Дүшәмбедән — дүшәмбегә». Мәдәният яңалыклары. 19.45 «Үзешчән сәнгатьтә катнашучылар концерты».

СИШӘМБЕ, 26 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 14.30, 18,30 20.45 — Радио-1. 12.25—14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Башкортстан артистлары концерты. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Юллар чатында» информацион программасы. 13.45 «Турыдан-туры элемтә» 17.45 «Яшьлек» студиясе. 18.15 «Көн темасына». Әңгәмәләр, аңлатмалар. 19.45 «Яшь башкаручылар концерты».

ЧӘРШӘМБЕ, 27 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Татарстан дулкынында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.53 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.53 — Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 21.00— Радио-1. 12.25—13.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Концерт. «Без Татарстан җирендә яшибез». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Старт» (Татар телендә). 19.45 Сораулар буенча концерт.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 28 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 14.30, 18.30, 20.45 — Радио-1. 12.25—14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 «Балалар җырлый». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Туры эфирда әңгәмә» 18.05 «Бизнес клубы». 19.45 «Эстрада ритмнары».

ҖОМГА, 29 СЕНТЯБРЬ

6.00 «Балкыш». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.00, 13.05, 19.15 — «Соңгы хәбәрләр». 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 20.45 — Радио-1. 12.25-13.30 «Көн үзәге» информацион нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 В.Шәрипова концерты. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Чишмәләр» (чуваш телендә). 19.45 «Композитор Исмай Шәмсетдинов». Туусына 85 ел тулу уңаеннан концерт-очерк.

ШИМБӘ, 30 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00 Соңгы хәбәрләр. 6.15 Авыл эшчәннәре өчен концерт. 6.58, 7.58, 14.30 Һава торышы. 7.15 Концерт. 7.45, 14.30 — Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00, 11.00, 14.35 — Радио-1. 8.15 «Сезнең хатларыгыз». 8.25 «Мәсьәләгә бер караш». 8.40 «Көмеш кыңгырау». 9.00 С.Есенинның тууына 100 ел тулуга карата тапшыру. 9.30 «Көн артыннан көн. 10.30 «Танышу». 11.45 «Кардәшлеккә чикләр юк». 12.15 Татар халык көйләре. 13.10 Яңалыклар эстафетасы. 13.30 «Яшьлек» студиясе. 14.00 «Әбугалисина» клубы.

ЯКШӘМБЕ, 1 ОКТЯБРЬ

7.02, 7.58, 13.40 — Һава торышы. 7.04 «Хәерле иртә!» 7.45, 13.40 — Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00 «Идел белән Урал арасында». Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы. 9.00 «Гөлбакча». 9.30 «Шигърият». Ф.Яруллин шигырьләре. 10.45,16.35 — Радио-1. 11.45 «Яктылыкны һәм изгелекне яклап». Өлкәннәр һәм балалар өчен. 12.15 «Тел күрке — сүз». 12.45 Ял концерты. 13.45 «Татарстан дулкынында». 14.23 Т.Миңнуллин. «Үзебез сайлаган язмыш». К.Тинчурин исемендәге ТДДК спектакле монтажы.





Зәһид МӘХМҮДИ

SOS: «Башкалабыз чүплек башында»

Өч-дүрт көн генә аерылып торсам да, Казаныма очар коштай ашкынып-сагынып кайтам мин. Әмма аның шапшак урамнарына аяк басуга барлык якты хисләр дә сүнә, күңелне сәер мескенлек һәм кызгану хисе биләп ала. Юк, килешмим мин Тукай белән. Дәрте дә юк, нуры да юк аның хәзер. Һәр чаты – бәдрәф, һәр урамы – чүплек. Шулай булгач, ничек итеп нурлы булсын ди ул? Матурлыкка болай матур үзе. Борынгы кала, борынгы йортлар, борынгы скверлар... Ләкин шапшак. Хәер, хуҗабикә нинди булса, йорты да шундый инде. Казаныбыз борын тотып кына, күзләрне йомып кына йөри торган фатирга охшап кала сыман. Аның бүген милли комганы да, ак сөлгесе дә юк – ул кәгазьгә мөкиббән. Җаның кушкан урынны сайла – телисең икән, подъездга кереп утыр, телисең икән – берәр агач төбенә. Кайберәүләр хәтта урам уртасында утырудан да тартынмыйлар. Чөнки беләләр: агач төбендә булдыңмы, урам уртасында ни, эләктерсәләр, барыбер алып китәләр, барыбер штраф түлисе. Закон телендә вак хулиганлык дип атала бу. Беркетмәгә, әлбәттә, «сүгенде, дорфа кыланды», дигән сүзләр дә өстәргә онытмаслар «атлы казаклар»ың. Мондый хәл булмады, дип кәҗәләнмә, юкса тиз генә чыгып та китә алмассың.

Закон ак атта, ә халык?

Чын булгандырмы ул, юкмы, бервакыт Казанда шундый мәзәк таралды.

Телсезне урамда табигый хаҗәтен үтәп торганда эләктергәннәр. Тиз генә түләп чыгып китәргә акчасы булмаганмы, төгәл өч тәүлек утырып чыккан бу. Гаепләү беркетмәсендә шундый сүзләр: «Выражался нецензурными словами на общественном месте». Нишлисең бит, бер беркетмәне икенчесенә күчереп кую өчен әллә ни зур баш кирәк түгел.

Буталган башы сержантның. Ә алар һаман күчерәләр, күчерәләр...

Сүз уңаеннан шуны әйтеп үтәсе килә: берәр милиция генералының ул вак хулиганнарны ябып тота торган мәхбүсханәгә кереп караганы бар микән? Аллам сакласын, керә күрмәсен инде. Анда, малай, мәхшәр! Борын тотып керә торган подъезд гына түгел ул сиңа, йогышлы авырулар котыра торган бу заманда бер дигән чир тарату урыны да. Тагын да төгәлрәк әйтсәк, сезгә һәм безгә каршы эшли торган чып-чын бактериологик лаборатория. Ун-унбиш мәхбүс бер савыттан су эчә анда. Иң түрдәге бер почмакта унитазсыз гына бәдрәфе дә бар. Урын җитмәгәндә, аны йоклау урыны буларак файдаланалар. Арада төрле бәндәләр очрый. Урамдагы чүп савытыннан гуклана торган сәрхушлардан алып әллә нинди зыялыларга кадәр эләгә монда. Дөреслеккә хилафлык китермик, бу хокуксыз һәм пычрак дәүләттә инсафлы кеше дә бәхетсезлеккә юлыгырга мөмкин бит. Аннан чыккан һәр адәм баласын ким дигәндә бер ай буе медицина күзәтүе астында тотарга кирәк. Юкса, иманым камил, хатыны һәм баласына да нинди дә булса бер авыру йоктырачак. Киная белән әйтмим, бу – ачы хакыйкать.

Ярый инде, хәзер тагын бәдрәфләр мәсьәләсенә кайтыйк. Калабызда чиләк белән дуслашкан гаиләләр дә бар икән. Мәсәлән, Бауман урамындагы 39 нчы йортта яшәүчеләр инде биш-алты ел буена чиләктә утыра-утыра бәдрәф дигән сүзне тәмам онытып җибәргәннәр. Дөрес, ул йорт тиздән сүтелергә тиеш. Анда яшәүчеләрнең кайберләренә фатир да биргәннәр. Әмма без биологик җан ияләре һәм бәдрәфтән башка бер генә көн дә яши алмыйбыз. Шулай булгач, анда барлык гаиләләр дә күченеп киткәнче бер бәдрәф булдырырга яисә булганын саклап калырга кирәк иде.

Әлеге йортның подъезды, андагы ярымҗимерек йортлар инде күптән шәһәр бәдрәфенә әверелгән. Ул – сержантлар өчен бер дигән «засада» урыны. Әллә кайдан вак хулиганнарны (бәдрәф эзләп йөрүчеләрне) эзләп йөрисе юк, эш бара, план үтәлә... рәхәт дөньялар!

Халык мыжлап торган үзәк урамда бер җәмәгать бәдрәфе дә булмагач, адәм баласы подъездга кермичә ни эшләсен? Бу уңайдан, мин кечкенә генә тәкъдим кертәм: штраф түлисең килмәсә, үзең белән чиләк йөрт. Шулай итсәң, сиңа берәү дә бәйләнмәс.

Аһ хәерче син, минем Казаным! Чүп савытларың да әллә кая китте. Юк, аяк астында аунап яткан тәмәке төпчекләре өчен борчылмыйм. Хәзерге кыйммәтчелек заманында аларны көндез чыра яндырып эзләп йөрсәң дә, табып булмый. Ипи сыныкларының да, шешәләрнең дә кадере артты. Тик шәһәрдә башка төрле чүп тә житәрлек бит: гундырма савытлары, тәмәке каплары, шоколад-кәнфит кәгазьләре, шырпы каплары... Аларны кая куярга? Кесәгә салып йөрергәме? Кайчагында безгә берәр баерак дәүләт төрле тәмле-татлы әйберләр урынына күбрәк чүп савытлары җибәрсен иде, дигән уй да туып куя. И Ходаем, бу хыял тизрәк тормышка ашсачы!

Әйләнә-тирәгезгә әйләнеп карагыз, башкалабыз үзе дә дифтерия, холера, дизентерия кебек куркыныч авыруларны үрчетә торган гигант бактериологик лабораториягә әверелеп бара түгелме? Ә без кемнәр? Аның заложникларымы? Бу сорауга инде һәркем үзе җавап тапсын.

Милләтче Лысенко Исламга каршы сугыш игълан итә

Чакырылган кунак чакырылмаганыннан яманрак

Үзен чын урыс дип атаучы Николай Лысенко якшәмбе көнне булып узган «Бергә-бер» («Один на один») тапшыруындагы әңгәмәдән соң кул кысышудан баш тартып, башка бер русиялегә – Халит Яхинга карата бөтен ил алдында тупаслык күрсәтте.

Без, партияләрнең исемнәрен азмы-күпме укый белүчеләр, әле кул селти алабыз: сәясәт тирәсендә бөтенүчы оятсыз һәм тупас адәмнәр шактый күп инде бу фани дөньяда. Әмма мин башка нәрсәдән куркам: кайдадыр бер далада яисә тауларда, Уралга җитәрәк берәр шәһәрдә яисә Идел буендагы берәр авылда яшәүче егерме оныгы булган татар карчыгы, сүзгә саран калмык көтүчесе яисә Салават Юлаевның тиз кызып китүчән берәр оныгы ниндидер «главный» урыс телевизор аша Русиядә Исламның тыелуы турында игълан итте, дип уйларга мөмкин бит. Кешеләр бик тиз ышанучан һәм беркатлылар, ә бу архиурыс мактанчыгының бөтен кыяфәте генералларныкыдай һавалы, тавышы үзәккә үтәрлек һәм каршы әйтә алмаслык иде ки, әйтерсең, бөтен ил шул ук минутта абына-сөртенә аның әмерләрен тормышка ашыра башлар кебек иде.

Шуңа күрә дә бу беркатлы кешеләргә: «Аллаһы Тәгалә һәм урыс Алласы хакына булса да бу бәндәгә ышанмагыз», – дип әйтәсе килә. Берниндидә «главный» һәм урыс кешесе дә түгел ул, чөнки нормаль булган һәрбер урыс аның өчен бик ояла һәм үзен уңайсыз хис итә. Үзенең акыллы һәм тыйнак әңгәмәдәшенә сүз әйтергә ирек бирми торган гап-гади бер чәрелдек һәм тәрбиясез кеше ул.

Гафу итәрсез, әмма әңгәмә дингә һәм дөньяга булган карашларга белән уртаклашу рәвешен аласы урында, гаҗәеп ахмак бер төс алды. Әңгәмәдәшен тыңларга һәм җавап бирергә өйрәнмәгән милләтче әфәнде, әйтик, җинаятьләрнең күбесе төнге вакытта эшләнгәнлеген сылтау итеп, дөньядагы иң төп диннәрнең берсенә – Ислам диненә каршы сугыш игълан итте. Латин Америкасы наркокартельләренә күз йомып (католиклар җавап бирә торган зона), Н.Лысенко Мәскәү рэкетының (православие җимеше түгелме?) барлыкка килүен һәм дөньядагы барча явызлыкларны Ислам һәм «Нур» мөселман хәрәкәте җитәкчесе оештырды, дип әйтүгә кадәр барып җитте. Инде хәзер җилкәләрне генә сикертәсе кала. Ул бит үз конфессиясенең башка конфессияләр, бигрәк тә – күршедәге, шәһәр һәм авыл дәрәҗәсендәге конфессияләр белән тыныч яшәве турындагы фикерне алга сөреп азапланган иде.

– Бу мизгелдә бер мактанып алырга да мөмкин: безнең «главный» урыс яхшырак булачак бит! Әмма монда да очы-очка ялганып бетми бит әле: баш урыс, Грозныйны һәм чечен авылларын бомбага тотырып, үзен дә, безне дә хурлык баганасына китереп терәде. Шулай булгач, әллә ни мактанырлыгыбыз да юк. Безгә, никадәр генә яман булса да, чын күңелдән шуны әйтергә кирәк: башка диндәгеләрнең тамырына балта чабучы әфәнде үзен милләтне коткаручы дип күпме генә күкрәк какмасын, аңа «главный» һәм чәрелдек, күршеләренә үпкәләгән урыслар түгел, ә гап-гади, нормаль урыс кешеләре кул бирмәячәк. Андыйлар күбрәк булыр, мөгаен. «Главный»лар милләтенә караганда, сезнең белән безнең милләтебез беррәк. Ул үзара кычкырышмый торган кешеләр милләте.

Кызганыч, магур итеп елмая белүче (бераз каушабрак елмайса да) бәхәсләр өстәле хуҗасы Саша Любимовның бу турыда искәртергә һәм үз тапшыруының абруен саклап калу өчен генә булса да хәлне төзәтергә башына килмәде. Кул кысыштырырга теләгән икән, тотсын да үзе Халит Яхинның кулын кыссын иде ул. Юкса, чакырулы булса да, «главный» кунак үзен студиядә кергәннән артык хуҗаларча тота башлады бит.

Андрей ТАРАСОВ.
(«Литературная газета»).

Биеп узган гомер

Атаклы балетмейстер Гай ага Таһирга мәрсия

● *Бу рәсем Кәрим Тинчурин архивыннан алынды. Матбугатта беренче тапкыр басыла. Уңда — Гай Таһир.*

1907 елда Күмерлек (Кемерово) өлкәсендә туып бию сәнгатендә авыр да ләззәтле дә иҗат газаплары узган мәшһүр биючебез 88 яшендә Казанда вафат булды.

Татар сәнгатендә бәһаләп бетергесез хезмәт күрсәткән атаклы шәхес арабыздан китте. Тарих китте. Гай ага — бик күп олуг зыялылар белән табындаш, сабакташ, сәхнәдәш булган кеше. Кәрим Тинчуриннар, Солтан Габәшиләр, Фатыйма Ильскаялар, Салих Сәйдәшләр белән бергә иҗат иткән сәнгать әһеле.

Утыз биш балет һәм опера спектакльләрен сәхнәгә куйган, беренче татар опералары «Сания», «Эшче», «Качкын», «Алтынчәч» спектакльләрен тамашачыларга ирештергән, «Шүрәле» балетының беренче балетмейстеры Гай Таһир вафат. Җыр һәм бию ансамбле, шулай ук һәвәскәрләр сәхнәсеннән һаман төшмәенчә башкарыла торган «Мәдрәсәдәге вакыйга», «Казан кунаклары» һәм башка бик күп биюләрне китап итеп чыгарып калдырган мәңгеләштергән Гай ага Таһиров вафат.

Хатыны, күренекле артистка Галимә ханым Ибраһимова һәм бердәнбер кызлары белән татар театрына тарих онытмаслык хезмәт куйган сәнгатькәр иде ул. Галимә апа гомере буе театрда онытылмас образлар уйнады, халыкның мәхәббәтен казанды. Кызлары табибә буларак опера һәм драма артистлары, филармония җырчыларына ярдәм итте, аларны дәвалады. Ул да күптән түгел генә дөнья куйды. Өчесе дә мәрхүм инде. Бетте нәсел. Гай ага Таһир белән Галимә апа Ибраһимова токымы бу дөньяда төкәнде. Ләкин өчесенең дә рухы, алар турында хатирәләр, истәлекләр безнең белән яшәр. Алар майтарган эшләр тарихыбыздан җуелмас. Токымы төкәнсә дә, Гай ага Таһирның шәкертләре, аны остаз санаучы дәвамчылар бар. Алар мәрхүм Гай аганың эшен дәвам иттерер.

Авыр туфрагың җиңел булсын, Гай абый! Урыныгызны җәннәттән әйләсен! Амин!

«МӘДӘНИ ҖОМГА».

Кыз һәм үлчәү йолдызлыгы астында туганнар

КОТЛЫЙБЫЗ!

22 сентябрь

РӘКЫЙПОВ Шамил Җиһанша улы — язучы.

23 сентябрь

ИЖБОЛДИН Хәмидулла Габдрахман улы — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры опера солисты.

24 сентябрь

ХӘЙРУЛЛИН Мөнир Галиулла улы — Татарстанның атказанган архитекторы.

25 сентябрь

ТИМЕРБУЛАТОВ Шамил Харис улы — композитор.

РАХМАЙ ХИСМӘТУЛЛА (ХИСМӘТУЛЛИН Рәхмәтулла Хисмәтулла улы) — публицист, шагыйрь.

26 сентябрь

ӘЗҺӘР ГАБИДИ (ГАБИДУЛЛИН Әзһәр Сәмигулла улы) — шагыйрь.

27 сентябрь

МӘҺДИЕВА Надежда Эрнестовна — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры балет солисты, Татарстанның атказанган артисты.

МАЛЫШЕВ Сергей Владимирович — шагыйрь.

28 сентябрь

ГАНИЕВ Сирин Арслангали улы — рәссам.

ГАРИПОВА Зөләйха Шәкур кызы — театр эшлеклеләре берләшмәсе консультанты.

МАЛЬЦЕВ Станислав Викторович — медицина фәннәре докторы, профессор.

Әдәби кроссворд



ГОРИЗОНТАЛЬ БУЕНЧА: 5. Г.Кутуйның «Шатлык җыры» пьесасыннан персонаж. 7. Һ.Такташ шигыре. 8. Герблы, эмблемалы тукыма кисәге. 9. Татар халык әкияте. 12. Һ.Такташ шигыре. 14. Япон язучысы, «Феникс» романының авторы. 16. Һинд язучысы, «Кули» романының авторы. 17. К.Тинчуринның «Американ» комедиясеннән персонаж. 18. Алабугада яшәгән урыс язучысы, «Бухенвальд кыңгыравы» повестеның авторы. 19. А.Островскийның «Гроза» драмасыннан персонаж. 21. Ышанмау хисе. 23. Урыс совет шагыйре, «Сары Мотэл турында повесть» исемле поэманың авторы. 27. К.Тинчуринның «Зар» трагедиясеннән персонаж. 28. Халык ышанулары буенча ут рәвешендә йөри торган рух. 29. Буйга җиткән яшь ир кеше. 30. Янып торган матдәнең чөчелеп киткән вак кисәкчеге, чаткы.

ВЕРТИКАЛЬ БУЕНЧА: 1. Ш.Камал пьесасы. 2. М.Җәлилнең 1938 елда язган шигыре. 3. Ш.Камалның язылып бетмәгән пьесасы. 4. Г.Исхакыйның «Алдым-бирдем» пьесасыннан персонаж. 6. Поляк язучысы Б.Прус романы. 10. Татар язучысы, «Бормалы юллар» повестеның авторы. 11. Капма-каршысын белдерә торган сүз. 13. Г.Бәширов романы. 14. Ф.Хөсни хикәясе. 15. Кечкенә күләмле әдәби әсәр. 16. М.Җәлилнең 1942 елда язган шигыре. 20. Хуҗа Насретдин комедиясенең авторы. 22. М.Җәлилнең 1929 елда чыккан шигырьләр җыентыгы. 24. Бер телдә язылган әсәрне икенче тел чаралары белән бирү. 25. Уран планетасының иярчене. 26. Бельгия язучысы, «Морельдье» романының авторы.

Ренат ГАЛӘВИН төзеде.

«Мәдәни җомга»ның 4 нче санында чыккан кроссвордның җавабы

ГОРИЗОНТАЛЬ БУЕНЧА: 4. Тито. 6. Торт. 8. Тотализатор. 10. Такт. 11. Троцкий. 12. Төтәл. 13. Тута. 15. Табагач. 16. Терминал. 18. Талтирәк. 19. Такмак. 20. Типтәр. 21. Тылмач. 22. Тотрык. 24. Тмин. 25. Тол. 26. Төер. 28. Турнепс. 30. Тавык. 31. Триест. 34. Тарантелла. 35. Трио. 36. Тир. 37. Тракай.

ВЕРТИКАЛЬ БУЕНЧА: 1. Томау. 2. Тахта. 3. Тимошенко. 5. Токката. 6. Тәрәч. 7. Төмләткеч. 9. Тбилиси. 10. Трал. 12. Тарткы. 13. Тәртә. 14. Төлке. 15. Тартар. 17. Трюм. 18. Трактор. 20. Тотам. 23. Тантана. 25. Температура. 27. Тукыма. 29. Теплица. 30. Тайшет. 32. Театр. 33. Тавот. 34. Титр.

ЭШКӘ ЧАКЫРАБЫЗ

Руда булмаган материаллар комбинатына түбәндәге белгечлекләр буенча эшчеләр кирәк:

— стропальщик,
— порт кранчысы (үзгәрүчән график буенча);
— йөзмә кран кранчысы;
— йөзмә кран электр механигы;
— В, С, Д, Е категорияле машина йөртүче;
— экскаваторчы;
— автотөягеч йөртүче;
— газ һәм электр белән эретеп ябыштыручы;
— судно электр механигы;
— порт краннарын ремонтлаучы электрик;
— столяр,
— балта остасы.

350-50 л тибындагы электр земснарядлары сатыла.

Адрес:
Казан шәһәре,
Портовая урамы,
27 нче йорт.
Тел.: 32-93-70.

Бу санда Василий Мартинков (1 нче бит), Әсрар Шакирҗанов, Әкрам Шәфигуллин төшергән һәм авторларның шәхси архивыннан алган фотолар, Айдар Үтәганов рәсемнәре файдаланылды.

Мәдәни ҖОМГА

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәррир урынбасарлары
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары
32-62-79 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге;
32-58-91, 32-68-22 — әдәбият бүлеге;
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге
32-59-55 — халык тормышы, рухияте якла
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-66-28, 32-59-22 — рәссамн
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакц фикере белән муафыйк бу маска да мөмкин

Хатлар, кулъязмалар, фот графияләр, рәсемнәргә бәл мә бирелми һәм алар ку кайтарылмый

Газетада басылган язмала ны, фотографияләрне фай ланганда, шулай ук өземтәлә китергәндә, «Мәдә җомга»дан алынганлыгын к рсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен з казлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүләрн төгәллеге өчен реклама бир челәр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме к рсәтергә теләүчеләр өчен р дакциянең исәп-хисап счеты 509403 МФО 265566 в Бауманском отд. ПСБ

Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 428 нче таныклык белән теркәлде

Индекс — 5412

Редакция адресы: 420503, Казан, Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмахана гаебе белән ж бәрелгән сыйфат җитешсезл кләре уңаеннан 49-36-62 ном рлы телефон буенча шалтыр тырга

Газета редакциянең компы тер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4458